PRESSA.RU

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№10 (310) – ОКТЯБРЬ 2017

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

«Татмедиа»: кешеләр һәм вакыйгалар

Татарстан рекорды: уңыш сере

Минем әдәбиятым кемгә кирәк?

ДӘҮЛӘТ МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫ КҮТӘРГӘН ЙӨК АВЫРМЫ?

4 612750 670011

PRESSA.RU

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Олеся Бондаревская,
Руфия Фазылова
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Ксения Сёмина, Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин,
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: «Татмедиа» АҖ генераль директоры
Андрей Кузьмин

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: 3500 данә,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми. «Промо» һәм «Медиа» рубрикалары материаллары реклама-коммерция нигезендә басыла.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә **басылды**: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № А-2561

Басарга кул куелды: 20.10.17

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com
Коммерция директоры:
Екатерина Благодарова,
eblagodarova@inbox.ru, тел. (843) 222-09-76
Сату бүлеге белгече:
Гөлфия Фәттахова
Махсус проектлар бүлеге белгече:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ЧЫН ТОРМЫШ ТӘМЕ

Газета белән бәйле әлеге тарих Инстаграмда башланды. Безнең веб-редактор сәхифәбездә бик тә тәэсирле фото элгән иде: газета өстендә балан ботагы ята. Һәм әнә шул фотодан «укучы белән кире элемтә» процессы башланып китте. «Бу фото миңа әбием белән бабамны хәтерләтә. Балачагымны... Аларга кунакка килгәндә, өстәлдә һәрвакыт хуш исле балан бәлешләре тезелеп тора иде. Әбием аларны газетага төреп күчтәнәч итеп җибәрә, һәм камырга текст ябышып кала. Ә бабай матбугатны алдырып һәм укып барды гел. Чәй вакытында газета алып килә дә әйтә: "Укып бир әле, нәрсә язалар икән". Исән-сау гына була күрсеннәр! Аларның өйләрендә яшәгән җылылык һәм балан бәлешләренең тәме һаман да тел очында тора!» – дип яза шәрехләрендә selarisa.

Әби белән бабайга башкалар да исәнлек теләп шәрехләр яудыра башлады. Шуның белән беррәттән, үз бәлешләре белән газеталарын да искә төшерде. Әби-бабайлары һәм бәлеш-газеталары булмаганнар исә кызыгу белдерде. Ә менә sascha_grom Волков белән Груздев урамнары чатында иске китаплар сатып утыручы һәм һәркемгә сәламәтлек теләп калучы бабай турында бәян итте: «Ул агач янында Ульяновлар гаиләсе турында китап укып утыра иде», «бабай бик начар ишетә, әмма аралашырга ярата – һәрбер китап турында озаклап, тәмләп сөйли ала!»

Сөйләшергә атлыгып торучы, әмма сөйләшергә кеше таба алмаучы картлар турындагы кечкенә генә, әмма күңелне нечкәртердәй тарихлар арта торды. Аңлашыла да: балалар – эштә, оныклар – баштанаяк гаджетларда... Ә картлар турындагы тарихлар вакыт-вакыт социаль челтәрләрдә чагылып ала – башкаларны да башларын күтәреп як-якка каратыр өчен генә булса да. Әй, ваемлагыз, тәрәз артында чын тормыш та бар лабаса, диеп.

Күптән түгел генә без дә картлар йортында булдык һәм анда үзебезнең журналны күреп куандык: таушалган, димәк, укылган... Безнең өчен шуннан да зуррак бәя бармы?! Монда яшәүчеләр җирдәге соңгы сыеныр урыннарында, аларны онытмыйча, журнал яздырып сөендерүче затларга рәхмәт белдереп калды... Без бу рәхмәтне, вәгъдәбезне үтәп, бүген менә бастырырга җибәрәбез, сайтта һәм социаль челтәрләрдә таратабыз – адресатларына барып ирешсен. Шулай ук чынбарлыктан коткарыр кебек тоелган гаджетларына кереп чумган яшьрәкләргә дә күренсен – аларның да әнә шул яшькә җитәсе бар бит, ә ничек каршылыйлар картлыкларын, әлегә билгесез...

Без сезне башыгызны дисплейдан күтәреп, дөньяны нинди бар, шундый итеп күрергә чакырабыз. Әнә ул – яңа пешеп чыккан һәм хуш ис бөркеп утырган балан бәлешедәй, чып-чын, һәм кетердәп тора, яңа гына өйгә килеп төшкән газета исе дә бөркелә үзеннән. Шулай ук – әби-бабайлар, туган йорт җылысы... Чын тормыш тәмен татырга чакырабыз сезне, озын сүзнең кыскасы.

СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фарит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе:
900 сум 00 тиен

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ®



Ирек Мусин. «Әбиләр чуагы». 2010 ел.

ОКТЯБРЬ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

6. Дәүләт ММЧ күтәргән йөк ни дәрәҗәдә авыр.
«Татмедиа» АҖ Директорлар советы әгъзаларының киләчәккә фаразлары

12. Безнең география.
«Татмедиа» АҖ медиаресурсына күпме газета, журнал, теле- һәм радиокомпания керә

16. 10 ел дәвамында туктаусыз эш.
Россиянең иң эре медиахолдингының юбилее: кешеләр һәм вакыйгалар

24. Районканың бөек вазыйфасы.
Татарча «Хезмәт» газетасы ничек итеп удмурт «Азьлане» газетасына әверелә

28. Яшел Үзән турында чын дөреслек.
Су басканда, кризис туганда нишләргә, мәңге яшәячәк газетаны ничек чыгарырга

32. Өйдә кычкырып китап уку гадәте.
«Казан утлары» баш мөхәрриренең китап киштәсе

34. Андрей Кузьминнан балык солянкасы.
«Татмедиа» АҖ гендиректоры солянканы ничек пешерә

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

44. Урып-җыю – 2017.
«Кырларым-тугайларым», яки Уңыш сере нәрсәдә

50. Түгәрәк өстәл.
Торакка бәяләр ничек үзгәрәчәк

60. Каһарманнарыбыз.
Казандагы элемтәче һәйкәленең прообразы кем

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

64. Бурятия татарлары.
Татар авылыннан – тайга урманына

67. Татар авыллары.
Иң матур күл кайда урнашкан

70. Как ясау осталары.
«Рәхмәт сүзен ишетүдән дә рәхәте юк!»

74. Тарих сәхифәләре.
Алтын Урда һәм татарлар

80. Әдәбиятлар фестивале.
Минем әдәбиятым кемгә кирәк

84. Китап киштәсе.
Уен дәвам итә, яки Бездән соңгы дәвер – нинди ул

103. Бакырчы авылы.
Һәркем шулай яшәсен!

112. Серле күлләр.
Каракүл ни өчен үз урынын алыштыра

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: www.protatarstan.ru

PRESSA.RU

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

11.09

Валерий Гаркалин, театр һәм кино актёры, Россиянең халык артисты, – XIII Казан халыкара мөселман киносы фестивале ябылу көнендә:

– Казан мине һәрвакыт гаҗәпләндерә, мин аның ничек тиз үзгәрүен, күз алдында чәчәк атуын күрәм. Бүген ул Идел буеның иң матур шәһәрләреннән берсе. Минем монда бик күп еллар элек тә килгәнем бар иде. Хәтеремдә, биредә Ленинның укыганлыгы шәһәрнең горурланырдай фактларының берсе булып тоелган иде. Ә хәзер Казан борынгылыкка, архитектура һәйкәлләренә аерым бер сакчыл мөнәсәбәте белән сокландыра. Тарихка зур хөрмәт белән карый башлаган җирдә цивилизация башлана.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

20.09

Никас Сафронов, рәссам, – КФУда, Татарстан башкаласында үз эшләренең күргәзмәсе ачылуга бер көн калгач:

– Миңа Казан ошый, ләкин монда кечкенә детальләр җитеп бетми. Шәһәрдә эклектика бар. Берәр көнбатыш архитекторын чакырырга кирәк, ул барысына да читтән карасын һәм аннары шәһәрне хәрәкәт иттерә, терелтә торган ниндидер детальләр тапсын өчен. Монда барысы да бар, әмма кайчагында «галәмнән» караш, иҗади кул җитми.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

21.09



Татьяна Шевцова, РФ оборона министры урынбасары, – Лаеш районының Атабай авылында Россия Герое Марат Әхмәтшинга һәйкәл ачканда:

– Татарстан туфрагы үз ватанын яраткан һәм ныклык, батырлык, ышаныч күрсәткән бик күп искиткеч кешеләрне тәрбияләгән. Безнең хәтеребездә Россия Герое, капитан Марат Әхмәтшин һәрвакыт шундый искиткеч кеше, чын офицер һәм патриот булып калыр. Аның тормышы – Ватанга ихлас хезмәт итүнең искиткеч үрнәге. Чит җирләрдә геройларча һәлак булып, ул туган ягына кайтты һәм мәңгелеккә антына һәм хәрби бурычына тугрылык символына әверелде.

Фото: gorod.lv, segodnya.ua, kremlin.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Дәүләт ММЧ күтәргән йөк **НИ** дәрәҗәдә авыр

КАЙДА өч телдә газета чыгарыла

Редакциянең мәңгелеге сере **НИДӘ**

«Татмедиа» АҖ гендиректоры солянканы **НИЧЕК** пешерә

PRESSA.RU



«ТАТМЕДИА» КОЛЛЕКТИВЫН ЧЫН КҮҢЕЛДӘН ЮБИЛЕЕ БЕЛӘН КОТЛЫЙМ!

«ТАТМЕДИА» АҖнә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов тарафыннан юлланган котлау сүзе

«ТАТМЕДИА» АҖ коллективын чын күңелдән юбилее белән котлыйм. Узган 10 ел эчендә компания ныгып кына калмады, ә бик яхшы тизләнеш алып, күпсанлы инновацион проектларга яшәү сулышы да өрде.

Бүген бу Россиянең иң әһәмиятле, зур үсеш кичерүче медиакомпанияләренең берсе. Монда мультимедиа технологияләрен актив үзләштерәләр, социаль челтәрләргә зур игътибар бирәләр, телевизион тапшыруларның цифрлы форматына күчү буенча җитди эш алып баралар. Шуның белән беррәттән, Татарстанның басма брендлары һәм аларның иҗтимагый юнәлеше дә саклана. Милли, бигрәк тә балалар басмаларын саклауга, сыйфатлы журналистикага омтылыш – медиакомпаниянең иң зур өстенлекләре әнә шулар. Милләтара һәм конфессияара татулыкның күп гасырлык тәҗрибәсенә ия Татарстан өчен бу аеруча әһәмиятле.

«ТАТМЕДИА» АҖнең 10 еллык юбилее медиакомпания ирешкән уңышлар арасындагы тагын бер матур этап булыр, дип ышанам. Иҗади эзләнү белән һөнәри осталык бу юлда аларның аерылгысыз юлдашлары булсын!

Бәйрәм белән!

Татарстан Республикасы Президенты
Р. Н. Миңнеханов

Фото ТР Президенты сайтыннан алынды

УКУЧЫЛАР, ТЫҢЛАУЧЫЛАР ҺӘМ КАРАУЧЫЛАРНЫҢ ИХЛАС РӘХМӘТЕ **ӘҺӘМИЯТЛЕ ЭШЕГЕЗ ӨЧЕН БҮЛӘК БУЛСЫН!**

«ТАТМЕДИА» АҖ коллективына Татарстан Республикасы Президенты Аппараты җитәкчесе Ә. Ә. Сәфәров тарафыннан юлланган котлау

Кадерле дуслар!

Холдингның оешуы Татарстандагы медиатармакның үсешенә көчле этәргеч бирде, шулай ук җирле һәм төбәк мәгълүмат ресурсларын саклап калырга һәм тупларга гына түгел, ә аларны билгеле бер аудитория өчен кызыклы һәм көндәшлеккә сәләтле итәргә дә юллар ачты.

«ТАТМЕДИА» АҖ үз эшчәнлеген дөньякүләм тенденцияләрне күздә тотып башкара – моны күзәтеп тору күңелле. Сез яңадан-яңа мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кертәсез, кире элемтә механизмнарын үзләштерәсез, челтәрдә үзегезне актив рәвештә күрсәтә беләсез.

«ТАТМЕДИА» АҖнә Татарстаныбыз һәм бирдә яшәүче күпмилләтле халыкларның иминлеге хакына яңадан-яңа үрләр яулап эш алып баруларын теләп калам. Тыңлаучыларыгыз, укучыларыгыз һәм карауычыларыгызның ихлас рәхмәте – сез башкарган әһәмиятле эш өчен бүләк әнә шул булсын.

*Татарстан Республикасы Президенты Аппараты җитәкчесе, «Татмедиа» АҖнең Директорлар советы рәисе **Ә. Ә. Сәфәров***

PRESSA.RU

ДӘҮЛӘТ ММЧ КҮТӘРГӘН ЙӨК АВЫРМЫ?

«Татмедиа» АҖнең Директорлар советы әгъзалары медиахолдинг юбилее алдыннан «Татарстан» журналы белән үзләренең «Татмедиа»ны төзүдәге рольләре һәм дәүләт ММЧның киләчәген ничек күзаллаулары турындагы фикерләре белән уртаклаштылар.

1 «Татмедиа»ны төзүдә сезнең ролегез нинди булды?

2 Дәүләт ММЧның киләчәген сез ничек күзаллыйсыз?

Фото: Ната Смирнова

ДӘҮЛӘТ ММЧ САКЛАНЫП КАЛАЧАК, ҺӘРХӘЛДӘ БЕЗ ӘЛЕ ИСӘН ЧАКТА



Римма Ратникова, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе:

1 2005 елда ил күләмендә муниципаль реформа башланды, һәм беренче мәлләрдә җирле хакимият органнары – район, шәһәр администрацияләренең массакүләм мәгълүмат чараларын гамәлгә куярга рөхсәтләре юк иде. Нәрсә эшләргә? Дистәләгән район газетасын һәм телекомпанияләрне ябаргамы? Әлбәттә, Татарстан әлеге юлдан китә алмый иде. Барлык ММЧ «Татмедиа» канаты астына берләштерелде. Шул рәвешле Татарстан үзенең сыйфатлы медиасферасын саклап кала алды.

Ләкин «Татмедиа» Республика агентлыгына үзендә каршылыклы функцияләрне берләштерә дигән гаепләүләрне ишетергә туры килде, ягъни ул дәүләт идарәсенең башкарма органы да булып тора (ул Мәгълүмат министрлыгы фундаментында төзелгән иде), һәм шул ук вакытта 88 республика массакүләм мәгълүмат чарасын гамәлгә куючы да санала. Менә шул чакта, идарә органының һәм дәүләт учреждениесенең функцияләрен бүлү йөзеннән, «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте барлыкка килде. Бу 2007 елның ноябре иде, холдинг тарихы да шул вакыттан исәпләнә.

Үземнең ниндидер аерым ролемне билгеләп үтәсем килми, гәрчә бүген 10 яшь тулган «бала тууының» барлык этапларын тикшерү вакытындагы бәхәсләрендә катнашсам һәм үз позициямне белдерсәм дә. Һәм бүгенге көнгә кадәр холдинг җитәкчелеге эшчәнлегенең тәнкыйтьчесе (һәрвакыт ачыктан-ачык булмаса да) булып торам. Журналистикага һәм укучылар, тыңлаучылар мәнфәгатьләренә каршы килеп, иң мөһиме – керем кертү дигән фикер белән килешмим. Чөнки моның нәтиҗәсендә чын, талантлы журналистика югала бара. Һәм димәк, газета һәм журналлар укый, телевидение карый, радио тыңлый торган, аннан да бигрәк – журналистларга ышана торган кешеләр дә кими дигән сүз. Бу турыда барыбызга да уйланырга, борчылырга кирәк.

2 Дәүләт ММЧ сакланып калачак, һәрхәлдә, без әле исән чакта. Ләкин аларның бары тик мәгълүмат бирүче яисә тулысы белән пропагандист һәм агитатор ролен үтәүчегә әверелмәүләре мөһим. Хакимият карарларын халыкка җиткереп кенә калмыйча, халык фикерен дә хакимиятләргә җиткерергә тиешләр (Татарстан Президенты Р.Н. Миңнеханов та үзенең Дәүләт Советы депутатларына Юлламасында әлеге кире элемтәне тәэмин итүнең кирәклеген шактый кискен иттереп әйтте). Ә хакимияткә халык фикерен җиткерү өчен күбрәк ирек һәм зуррак гражданлык кыюлыгы кирәк. Кадерле коллегаларыма әнә шуны телим! Беренче юбилеегыз белән! Үзегезнең җәмгыятькә кирәклегегезне саклап калырсыз, дип ышанам!

ҮСЕШКӘ ОМТЫЛГАН ММЧ ГЫНА УҢЫШЛЫ ЭШЛӘЯЧӘК

Роман Шәйхетдинов, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгълүмат һәм элемтә министры:

1 «Татмедиа» АҖнең төп максаты – төбәкнең инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыру, уңай миграцияне тәэмин итү, массакүләм мәгълүмат чараларын үстерү һәм аларга ярдәм итү, альтернатив караш булдыру һәм мәгълүмати суверенитетны тәэмин итү максатында төбәк эчендә һәм аннан читтә республикага туры килүче мәгълүмати пространствоны формалаштыру.

«Татмедиа» АҖ Директорлар советы әгъзалары буларак, без юридик яктан компаниянең яхшы эшләвен тәэмин итеп кенә калмыйча, аның үсешен кайгыртып, эшчәнлекләренә мәгълүмати технологияләр кулланылган яңа трендларны кертергә тәкъдим итәбез – Җәмгыять эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү өчен дә, «Татмедиа»ның максатчан аудиториясен киңәйтү өчен дә башкарыла бу эш.

2 Шунысы ачык: киләчәк – социаль челтәрләрдә. Алар безнең тормышта чагыштырмача күптән түгел генә пәйда булдылар, ләкин нәкъ менә хәзер без аларның мөмкинлекләре ничек артуын күзәтәбез. Илебезнең яшәрә барган халкы – X һәм Y буыннары, мәгълүмати технологияләрдән һәм һәртөрле гаджетлардан актив файдаланып, күбрәк социаль челтәрләрдә утыралар һәм нәкъ менә аннан кирәкле мәгълүматны табалар.

Шуңа күрә үсешкә омтылган һәм әлеге аудитория көткәннәргә җавап бирә торган ММЧ гына исән калачак һәм киләчәктә уңышлы эшләячәк.

Фотолар Римма Ратникова, Роман Шәйхетдинов архивыннан

PRESSA.RU

БАСМАЛАРНЫҢ МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕГЕ АРТА БАРЫРГА ТИЕШ

Александр Терентьев, ТР Президенты Аппараты җитәкчесе урынбасары – ТР Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе:

1 Төзелгән көненнән башлап «Татмедиа» АҖнең, халык белән кире элемтәне тәэмин итеп, фикерләр төрлелеген чагылдырып, медиа тармакны үстерү, журналистлар берлегенә һәм социаль әһәмияткә ия ММЧна ярдәм күрсәтү буенча Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан куелган бурычларны эзлекле һәм нәтиҗәле рәвештә гамәлгә ашыруын мөһим дип саныйм.

2 Беренчедән, ММЧ мәгълүмат тарату каналларын диверсификацияләүгә юнәлдерелгән булырга һәм мәгълүматны максатчан аудиториягә җиткерүнең кирәкле, кулай формаларын тәкъдим итәргә тиеш. Икенчедән, басмаларның мөстәкыйльлеге, мәгълүмати трендларны формалаштырганда аларның көндәшлеккә сәләтлелеге арта барырга тиеш. Һәм, өченчедән, контентның дөреслеге һәм эчтәлекле булуы өчен җаваплылыкның артуы зарур, моннардан башка киләчәк томанлы. Әгәр әлеге факторлар системалы нигездә исәпкә алыналар икән, мин дәүләт медиахолдингына кергән ММЧ үсеше өчен уңай перспективалар күрәм.

ДӘҮЛӘТ ММЧНА НИГЕЗЕНДӘ КОММЕРЦИЯ ТОРГАННАРЫНА КАРАГАНДА КЫЕНРАК

Разил Вәлиев, ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли сораулар комитеты рәисе:

1 Биш ел элек Республика басма һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгын таркату турында документ имзаланган иде. ТР бюджетын чираттагы карау вакытында түбәндәгеләр ачыкланды: акционерлык җәмгыяте структурасындагы дәүләт ММЧ ни рәвешле финансланачак? Өметсез ситуация! Шулчакта берничә депутат, шул исәптән мин дә, агентлыкны яңадан торгызуны сорап мөрәҗәгать иттек. «Татмедиа» тормышында мин актив катнашам. Өстәвенә, өч төрле яссылыкта. Беренчедән, газета һәм журналлар авторы буларак. Икенчедән, аларның тугрылыклы укучысы буларак. Һәм, әлбәттә, эшчәнлегенең беренче көннәреннән үк – Директорлар советы әгъзасы буларак та. Мине һәрвакыт ике сорау борчыды: дәүләт сәясәтендә, шул исәптән идеология һәм тәрбия өлкәсендә рупор булган ММЧбызның эчтәлек ягы, һәм шулай ук журналистларның хезмәт хакы дәрәҗәсе. Соңгысы, кызганыч, сөендерми. Болай булганда без беркайчан да яшьләрдә әлеге профессияне сайлауга карата кызыксыну уята алмаячакбыз! Әлеге проблемаларны мин һәр утырышта диярлек күтәрәм.

2 Дәүләт ММЧ булган, бар һәм дәүләт үзе яшәгәндә булырга да тиеш! Алай гына да түгел, газета һәм журналлар электрон формада да, кәгазьгә басылган формада да яшәячәгенә ышанам. Моны алга киткән илләр тәҗрибәсе дә ачык күрсәтә. Аларда интернет-басмалар безгә караганда күпкә иртәрәк үсә башлады, әмма кәгазьгә басылганнары да беркая китмәде бит. Хәер, соңгыларына алай да челтәрдәге версияләрен көчәйтергә кирәктер – бүген яшьләр ешрак интернетка мөрәҗәгать итә. Ә инде контентның сыйфатына килгәндә, дәүләт ММЧ алдында гаять катлаулы бурыч торганын танырга кирәк: рәсми чараларны чагылдырган репортажлар, төрле хәбәрләр рәвешендәге мәҗбүри язмалар белән укучыларны беренче чиратта кызыксындырган кеше тормышы, аларның проблемалары турындагы материаллар арасында балансны ничек табарга? Монда, минемчә, дәүләт ММЧна коммерция нигезендәгеләргә караганда кыенгарак туры килә.

Фотолар Александр Терентьев, Разил Вәлиев архивыннан

Фото ТР Президенты матбугат хезмәтеннән алынды

ДӘҮЛӘТКӘ ХАЛЫК БЕЛӘН КИРЕ ЭЛЕМТӘНЕ КҮБРӘК БИРЕГЕЗ

Эдуард Хәйруллин, Татарстан Республикасы Президенты матбугат хезмәте җитәкчесе:

1 «Татмедиа»ны төзүдә минем ролем юк. 10 ел элек, Беренче каналның үзхәбәрчесе буларак, минем эшем Татарстан Республикасындагы, күрше төбәкләрдәге яңалыкларны эзләүгә, проблемаларны һәм казанышларны күрсәтүгә, ул вакытта картадагы кайнар нокталарны яктыртуга кайтып кала иде. Шунысын хәтерлим: «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале миңа «Татмедиа»дан килде. Бары тик ТР Президенты матбугат хезмәтендә эшли башлагач кына дәүләт ММЧ күтәргән йөкнең никадәр авыр булуын чынлап торып аңладым.

2 Һәм ММЧның киләчәген тагын да көчлерәк мобильлектә, шаблоннардан котылуда, челтәрдә кызыклы итеп күренә белүдә, кешеләр проблемасына өстән генә карамауда күрәм. Дәүләт ММЧна теләгем шул: дәүләткә халык белән кире элемтәне күбрәк бирергә һәм хакимиятнең гамәлләрен аңлаешлы, кызыклы итеп аңлата белергә кирәк.

> **– Дәүләт ММЧна теләгем шул: дәүләткә халык белән кире элемтәне күбрәк бирергә һәм хакимиятнең гамәлләрен аңлаешлы, кызыклы итеп аңлата белергә кирәк.**

БАРЛЫК АВЫРЛЫКЛАРГА ДА КАРАМАСТАН, ДӘҮЛӘТ ММЧНЫҢ РОЛЕ ҮЗГӘРЕШСЕЗ КАЛАЧАК

Әнәс Әскәров, «Идел-пресс» нәшрияты генераль директоры:

1 «Идел-Пресс» «Татмедиа» холдингының басма ММЧның төп өлеше басыла торган иң эре филиалы булу сәбәпле, минем җитәкче вазыйфасындагы ролем «Татмедиа» АҖнең вакытлы матбугат чараларын үз вакытында һәм сыйфатлы итеп бастыру өчен шартлар тудыруга кайтып кала.

2 Елдан-ел басмаларның саны якынча бер дәрәҗәдә тора, ләкин тираж буенча бераз кимү күзәтелә. Типография директоры буларак мин мондый фикердә: киләчәктә кайбер басмаларны кушып эреләндерү ихтималы бар.

Барлык авырлыкларга да карамастан, дәүләт ММЧның роле үзгәрешсез калачак.

Фото: Александр Ефремов

PRESSA.RU

www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
WWW.PROTATRSTAN.RU
Реклама 16+


АЭРОФЛОТ
Российские авиалинии
SKYTEAM
Москва
до 8 рейсов в день
Санкт-Петербург
Ежедневно
Франкфурт-на-Майне
2 рейса в неделю
Операторы рейсов:
АЭРОФЛОТ
РОССИЯ
Аэрофлот – шестикратный обладатель звания лучшей авиакомпании Восточной Европы и самый сильный авиационный бренд мира.* Самолетный парк компании – один из самых молодых в мире, а это дополнительная гарантия надежности, безопасности и комфорта. Рейтинг «четыре звезды» Skytrax** говорит о высочайшем уровне сервиса на всех этапах путешествия. Маршрутная сеть Аэрофлота охватывает более 300 направлений в более 60 стран мира, включая собственные регулярные рейсы, рейсы дочерних авиакомпаний и авиакомпаний-партнеров по «код-шеру».
* По данным Брендфинанс.
Реклама. Сертификат эксплуатанта №1 от 17.11.2011
г. Казань, ул. Бутлерова, д. 35/15
тел.: 8 (843) 200-95-85
8 (800) 444-55-55 (звонок по России бесплатный)
*555 МТС, Билайн, Мегафон
Установите приложение:
Зимнее расписание полетов действует в период с 29.10.17 по 24.03.18. Возможны изменения в расписании полетов.
** Скайтракс.

PRESSA.RU

БЕЗНЕҢ ГЕОГРАФИЯ

«ТАТМЕДИА» АҖ – Россия Федерациясендә иң эре төбәк медиакомпаниясе





«ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕНЕҢ МЕДИАРЕСУРСЛАРЫНА ТҮБӘНДӘГЕЛӘР КЕРӘ:

98

РАЙОН, ШӘҺӘР ҺӘМ РЕСПУБЛИКА ГАЗЕТАСЫ

43 газета рус телендә,
49ы – татар телендә,
5се – чуваш телендә
һәм **1** газета удмурт телендә чыга.

15

ЖУРНАЛ

17

ТЕЛЕКАНАЛ

11

РАДИОСТАНЦИЯ

87

ИНТЕРНЕТ ЧЕЛТӘРЕНДӘГЕ САЙТЛАР

«ТАТАР-ИНФОРМ» МӘГЪЛҮМАТ АГЕНТЛЫГЫ

PRESSA.RU

Фото «Татмедиа» АҖ архивыннан

«ТАТМЕДИА» ТЕЛЕКАНАЛЛАРЫ



Йолдыз Крепостина фотосы



«ТАТМЕДИА» РАДИОКАНАЛЛАРЫ



Радиостанцияләр: «Күңел» «Болгар» «Арча» «ДИ-ФМ» «Авторадио»

PRESSA.RU

«ТАТМЕДИА»: КЕШЕЛӘР ҺӘМ ВАКЫЙГАЛАР

10 ел – балалар яше генә әле ул. Хәтта яшүсмерләрнеке дә түгел. Артта – тырыша-тырыша каләм үткенләү еллары; медиапространствоны яулаудагы тәүге адымнар; аннан – ясле-балалар бакчасы, мәктәп... Әнә шул елларда «Татмедиа» АҖ филиаллары арасында дуслык җепләре үрелә башлый да инде. 10 ел буе акыллы, игелекле, позитив яңалыклар белән уртаклашу һәм Татарстан ММЧын укучы-тыңлаучы-караучыларны республикабызның кайнап торган иҗади-эшлекле тормышына җәлеп итү. Яшьнәп торган яшьлек һәм җитлегү чорлары – алда. Аннан инде тупланган тәҗрибәне яшьләргә тапшырырга кирәк булачак. Россиянең Татарстан Республикасында яшәүче халыкны мәгълүмат белән тәэмин итүче иң эре медиахолдингларыннан берсе – «Татарстан» журналы фотопроекты сәхифәсендә. Кешеләр һәм вакыйгалар аша, әйдәгез, аның үтелгән елларына күз йөртеп узыйк.

2010 ел.
Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм «Татмедиа» республика агентлыгы җитәкчесе Марат Моратов «Сөембикә» белән «Татарстан» журналларында кунакта.

2012 ел.
«Вести в субботу» программасының алып баручысы Сергей Брилёв «Татмедиа»да.

Фотолар «Татмедиа» АҖ архивыннан

PRESSA.RU

татмедиа 10 ел

2010 ел.
Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Татар-информ» Мәгълүмат агентлыгында яңалыкларның ничек эшләнүе белән кызыксына.

Яр Чаллы телевидениесе һәрчак вакыйгалар үзәгендә.

2012 ел.
Өмәләр – җитди вакыйга.
Сезне шаян «чаян»лылар сәламли!

Замана журналисты бер үк вакытта репортёр да, фотограф та, блогер да булырга тиеш. Әйтик, Любовь Владимировна Агеева шикелле.

PRESSA.RU

2011 ел. «Казанский медицинский журнал» – тәмле дә, сәламәтлеккә дә файдалы.

Ел лидерларын «Татмедиа» АҖ генераль директоры Андрей Кузьмин тәбрикли.

Газета укырга кирәк. Матбугат кеше күңеленә акыллылык, игелеклелек орлыклары сала.

«Казань» журналы редакторы Юрий Балашов яраткан авторы Светлана Колина белән.

Танылган журналист Юрий Шевчук турында белмәгән кеше юктыр. Кызганыч, арабыздан иртә китеп барды...

Минзәләчә Яңа ел.

PRESSA.RU

татмедиа 10 ел

2015 ел.
ТР Премьер-министры Илдар Халиков Айрат Зариповка «министр портфелен» тапшыра.

«Арча хәбәрләре»нең баш мөхәррире Исрафил Насыйбуллин эштән бушаган арада гер күтәрү белән мавыга...

PRESSA.RU



Ната Смирнова фотолары

РАЙОНКАНЫҢ БӨЕК **ВАЗЫЙФАСЫ**

«…Район үзәкләрендә гомер итүче кешеләр янәшәләрендә яшәүче кешеләр турында сөйли торган «үзләренеке» диярлек басма матбугат барлыгына ияләшкән инде. Мәскәү проблемалары һәм сәяси интригалары турында түгел, ә райондагы яңалыклар турында сөйләүче газета файдалы һәм кызыклы: кайсы танышның юбилее, кайсы колхоз уңыш җыюда алдынгы, җирле сатып алулар һәм сатулар. Бу яктан караганда, бүгенге көндә район газеталары чыннан да халыкчан…»

Автор:
Алсу Троицкая

ДӨНЬЯДА БҮТӘН МОНДЫЙ ЮК

Бу юлларны укыганда, мин әле генә кибеттә очраткан кешенең көтмәгәндә миңа яңа чыккан газета битеннән карап торуын күз алдыма китерәм. Хәтта күзен дә кыса әле – «Гарри Поттер»ның авторы нәкъ әнә шундый эффект уйлап тапкан иде бит, хәтерләсәгез. Югарыда китерелгән юлларның авторы Наталья Жукова белән дә шулай булган – Балтач кешеләрен ул газета битләреннән таныган. Ә район газетасының халыкчанлыгы турындагы фикерләре «Татарстан» журналы сәхифәләренә аның авыр әйтелешле «Полилингваль район газетасының милләтара килешүчәнлекне локаль урнаштырудагы роле («Вперёд» Балтач газетасы мисалында)» дигән исемдәге диплом эшеннән күчереп алынган.

Наталья әле генә студент-практикант иде кебек, ә бүген инде – Мари дәүләт университетын тәмамлаган һәм менә бер ай инде «Хезмәт» дигән Балтач район газетасы хәбәрчесе булып эшли.

Яшь журналист әйтүенчә, «профессиональ һәм лингвистик яктан татар, удмурт һәм рус укучылары аудиториясен сыйдырган икенче мондый газета дөньяда юк».

Безнең дә очратканыбыз булмады.

РЕДАКЦИЯДӘ ӨЙДӘГЕ КЕБЕК…

Гомумән алганда, газетаның исеме берничә тапкыр алышынган. Арча типографиясендә басылган беренче номерлары 1932 елда «МТС» исеме белән чыккан. Аннары – «Югары уңышка», «Коммунизмга», ә 1965 елдан ул «Хезмәт» дип аталган.

Икенче катка күтәрелеп, редакциягә керәбез. Ишек төбендә төрле төстәге һәм төрле үлчәмдәге башмаклар тезелгән.



«Татарстан»га өйдәгечә уңайлы редакция буйлап экскурсия үткәргәндә, баш мөхәррир Вакыйф Зәкиев, кабинет ишекләрен ача-ача, алар белән таныштыра бара.



Гөлзидә Газизуллина һәм Зәлия Фәйзрахманова – хәбәрчеләр. Нәкъ менә алар аша Балтач халкы бистәдә һәм районда нинди кызыклы хәлләр булуын белеп тора.

«ТАМЕДИА» АҖ филиалларыннан берсе булган Балтач район газетасының үзенчәлеге аның ике телдә чыгуында. Татар версиясендә ул «Хезмәт» дип аталса, удмуртча дубляжы – «Азьлане», тәрҗемәдә ул «Алга» мәгънәсен аңлата – 1958 елда барлыкка килгән. Ә электрон версиядә газета рус телендә дә чыга.

«Өйдәге кебек», – дип пышылдый фотографыбыз.

– Бу – реклама бүлеге. Безне ашатучылар, күзгә күренми торган геройлар. Ә менә Рузилә Дәминова – баш хисапчы һәм иң озак эшләүче хезмәткәр – редакциядә 28 ел. Һәрвакыт компьютер каршында ул. Менә хәзер дә утыра, акча саный…

Рузилә Дәминова, баш хисапчы. Көнен компьютер каршында үткәрүче бердәнбер хезмәткәр. Эше шундый.

PRESSA.RU

1. Зөлфия Шакирова. Номерны басмага әзерләгәндә аны борчымавың яхшырак. Хәер, бу барлык җаваплы секретарьларга карата да шулайдыр.

2. Тәрҗемәчеләр бүлеге: Ольга Плотникова (дубляж буенча баш мөхәррир урынбасары), Ольга Матвеева (тәрҗемәче), Наталья Жукова (журналист), Екатерина Салтыкова (филолог). Алар бүлмәсенең ишеге ябылып тормый дияргә була, чөнки район газетасы ике телдә басыла – татар һәм удмурт телләрендә. Ә сайт исә рус телендә дә алып барыла.

ӨЧ ТЕЛЛЕ САЙТ

– Гомумән, бездә барысы да яза, шул исәптән мин дә. Материалларга фотоларны да үзебез ясыйбыз. Һәркемнең фотоаппараты бар. Мәгълүматны сайтка оператив урнаштырырга кирәк булганда, бу аеруча мөһим. Сайт – монысы аерым тема. Газетаның электрон версиясе башта татар телендә генә эшләнә иде, аннары рус һәм удмурт телләрендә дә барлыкка килде, – дип дәвам итә Вакыйф Мансурович, безне тәрҗемәчеләр кабинетына алып кергәндә:

– Менә алар – эшләргә теләгең булганда, барысына да ирешеп булуның чын дәлилләре. Кызлар русча да, татарча да, удмуртча да беләә. Мин инде ничә елдан бирле тел өйрәнә башламакчы булам, һич тотына алмыйм. Юкса, аерым сүзләрне беләм үзе. Мар хальёс, гажано эшъёс? – дип елмая баш мөхәррир, кызларга карап. (Хәлләр ничек, кадерле дуслар? – *Авт. Удмуртчадан тәрҗемә.*)

– Туж умой! – дип җавап бирә кызлар хор белән. (Бик яхшы! – *Авт. Удмуртчадан тәрҗемә*)

– Миңа удмурт теле ошый, ул шундый көйле. Тәрҗемәчеләребез дә чын профессионаллар. Минемчә, газетаның интернет-версиясе популярлаша бару сәбәпләреннән берсе ул, – дип, кабат сайтка кайта Вакыйф Мансурович. – Сүз уңаеннан, узган ел безнең портал республиканың шундый ук ресурслары арасында «Татар телендәге иң яхшы сайт» исеменә лаек булды.

Газета сайтына уртача 1700–1800 кеше керә. Ә ун укучыдан башланып киткән иде, диләр... Бүгенге көндә кешеләр әзер материалларны гына укып калмый, үз фикерләрен, комментарийларын да калдыра, идеяләр тәкъдим итә, конкурсларда катнаша. Хәзер әбүнәчеләр арасында «Минем әбием – иң яхшысы» дигән конкурска тавыш бирүнең кызган чагы. Веб-редактор Фирдүс Шакиров Балтач кешеләре басманың сайтына кабат-кабат керсен өчен барысын да эшли. Башка бөтен журналистлар кебек үк. Мөгаен, шушы һөнәри кызыксынучанлык район газетасының һәм аның интернет-ресурсының үсеш тенденцияләренә йогынты ясыйдыр да – милли фольклор, йолалар белән бәйле темалар бирелә торган саен ешрак пәйда була.

РЕДАКЦИЯ ЯШӘРӘ, ТРАДИЦИЯЛӘР КАЛА

– Соңгы елларда редакция составы сизелерлек яшәр-

де, һәм газета эшендә дә күп нәрсәләр үзгәрде. Әмма бездә элекке традицияләр дә калды. Журналистлар район һәм республика дәрәҗәсендәге төрле конкурсларда катнашалар. Быел редакция «Бәллүр каләм» конкурсының «Россиядә кино елын иң яхшы яктыртучы» номинациясендә бүләккә лаек булды, – дип, Вакыйф Мансурович безне күпсанлы дипломнар һәм рәхмәт хатлары эленгән стенд янына алып килә. – Инде утыз елга якын Балтачта «Хезмәт» газетасы призына хоккей турниры үткәрелә. Әмма безнең төп традициябез – ул, әлбәттә, бердәм дус-тату команда булып эшләү. Без эшлибез, идеяләрне сынап карыйбыз, газетаны һәм сайтны укучыбыз өчен, аның нинди милләттән булуына һәм нинди телдә сөйләшүенә карамастан, басманы якты эчтәлекле һәм актуаль итәргә тырышабыз. Без үзебезгә девиз итеп тә шундый шигырь юлларын сайладык: «Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!» Ышанығыз, бу бик җиңел түгел, әммa бик кызыклы.

ҺӘР АВТОРНЫҢ – ҮЗ УКУЧЫЛАР АРМИЯСЕ

«Хезмәт» газетасы укучылар белән үзара тыгыз бәйләнештән дә мәхрүм түгел – хатлар аша да, сайттагы хәбәрләр аша да. Үзәк яисә төбәк матбугаты укучысын район газетасы укучысыннан элеккечә үк шул нәрсә аера: беренчесе иң элек баш исемгә, фотографияләргә, спикерларга, дизайнга игътибар итсә, район газетасы укучысы, шул исәптән, Балтач кешесе дә, укыргамы-юкмы дигәндә, мәкаләнең темасына һәм авторның фамилиясенә карый. Район газетасының һәр журналисты, хедлайнер кебек үк, үзенең «җанатарлар армиясенә» ия. Әгәр аның язмалары кызыксыз икән, кире реакция булмаячак.

– Әйе, без шау-шулы скандаллар һәм грандиоз проектлар турында язмыйбыз. Бәлки, кем өчендер бу күңелсездер дә. Әмма районкада да булмаса, гади кешеләр турында тагын кайда язарлар соң? – дип, район газетасының бөек вазыйфасы турында нәтиҗә ясый Вакыйф Зәкиев.

3. Район газетасы лаек булган бүләкләр эленгән стенд кунакларны ишек төбендә үк каршы ала.

PRESSA.RU

ЯШЕЛ ҮЗӘН
ТУРЫНДАГЫ БАР ДӨРЕСЛЕК

«Татмедиа» АҖ филиалларының берсенә ясаган экскурсиябез тоташ «лайфхаклар» чылбырына әверелде. Һәм без яңа туфан килеп чыккан очракта – кемгә шалтыратырга, кризис башланса – нәрсә эшләргә, ә иң мөһиме, мәңге яшь торган газетаны ничек чыгарырга икәнлеген белеп кайттык.

Автор:
Олеся Бондаревская

Бусагадан атлап керүгә, тезелеп торган чиратка килеп эләгәм – газетага язылырга икән. Алдымда – театр персонажы булырдай берәү. Ул үзе белән «Николай» дип таныштырды. Һәм менә, ул язылу шартларын җентекләп белешә.

– Ник аны ваклап саткан җирдән генә алмыйсыз соң? – дип сорыйм аңардан. «Зеленодольская правда» белән «Наш Зеленый Дол» газеталарын, әйтүләренчә, чыннан да һәр киоск киштәсендә табып буламы икәнлеген белешәсем килә. – Ул газеталар сезнең һәр ипи кибетендә диярлек сатыла, диләр бит...

– Язылу арзангарак төшә, – дип җавап кайтара Николай.

– Шундый кызыклымыни газеталарыгыз? Нәрсәләр бар анда?

– Барысы да бар! – дип, горурлык белән җавап кайтара яңа танышым, тутырылачак квитанцияне күкрәгенә кысып.

РЕДАКЦИЯНЕҢ ҮЛЕМСЕЗЛЕГЕ СЕРЛӘРЕ

Халыкның килә-китә йөрүе – җирле газета редакцияләре тормышы өчен гадәти хәл. Шәһәр халкы бирегә шикаять тә китерә, гозерләрен дә белдерә, шатлыклары белән дә уртаклаша. Һәм әле идеяләр төяп тә килә икән! Язмалар, сәхифәләр өчен... Алай гына да түгел, тулы бер газетаны тутырыр өчен материал эзләп чыгасы да юк!

– «Татмедиа» безнең өчен даими оештыра торган чираттагы уку-укыту программасы кысаларында Мәскәүдән медиатренер Сергей Бондарев килгән иде. Ул безгә болай диде: «Беләсезме, сез ни өчен үлмәячәксез? Чөнки сездән халык ташкыны өзелми», – дип елмаеп сөйли «Татмедиа»ның Яшел Үзән филиаллары директоры Татьяна Витовская. – Әмма әлеге халык өзелми торган сукмакны чүп басмасын өчен, безгә 90нчы елларда бик зур көч түгәргә туры килде. Язылу хисабына гына исән калмаячыгыбызны аңлагач, шәһәрдәге барлык сәүдә үзәкләре белән килешү төзеп чыктык. Хәзерге көндә «Зеленодольская правда» белән «Наш Зелёный Дол»ның 8 мең данә тиражыннан 4 меңе ваклап сату буенча тарала.

Әлеге уңышның сере нәрсәдә соң – Татьяна Владимировнадан шуны төпченәм. Ә ул миңа подшивкалар күрсәтә:

– Элек мөхәррирләр эчтәлек һәм тупланган мәгълүматның дөреслеге өчен генә җавап бирсә, хәзер безнең алда тагын бер бурыч тора – акча эшләү, ягъни мөмкин кадәр күбрәк тиражны сату. Һәр дүшәмбе без «акыл штурмына» җыелабыз: беренче полосага нәрсә куябыз? Әйтик, Шәһәр көне алдыннан болай эшләдек: Аллегро-

Фото: Александр Ефремов

1. «Зеленодольская правда» газетасының реклама буенча белгечләре Ольга Скибина һәм Надежда Филипова басма кешегә барып җитсен, ә кешеләр аны алырга атлыгып торсын өчен тырышалар.

ва, Варум һәм Лада Дэнс фотоларын бирдек тә шундый язу урнаштырдык: «Бәйрәмгә бу йолдызларның кайсы киләчәк?» Кырылып алдылар! 1 сентябрь алдыннан шундый табышмак биргән идек: хәзерге мәктәп директорларын аларның балачак фотоларыннан танып белегез. Тагын бер яхшы бара торган нәрсә – ул сенсация: мәсәлән, бистә почтасының 4 хезмәткәре каракны тоткан... Мин юл хәрәкәте фаҗигаләрен төшереп урнаштыруны тыям (гәрчә алар сатылуны тәэмин итә торган булса да), миңа, мисал өчен, урамда узып барганда кемнедер коткарган студентның – булачак врачның фотосы кадерлерәк...

– Элек безнең дүрт ярым полосабыз шәхси игъланнар өчен каралган иде. Хәзер күбесе Интернетка кереп чумды. Шул исәптән безнең клиентлар да. Аларның һәрберсе өчен чын мәгънәсендә көрәшергә туры килә, – ди язылу бүлеге хезмәткәре Ольга Скибина. – Газетага ихтыяҗ булу безнең журналистларның эшчәнлегеннән дә тора. Ягъни язылган материалларның мавыктыра алуыннан.

Журналистларга килгәндә... Татьяна Владимировна кабинетындагы күпсанлы грамоталар белән кубокларга күз салсак, алар чынлап та үз эшләренең осталары. Хәер, ике газетаның, телевизион каналның һәм аларны берләштерүче порталның популярлыгы нигезендә коллегаларымның каләмнәре үткенлеге генә ятмый.

ТУФАННЫ ТУКТАТКАН СҮЗ

– Әйбәт килеп чыккан нәрсә турында сөйләп тору кызык түгел. Килеп чыкмаса, сөйләргә мөмкин менә. Нишләп килеп чыкмавы турында, – ди Рөстәм Сабитов. «Зеленодольская правда» газетасында сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы бүлегенә җитәкчелек итә ул. Офис хроникасы һәм экология өчен дә җаваплы. – Әйтик, үзәк паркны юллар һәм биналар белән урталай бүлү идеясе әле проект чагында ук без мөмкин булган һәркемне җәлеп иттек: эколог-экспертларны, җәмәгать эшлеклеләрен, депутатларны... Алар ярдәмендә хакимиятне бу гамәлнең ялгыш булачагына инандыра алдык. Парк бит ул – шәһәребезнең экологик умырткасы! Яшел Үзән – үзе үк «яшел» сүзеннән... һәм ул яшел урыннарны саклап калу кайчакта мөмкин дә булмый. Әйтик, паркта барыбер дә йорт төзергә керештеләр. Әмма без кул кушырып утыручылардан түгел.

– Миңа төннәрен генә шалтыратмыйлар. Куръмсең, йокласын, диләр, хәлемә керәләр, – дип шаярта Юлия Озерова. Ул «Наш Зеленый Дол» газетасы редакциясенең хатлар бүлеген җитәкли. Моннан тыш, «Зеленый Дол-24» телеканалының махсус хәбәрчесе вазыйфасын да башкара. Ул, филиалда беренчеләрдән булып, модадагы трендны үзләштерә, ягъни смартфонга материалны төшереп ала да шунда ук, редакция сайтында урнаштырыр өчен, кыскача шәрех белән коллегаларына җибәрә.

Юлия безгә бер очрак турында сөйләде: җәй көне шәһәрдәге берничә йортны су баса. Анда яшәүчеләрнең ремонты яңгыр сезонына туры килә.

– Иртән бер йорттан шалтыратсалар, кичкә инде – икенчесеннән. Оператор төшергән материалны монтажлап өлгерә алмыйча җәфаландык. Шулай булгач, соңгы чакыруларына үзем генә бардым. Кешеләр фатир ишекләрен ачып җибәрәләр, ә эчтә – туфан. Чыланмас

2. «Зеленодольская правда» командасы.

3. Рөстәм Сабитов үз материалларында шәһәрнең экологик мәсьәләләрен күтәреп чыга. Шул рәвешле Яшел Үзәннең яшеллеге хакына да, дөреслек өстен чыксын өчен дә көрәшә.

4. «Наш Зеленый Дол» газетасы редакторы Светлана Васильева тулы бер завод тарихын да, бер эшче язмышын да язып бирә ала. Кайсын гына алма, әйбәт роман укыгандай, аерыла алмаячаксың.

5. Журналист Юлия Озерова һәм оператор Дамир Низамов вакыйгалар куерган урынга беренче булып килеп җитеп кенә калмыйлар, ә һәрчак гамәл белән ныгытыла торган газета сүзе белән ярдәм дә итәләр.

PRESSA.RU

1. «Зеленый Дол» Мәгълүмат үзәгенә һәртөрле интернет-инновацияләр кертү процессы (өзлексез диярлек) белән үзәкнең директор урынбасары Владимир Витовский җитәкчелек итә.

2. Яхшы баш-исем – текст казанначак уңышның 80%ын тәшкил итә, диләр. Ә калган 20%ын – нәрсә? Төгәл җавапны «Зеленодольск яңалыклары» сайтының модераторы Илья Ануфриев белә. Ул тәүлекнең 24 сәгате буена диярлек – онлайн.

өчен, аяк киемен салып керергә туры килде... – дип искә ала Юлия. Бу тарихның шундый шау-шу куптаруы проблеманы тиз арада хәл итәргә мөмкинлек биргән. Подрядчы оешма бәлагә тарыган фатир хуҗалары белән ремонт компания хисабына уздырылачак, дигән килешү төзегән.

– Әле ул адреслар буенча кабат йөреп чыгарга кирәк булачак: чынлап та эш барамы икән, вәгъдәсендә торганмы оешма җитәкчелеге, – ди Юлия. Хәзер ул чираттагы проблемалы материалны эшли – бер егетнең армиягә китәсе килә, ди, әмма бара алмый, чөнки йортларын сүткәннән соң теркәлеп өлгермәгәннәр. Әле яңа йортка кермәгәнгә күрә, теркәлер урыны юк, ә хезмәт итәргә бүген үк чыгып китәргә әзер үзе.

– Безнең шәһәр мәгълүматка кытлык кичерә торган урын түгел, сәбәпләр дә, вакыйгалар да табылып кына тора. Ул бик күпкырлы. Һәм без яшелүзәнлеләрнең проблемаларын һәрвакыт аларның үзләреннән белеп торабыз. Бу очракта төбәктәге ММЧның мөмкинлекләре зуррак, – ди Татьяна Витовская. – Инкассаторларны талаганнар иде, хәтерегездәме? Без эксклюзив материалны беренче булып эшләдек ул чакта – Богаченконың коллегасына чыктык та җинаятьче турындагы мифны, Робин Гуд хакындагы мифтай, куып тараттык. Кайвакыт теге яки бу онлайн-ММЧнда безнең шәһәргә кагылышлы язмага юлыгасың да шунда ук аңлап аласың: моны язган кеше Яшел Үзәндә, вакыйга барган урында булмаган, ә мәгълүматны башка бер чыганактан алган. Андый чакта укучылар безнең басмага өстенлек бирә, һәм бу шатлыклы хәл.

ПЛАТФОРМАДА ОЧРАШКАНГА КАДӘР...

Шулай да укучы игътибары өчен иң көчле «сугышлар» кәгазь басма битләрендә түгел, ә виртуаль пространствода бара.

– 2011 елда без zpravda.ru дип аталган сайтыбызның концепциясен тулаем үзгәрттек. «Татмедиа»дан экспертлар килде, мастер-класслар уздырды. Хәзер безнең барлык хәбәрчеләр дә – универсаллар. Һәм бу без уйлаганнан да кызыклырак булып чыкты, – ди «Зеленый Дол» Мәгълүмат үзәге директоры урынбасары Владимир Витовский. – 150 кеше керүдән башланган иде сайтның рейтингы. Алты ел элек безгә бу әйбәт күрсәткеч булып тоелды. Хәзер исә көненә 4 меңгә кадәр керүче җыела. Безнең әле тагын да үсәргә мөмкинлегебез бар. Узган атнада гына «Татмедиа» күпкә уңайлырак интерфейс булдырган беренче басмалар рәтенә эләктек. Әлеге интерфейс барлык платформалар өчен дә каралган: мобиль телефоннар, планшетлар. Һәм, әйтергә кирәк, эш үзеннән-үзе җайлыракка әверелде.

– Сайтның контенты максималь рәвештә мультимедиалы булырга тиеш. Текстны фото, сурәт белән бизәми ярамый, өстәвенә, видео белән дә тулыландырылса, бигрәк тә әйбәт, – ди «Новости Зеленодольска» сайтының мөхәррире Илья Ануфриев. – Ә басылган материалның уңышлы булу-булмавының 80%ы аның баш исеменә бәйле. Кайвакыт нинди дә булса нормативларның үзгәртелүе турындагы яңалыкка башисем эзләп шактый озак баш ватарга туры килә.

Илья миңа сайтның статистикасын күрсәтә. Сайтка керүчеләр арасында РФнең башка төбәкләрендә яшәүчеләр дә бар, хәтта чит илләрдән дә керәләр, ди, әмма төп аудиторияне шулай да яшелүзәнлеләр тәшкил итә. Җирле хәлләр һәм кешеләр турындагы материалларның зур игътибар җәлеп итүе дә шуның белән аңлатыла. Сайттагы соңгы иң күп каралган видео – Данил Буранов турындагы материал. Ул «Голос-6» шоу-программасына узган иде. Ә менә «Яңалыклар»дан кала иң популяр сәхифә – «Портретлар телеГалереясе». Бу күренекле яшелүзәнлеләр турындагы фильм-интервьюлар. «Тиз игътибар итү»не күздә тоткан сәхифәләр дә шактый популяр икән: «Белергә хокукым бар» (шәһәр һәм район тормышына кагылышлы иң кискен сораулар, дәгъвалар, тәкъдимнәр һәм фикерләр туплап бирелә монда) һәм «Мобиль репортер». Соңгысы өчен шәһәрлеләр үзләрен дулкынландырган яки борчыган нәрсәләрне фотога төшереп җибәрә: Дан скверындагы диварга рәсем ясаучыларны, мисал өчен. Йә булмаса – түбәдән узып китеп үсеп утыручы көнбагышларны.

– Без даими рәвештә нәрсә дә булса өчен тавыш бирү игълан итәбез (түләүле смс-игъланнар, бу күпмедер дәрәҗәдә керем чыганагы да булып тора): ул иң шәп шәһәр күренеше фонындагы фото да, яки шәһәрдәге иң шәп урынны гәүдәләндерүче фото да булырга мөмкин һ.б. Медицина хезмәткәре көне алдыннан яшь табибларны олыладык (алар шәһәрдә гел җитми), үзәк район хастаханәсендә эшләүче иң яхшы яшь белгечне тавыш бирү юлы белән сайладык, – ди Татьяна Витовская. – Сайтыбызда 14 анкета элдек. Сез күрсәгез нәрсә килеп чыкты... ҮРХда «хирургия» белән «травма» арасында чын көрәш башланды... Табиб-травматолог җиңеп чыкты, ахыр чиктә! Аңа – дан, шөһрәт, ә безнең сайтыбызга – рейтинг, дигәндәй...

«Татмедиа»да күптән түгел генә узган бер тренинг вакытында мөхәррирләргә уңышлы мультимедиа проектка гына ышанып, тынычланып калмаска киңәш иткәннәр.

– Тиздән сайтлар да ихтыяҗ тудырмый башлаячак, барлык мәгълүмат ташкыны соцчелтәрләр белән



3

мессенджерларга китәчәк. Шулай булгач, без дә ул платформаларга күчәргә мәҗбүр: «ВКонтакте»да ике төркемне алып барабыз (анда барлыгы 30 мең реаль язылучыбыз бар), Facebookта – бер төркем, Instagram, Telegram каналларын да эшлибез, – дип сөйли Татьяна Владимировна. – Әлбәттә, социаль челтәрләрдәге контент безнең осталарыбыз – журналистлар эшләргә күнеккән форма түгел. Әмма без тырышабыз. Һәм, кабатлап әйтәм, безнең өстенлегебез – дөреслектә. Шулай ук эксклюзивлыкта – кайвакыт без актив рәвештә теге яки бу мәгълүматны раслый, йә булмаса кире кага алабыз. Сүз уңаеннан, безгә ара-тирә федераль мәгълүмат агентлыклары да мөрәҗәгать итә – нинди дә булса фото яки видеосюжет кирәк булганда, мәсәлән.

СТРИНГЕР ЭЗЕҢӘ БАСЫП КИЛСӘ...

Яшел Үзән редакциясе контентының югары көндәшлелеге «Зеленый Дол – 24» дип аталучы үз ТВ-каналының нигезендә үсеп чыгуына да бәйле. 90нчы еллар башында әлеге телекомпания республикада беренчеләрдән булып лицензия ала, районнардан беренче булып эфирга чыга. Бу елда телекомпания шулай ук беренчеләрдән булып кабельле яктыртуга күчү буенча челтәрдәге партнеры «Татарстан – 24» белән бергә лицензия алды. Әбүнәчеләр базасында хәзерге көндә – 30 меңнән артык яшелүзәнле, ел саен алар арта гына бара, 19%ка ук хәтта.

Телеканал студиясенә барып кергәч, беренче эш итеп ике гүзәл кыз – «Яңалыклар» сәхифәсенең алып баручылары белән сөйләшәм. Болар – Татьяна Коварина һәм Айгөл Герасимова. Мәгълүмат үзәгенең һәрбер хезмәткәре шикелле үк, кызлар – күптөрле бурычларны хәл итәргә өйрәнгәннәр. Алар каналның йөзе генә дә түгел, ә – баш мие дә. Айгөл – яңалыклар хезмәте мөхәррире, өстәвенә, ул әле республикадагы яшүсмерләр өчен иң яхшы мультимедиа проекты – «Яшь журналист мәктәбе»н алып бара. Бу проект кысаларында балалар үз мәгълүмати программаларын әзерләргә һәм яздырырга өйрәнә. Татьяна яңалыкларның сюжетлары һәм коммерцияле видеоматериалларның чыгарылышы өчен җаваплы.

Күпчелек җиһазларны үз акчаларына алганнар, рекламадан җыелган керем хисабына. «Татарстан – 24» республика каналы составында чыга торган булса да, район каналлары арасында бу бик сирәк очрый торган, гадәти булмаган күренеш.

– Медиабазардагы көндәшлек бүген бик көчле. Мисал өчен, нинди дә булса вакыйгага, синең белән беррәттән, гаять кыйммәтле җайланмасын күтәреп, берәр «стрингер» да килергә мөмкин. Һәм ул, гадәттә, сыйфаты ягыннан нәкъ синекедәй материал эшли. Ә син әле, үз чиратында, реклама бирүче сюжетның меңләгән кеше караячак, дип инандырырга тиеш буласың. Җирле элемтә операторларына рәхмәт инде: алар актив рәвештә районга кабель сузалар, ел саен безнең аудитория арта гына бара, – ди «Зеленый Дол» Мәгълүмат үзәгенең коммерция бүлеге җитәкчесе Елена Сабирҗанова. – Без, барлык башка редакцияләр кебек үк, икътисадый кризисның нәтиҗәләрен аермачык тоябыз. Әйтик, Яшел Үзән районында бер ел эчендә 200 гә якын кече һәм урта эшмәкәрлек оешмасы ябылды. Ә бит нәкъ менә шулар – безнең йөз тоткан аудиториябез... Креативтан башка беркая да бара алмыйсың бүген.

Мин Елена сөйләгәндә аның тавышындагы борчу һәм киеренкелек аһәңнәрен ваемлап алырга тырышам, әмма, юк, аның күтәренке кәефе өстенрәк чыга. Менеджерлар иң яхшы «медиапроектлар»ны искә төшерә, мәсәлән, «Звездочка ТВ Зед» программасында дүрт яшьлек кыз баланың, әнисе кулын җибәрмичә, шигырь укыганын. Монтаж вакытында ул кулны күренми торган иткәннәр... Ә бер киңәшмәдә «витаминлы дүшәмбе» оештырганнар: һәр язылган түрә әфлисунлы костюмнар киеп алган балалар кулыннан әфлисун алу бәхетенә ирешкән... Ничек баш тартасың ди инде әфлисуннан?

– Шәһәр халкы безнең барлык инициативаларны да бишкуллап күтәреп ала. Дүртенче ел рәттән ММЧ фестивале уздырабыз, анда безнең газета сәхифәләренә тәңгәл берничә мәйданчык эшли. Быел фестивальгә 4 мең кеше килде. «Татмедиа» АҖндә Яшел Үзән ММЧның имиджын ныгытып кына калмыйбыз, ә акча да эшлибез. Тиздән көтеләчәк зур чара – «ТихоTVорение» бард җырлары фестивале, ул ел саен көзен үткәрелә, – ди Татьяна Витовская. – Тик утырып торган юк, без төрле мәгълүмати сәбәпләрне эзләп кенә йөрмибез, аларны үзебез үк уйлап табабыз!

Ә иң шәп яңалыкларның берсе: сентябрь азагында Дагомыста узган «Вся Россия – 2017» журналистлар фестивалендә «Наш Зеленый Дол» газетасы «Иң шәп шәһәр проекты» номинациясендә илебезнең шәһәр газеталары арасында икенче призлы урынга лаек дип табылды.

3. «Иң актуаль яңалыклар һәм кызыклы сюжетлар гына эфирга чыга ала. Моның өчен күпме көч һәм дубль сарыф ителәчәген сөйләп тору артык» – алып баручылар Татьяна Коварина белән Айгөл Герасимованың эш кредосы әнә шундый.

4. Бернинди авырлыклар да куркытмый, ә бары рухландыра гына торган бердәм коллектив.

4

PRESSA.RU

ИЛФАК ИБРАҺИМОВНЫҢ КИТАП КИШТӘСЕ

Язучылар нинди китапларга өстенлек бирә? Әдәби басмаларның баш мөхәррирләрен нинди китаплар илһамландыра? Ике сорауга да җавапны татар матбугатының иң саллы һәм олы тарихы булган басмаларының берсе – «Казан утлары» журналы баш мөхәррире, танылган татар шагыйре Илфак Ибраһимовның (әдәби тәхәллүсе – Мөхәммәт Мирза) китап киштәсенә күз салып табарга мөмкин.

1. БАЛАЧАКТА МИҢА ЗУР ЙОГЫНТЫ ЯСАГАН КИТАПЛАР...

Безнең өйдә кычкырып китап уку гадәте бар иде. Ул гадәтне Әткәй кертте – тарихчы, мәктәп директоры. Ул фронтовик та иде. Әткәйнең беренче тапкыр «Моабит дәфтәре»н укыганын ишеттем дә, Муса Җәлил шигъриятенә мәңгегә гашыйк булдым. Ә аннары сугыш чоры язучыларының прозасына – Ибраһим Гази, Нәби Дәүлиләргә... Шулай бервакыт Әткәй: «Карале, улым, керәчин яктысында укып күзем арыды, әйдә, син дәвам ит әле», – диде... Һәм мин шуннан укый башладым. Өйдә һәм авыл китапханәсендә нәрсә табабыз, шуны кырып-себереп укый идек без ул заманда.



2. ХӘЗЕР УКЫГАН КИТАБЫМ...

Тапталган, уйлап чыгарылган, артык беркатлы сюжетларны яратмыйм. Психологик романнарга күбрәк өстенлек бирәм. Миңа әдәби каһарманнарның язмышы кызыклы. Нәрсә эзли адәм баласы бу дөньяда? Кыйммәтләре нинди аның? Ник ул әлеге дә баягы гамәлне кыла, нишләп башкача эшләми? Безнең журналда казах прозаигы Телен Абдиколының «Акыл сугышы» һәм үзебезнең татар язучысы Фоат Садриевның «Кышкы яшен» повестьлары басылып чыккан иде. Алар бүгенге заманны тасвирлый. Әмма икесендә дә олигарх-каһарманнар, баскыннар, янгыннар, үтереш, һәлакәтләр юк... Ә чын тормыш вакыйгалары белән кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр психологиясен гәүдәләндерү бар. Мондый төр әсәрләрне яшь авторлар Рөстәм Галиуллин белән Айгөл Әхмәтгалиева да иҗат итә бездә...

Фотолар «Казан утлары» журналы редакциясеннән алынды.

3. ЯРАТКАН ӘСӘРЛӘРЕМ

Кайчагында бүгенге татар әдәбияты кризис кичерә, дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Мең кат кабатларга да әзермен: бу алай түгел! Шигърияттә кризис юк та юк! «Казан утлары»ның һәр санында бүгенге заманның 5-6 шагыйрен биреп барабыз. Мин аларның барысын да яратам! Заманыбыз шагыйрьләреннән дистәләгән исемне атый алам. Әйтик, узган елны үзем өчен Фирүзә Җамалетдинова белән Айрат Суфияров лирикасын ачтым. Аларның шигырь шәлкемнәрен укып чыккач, шунда ук анык карарга килдем: кичекмәстән, бастырырга кирәк үзләрен!

Шушы көннәрдә генә Халыкара ТЮРКСОЙ оешмасы 2018 елның төрки телле әдәбиятындагы Адәм исемен игълан итте. Ул безнең якташыбыз – шагыйрь, публицист Зиннур Мансуров. Ул, үз чиратында, безнең татар поэзиясе Адәменең иҗаты буенча чын белгеч. «Тукай белән әңгәмәләр» дип исемләнгән үзенчәлекле китабында Зиннур Мансуров Тукай сүзләре белән үзенә сорау куя һәм аның сүзләре белән үк җавап та бирә. Ягъни Тукай безнең күз алдында терелгәндәй була… Шуннан аңлыйсың: Тукай чыннан да – пәйгамбәр! Аның социаль лирикасы – бөек, һәм әле Тукайны уза алганыбыз юк безнең. Аның язганнары бүген дә актуаль. Тукай премиясе лауреаты Роберт Әхмәтҗанов әйткәнчә, чын шагыйрь ул – Тукай биеклегенә аз гына булса якын килә алган каләм әһеле. Гамил Афзал белән Зөлфәт ул биеклеккә якыная алдылар, минемчә…



4. СОҢГЫ УКЫГАННАРДАН НӘРСӘ ТЕТРӘНДЕРДЕ…

Четерекле сорауларга, үткәнеңә әйләнеп карамыйча, җавап биреп булмый. «Казан утлары» битләрендә тарихи әсәрләргә урын күп бирелү дә, мөгаен, шуның белән аңлатыладыр. Күптән түгел генә Анатолий Егинның «Үзбәк хан» дип аталган менә дигән романын татарчага тәрҗемә итеп бастырдык. Аның төп каһарманы – Алтын Урданың атаклы хакиме. Бездә шулай ук Рабит Батулланың «Илбашы» да басылды. Ул республикабызның беренче президенты Минтимер Шәймиев турындагы хикәяләрне туплаган әсәр. Быел ике номерда прозаикларыбызның яңа романнарын бастырдык: Вахит Имамовның «Карабәк» һәм Фәүзия Бәйрәмованың «Хиҗрәт» әсәрләрен. Бу кульязмаларны беренче булып укый алуым белән горурланам! Әлеге романнар һәм бүгенге татар прозасы турында күп сөйли алам, әмма аның турында башкаларның ни уйлавы да мөһим бит. Елына берничә тапкыр безнең редакциядә түгәрәк өстәлләр уза. Анда без иң күренекле галимнәрне, белгечләрне чакырабыз. Алдагы очрашуларның берсендә «Карабәк» романын тикшерәчәкбез.





5. СЕЗГӘ ДӘ УКЫРГА КИҢӘШ ИТӘМ!

Халед Хоссейниның «Бегущий за ветром» романын. Ул аның тәүге романы, басылып чыгуга ук бестселлерга әверелә һәм авторына дөньякүләм танылу китерә. Әфган сугышы фаҗигасе, АКШ һәм башка илләргә иммиграциягә китәргә мәҗбүр ителгәннәр язмышы турында ул китап. Әлеге качып китүчеләр арасында Хоссейни үзе дә була. Димәк, китабы автобиографик нигезгә ия дип әйтергә мөмкин. Мин аны дүрт төн эчендә укып чыктым – аерыла алмыйча, йотлыгып. Ул китапны татарчага тәрҗемә итәсем һәм «Казан утлары»нда бастырасым килә.

6. КӘГАЗЬ КИТАПМЫ, ЭЛЕКТРОН БАСМАМЫ?

Бу ике вариантның һәрберсе дә – китап, иң мөһиме әнә шул. Мин үзем кәгазь вариантына өстенлек бирәм, әмма кешеләрнең торган саен күбрәк планшеттан укуын күреп тә гаҗәпләнмим. Бер интервьюсында академик һәм җәмәгать эшлеклесе Рафаэль Хәкимов миңа: «Менә элек параллель дөнья турында сөйлиләр иде. Кайда ул, дип аптырыйлар. Кайсы галәмдә? Без аны күз алдыбызга да китерә алмый идек, әлбәттә! Ә хәзер шул «параллель» дөнья кешесе – минем каршымда. Наушникларын киеп алып, шул үз дөньясында утыра, мине ишетми дә, күрми дә, әмма ул барысын да белә!» «Безгә аның белән нәрсә эшләргә соң?» – дип сорыйм. «Аның тормышына үтеп керергә, һәм үзебездәге иң шәп нәрсәләрне тәкъдим итәргә, ди». Без бу киңәшне тотып эш итәбез: хезмәттәшләребез еш кына мәктәпләргә чыга, без – редакторлар һәм язучылар – булачак укытучыларга дәресләр бирәбез. Сүз педагогик көллиятләр һәм югары уку йортлары студентлары турында бара.

7. КИТАП МИНЕМ ӨЧЕН НӘРСӘ УЛ?

Иң әүвәл – әдәбият, дәреслек, киңәшче! Әгәр яхшы китап белән яхшы фильм арасында сайларга туры килсә, мин һәрчак китапны сайлыйм.

PRESSA.RU

РЕДАКЦИЯ КУХНЯСЫ

АНДРЕЙ КУЗЬМИННАН *төнге судак солянкасы*

Автор:
Татьяна Вафина

– Ир-ат мамонтны аулап, тотып алып кайтырга, ә хатын-кыз шуны пешереп-әзерләп бирергә тиеш, – дип белдерде «Татмедиа» АҖ генераль директоры Андрей Кузьмин «Татарстан» журналының «аш-су бүлмәсе»нә шәхсән үзе тотып кайткан бер кечкенә «мамонт»ны күтәреп кергәндә. Ул «мамонт» дигәннәре бик зур судак балыгы булып чыкты.

Фото: Ната Смирнова

ТАТАРСТАН

PRESSA.RU

Андрей Кузьминның «мамонт» дигәне бик зур судак балыгы булып чыкты.

БАЛЫКЧЫ СУДАКНЫ ЕРАКТАН КҮРӘ, ХӘТТА ТӨНЛӘ ДӘ

– Мин аш-су эшенә һушым китә торган кеше түгел. Тик кайчак табигатькә чыккач, әйтик, мангалда шашлык кыздыра алам. Хатын-кызны иткә якын җибәрмим, ник дигәндә, табигатьтә ир-атның җаваплылык даирәсенә керә ул.

– Бүген бездә бөтенләй ит түгел бит, табигатькә дә чыкмадык. Ләкин, шуңа карамастан, ризык әзерләргә туры киләчәк. Бу безнең бер традиция. Нәрсә пешерәбез соң?

– Солянка. Балык солянкасы. Судактан, – дип, Андрей Владимирович җиңнәрен сызгана да, балыкны чистарта-бүлгәли башлый.

– Бу – балыктан пешерелә торган иң яраткан ризыгыгызмы, әллә бу судакка тукталуыгызның берәр сере бармы?

– Тел төбендә яшерелгән мәгънәсе бар. Мәгълүматны җитештерү һәм тарату белән шөгыльләнә торган бик зур оешмабыз бу өлкәдә шулкадәр төрледән-төрле матбугат чараларын берләштерә ки, шушы солянканы хәтерләтеп куя. «Татмедиа» җәмгыятендә телевидение дә, радио да, газета-журналлар да, интернет басмалар да бар, ягъни медиахолдингта матбугатның һәр тарафы бергә тупланган. Солянканы да шуңа охшаш рәвештәрәк пешерәбез – аңа күп төрле нәрсә салына, бик тәмле, туклыклы, ашаучылар һәрчак сорап алырлык була ул.

– Солянканы балыктан пешерү сезнең балыкчы булуга бәйлеме?

– Әйе, мин – балыкчы һәм бу судакны төнлә Иделдән тоттым. Бу төнге судак безнең солянканың төп нигезе булачак. Солянка – бәйрәм ризыгы ул. «Татмедиа»ның юбилее уңаеннан аны бүген күп итеп, бөтенебезгә җитәрлек итеп әзерлим.

– «Татмедиа» кебек оешмалар башка төбәкләрдә бармы?

– Миңа мәгълүм булганы шул: бездәгедәй күләмлесе, бездәгедәй масштаблысы юк. Безнең тәҗрибәне өйрәнер өчен, башка төбәкләрдән һәрдаим килеп торалар. Монда оештыру, системага салу тәҗрибәсе дә, башкалары да кызыксындыра. Структура белән идарә итү мөмкинлегенә ягыннан бу система һәркемнең күңеленә хуш килә. Фәкать «Татмедиа»ның элекке җитәкчеләре моннан ун ел элек узган бу юлны, андагы киртәләрне ничек үтеп чыгарга икәнен төшенүчеләр аз. Чөнки монда муниципаль, республикакүләм мәсьәләләр бергә чорналган. Кыскасы, башка төбәкләр безнең тәҗрибәне кулана, ләкин бу кадәр киң колачлы шәкелдә түгел.

БАЛЫК ПЕШКӘН АРАДА

Ашчыбыз судак кисәкләренә салкын су салып, плитәгә куя. Әкрен утта балык пешкән арада, Андрей-

Кирәк булачак:

- 7 кг чамасы авырлыктагы судак балыгы – 1 данә;
- Суган – 2–3 данә;
- Бәрәңге – 4–5 данә;
- Кишер – 2 данә;
- Тозлы кыяр – 3 данә;
- Дәфнә яфрагы – 3 данә;
- Үсемлек мае – 2–3 аш кашыгы;
- Тоз, борыч – тәмена карап.

Владимирович томалап кыздыру өчен җитез-җитез генә яшелчәләр әзерли: суган турый, угычта кишер уа... Юбиляр турында сүзен дә дәвам итә.

– Андрей Владимирович, «Татмедиа» җитәкчелеге төрледән-төрле иҗади тәкъдимнәре белән һәрчак шаккатырып тора. Белүемчә, сез килгәч, газета-журналларга яздыру мәсьәләсенә мөнәсәбәт үзгәрде...

– Язылу кампаниясенә бәйле төрле кызыксындыру чаралары уйлап чыгару эш юклыктан түгел. Газета-журналларга язылу кими, бу процесстан качып булмый. Чөнки хәзерге заманда мәгълүматны цифрлы җайланмалардан кабул итү арта гына бара. Үз аудиториябезне югалтмыйча, мәгълүматны укучыларга җиткерү өчен, безгә заманга яраклашырга туры килә. Ниндидер кызыклы чаралар, акцияләр уйлап чыгарганда гына, халыкны кәгазьдән укырга күндереп була. Хәйрия юнәлешенә аеруча игътибар бирәбез. Чөнки бик күп өлкәннәрнең матди хәле матбугатка язылу мөмкинлеген чикли. Элек газета-журналлар тиен генә тора иде, ә хәзер пенсионерларыбыз, ветераннар, аз керемле гаиләләр, басма матбугатны әүвәлгечә укый алыр өчен, хәллерәк кешеләр ярдәменә мохтаҗ.

– Социаль челтәрләргә күчкән укучыларны кире кайтарып буламы?

– Андый челтәрләргә китүчеләр күп булды, чөнки мәгълүмат алуның бер ысулы ул. Алар белән шунда очрашабыз да. «Татмедиа» филиалларының һәрберсе социаль челтәрләрдә үз сәхифәләрен алып бара. Ник дигәндә, кайбер кешеләр хәзер шул социаль челтәрләрдә чын мәгънәсендә яши, бу бер чиргә дә әйләнеп китә.

– Мондый чиргә сезнең карашыгыз ничегрәк?

– Һәрнәрсәнең чиге булырга тиеш. Аралашу өчен бихисап мөмкинлекләр тудыра торган, яңа, мавыктыргыч коммуникацияләр – шәп нәрсә. Ләкин кешеләр тормышларын шул челтәрләрдәге гыйбарәләр, мактаулар белән үлчи башлый икән, хәерлегә түгел. Бу – бәйлелек, ә аның бар төре дә начар.

МУЛЬТИМЕДИА РЕДАКЦИЯ – ТОРМЫШ ТАЛӘБЕ

– Сезнеңчә, ниндидер алтын урталыкны табарга мөмкинме?

– Мөмкин. Без социаль челтәрләр белән эшлибез, кайбер редакцияләрне моңа күндерәбез, кайдадыр мәҗбүр итәбез... Хуҗалыгыбыз бик зур бит, газета-журналлар күп. Бөтен басмаларның да мөхәррирләре заманча карашлы, алдынгы фикерле дигән сүз түгел бит. Журналист кешенең, эшкә килеп, мәкалә язгач, өйгә кайтып китә торган чорлары күптән үткәндә калды, хәзер бәяләү өчен яңа критерийлар кертергә кирәклеген үгетләп тә, кайдадыр мәҗбүриләп тә төшендерергә туры килә. Хәзерге заманда кешеләр мәгълүматны башкача ала. Соңгы 2016–2017 елларда без бу мәсьәлә белән актив шөгыльләнәбез. Иң эре филиалларыбыз берләштерелде. Мультимедиа редакция ниндидер мода түгел, ә тормыш таләбе. Безнең бурычыбыз – мәгълүматны мөмкин кадәр киңрәк тарату. Шуңа күрә сайтлар да, социаль челтәрләр дә кирәк. Өстәвенә, син социаль челтәргә килгәнсең икән, анда бөтенләй башка тел икәнен аңларга тиеш. Мультимедиа редакция – матбугатның киләчәге түгел, бүгенгесе ул.

– «Татмедиа»да мультимедиа редакцияләр күпме? Алар ничек барлыкка килә?

– Контент дигән төшенчә бар. Контент – журналистның иҗади эш нәтиҗәсе ул, моны ул халыкка ничек җиткерә – сайт ашамы, социаль челтәрләр аркылымы яки үз сәхифәсе ярдәмендәме – башка мәсьәлә. Иң мөһиме, бу ысулларның барысын да куллану мөмкинлегенә ия булу, видео- һәм фотоматериаллар белән эш йөртә белү. Менә шул чакта контентың мөмкин кадәр күбрәк кешегә ирешәчәгенә өмет бар.

– Кайчандыр сез телевидение белән генә шөгыльләнә идегез...

– Булды андый вакытлар, тик шактый күптән иде. Хәзер инде башка процесслардан да хәбәрдармын. Татарстан Президентының матбугат хезмәтендә узган ун елда төрле юнәлешләр белән эш йөртергә туры килде. Шуңа күрә басма матбугат, радио, телевидение, интернет технологияләрен дә, башкаларныкын да өйрәндем...

ҮЗЕБЕЗНЕКЕЛӘР ҺӘМ БАШКАЛАР

– Башка матбугат чараларына мөнәсәбәтегез ничегрәк? «Татмедиа» составына керми торганнар турында сүзем. Дәүләтнеке булмаган матбугатта сүз ирегә күбрәк дигән фикер яши...

– Үз эшләрен профессиональ югарылыкта алып барган барлык матбугат чараларына да яхшы мөнәсәбәттәмен. Матбугатта нормаль тәнкыйть бар икән, аны дөрес аңларга һәм моңа тиешенчә җавап бирергә кирәк. Әмма теге яки бу тема үзләре өчен мөһим булмаса да, ачуларын чәчәр өчен генә тәнкыйть яудырганнарны хөрмәт итмим. Компьютер каршына утырып, уңга-сулга аноним комментарийлар язып, һәркемгә пычрак коеп утырудан да җайлырак нәрсә юк. Ә ниндидер игелекле, файдалы гамәл кылырга дигәндә – андый кешеләр гадәттә җитеп бетми шул. Миңа бит Президент Аппаратының ничек эшләгәнен күрергә насыйп булды. Җитәкченең нормаль хезмәтен тәэмин итү өчен, бу кешеләр әллә ни зур булмаган акчага хәтта тәүлек буе да эшли. Менә башта шулай эшләп карагыз! Шуңа күрә чын профессионал авызыннан яки шушы өлкәдә утны-суны кичеп, аның боткасында кайнаган кеше

АНДРЕЙ КУЗЬМИННАН БЕР КИҢӘШ:

– Кулинариядәге иң төп киңәшем – аш-су эшендә оста хатынга өйләнегез. Ашарга пешерүе ташка үлчим генә икән, тәмле итеп пешерергә өйрәтегез. Яки башка хатын табыгыз.

PRESSA.RU

Бәрәңгедән гаҗәеп матур нәрсә килеп чыга!

тарафыннан әйтелгән тәнкыйтьне генә кабул итәм.

«Ботка»дан әкрен генә үзебезнең солянкага күчәбез. Ә аңа бәрәңге салып, көч биреп җибәрү кирәк. Бәрәңгене рядовой Андрей Кузьмин армиядә хезмәт иткәндә әрчергә өйрәнгән.

– Бөтен ротага җитәрлек итеп әрчи алам! – дип вәгъдә бирә. Үзе шул арада бәрәңге кабыгын бизәкле спираль рәвешендә бөтереп, күпләр яратмаган бу эшне ничек кызыклы итәргә мөмкинлеген күрсәтергә өлгерә. Бәрәңгедән гаҗәеп матур нәрсә килеп чыга бит!

ШАТЛЫГЫМ ДА, КАЙГЫМ ДА

– «Татмедиа»да сез үзегез яраткан матбугат чарасы бармы? Журнал? Телеканал? Сайт?

– Яратканы юк. Алар миңа барысы да балаларым, кошчыкларым кебек. Алар минем шатлыгым да, кайгым да. Мин үзем дә, башка күп кенә журналистлар кебек, «Эфир» исемле туган оядан канат чыгарган зат. Бүген исә Андрей Парамонович Григорьев белән бергә уртак проектны тормышка ашыра алуыбызга бик шат. «Татарстан 24» дип аталган бу проект республика буйлап зур-зур адымнар белән алга бара инде. Ул үз аудиториясен яулап килә. Анда яхшы команда җыелды, һөнәри яктан ныгырга да өлгерделәр. Бу проектны соңгы вакытта телевидение тармагында килеп туган хәлдән чыгу өчен уңышлы адым дип саныйм. Беләсезме, хәзер мультиплекс белән бәйле никадәр зур кыенлыклар пәйда булды... Төбәк каналларының күбесе тапшырулар дулкыннан төшеп калырга мөмкин. Кабельдән үзәк каналлар үзгәрешсез киләчәк. Ә элек бездәге телекомпанияләр төрле федераль каналлар белән килешү төзеп, үз тапшыруларын шушы канал тапшырулары арасына кертә, шунда үзләре рекламаны куя иде. Хәзер исә бу эш тыелган, беренче исемлектәге 20 канал тапшырулары «чиста» килеш, җирле өстәмәләрсез күрсәтеләчәк. Калганнар исә йә тәүлек буе үз тапшыруларын тәкъдим итәргә тиеш, ә бу һич тә кечкенә телестанцияләр кулыннан килә торган нәрсә түгел, яисә 50 нчеме, 60 нчымы төймәдә урын алырга мәҗбүр булачак. Аларга исә тамашачы һичкайчан барып җитмәячәк. Яки инде бу телеканалларга ябылу куркынычы яный. Һәм, мөгаен, ябылырлар да, илдә бу процесс бара инде. Мондый хәлдән чыгу юлы буларак, ел ярым элек без «Татарстан 24» каналын уйлап таптык. Ул бездәге муниципаль каналлар өчен коткаручы булды, һәм бүген телеканалларыбыз «Татарстан 24» проектының партнеры хисапланып, эшләрен уңышлы дәвам итә. Яңалыклар челтәрендә бер тапшыруны да кыскартмадык. Тапшырулар татар һәм рус телләрендә чыгып килә.

АКЫЛЛЫ, ИГЕЛЕКЛЕ ГАМӘЛЛӘР, МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР ТУРЫНДА

Шулпадан судак кисәкләрен алып, бәрәңге салабыз, ә аннары яшелчәләрне майда кыздыру эшенә керешәбез. Суган, кишер, кыяр, томат пастасын бер-бер артлы табага салып, тәмам пешеп йомшарганчы болгата-болгата 10-15-20... минут кыздырабыз.

– «Татмедиа» карамагындагы матбугат чараларына эшкә килүче яшь журналистларны һөнәри әзерләү системасына нинди бәя бирәсез?

– Гомумән алганда, үземнең журналистлык белемем юк. Мөгаен,

1. Кискәлибез!

2. Пешерәбез!

3. Әрчибез!

4. Ваклыйбыз!

5. Вак итеп турыйбыз!

7. Буләбез!

8. Салабыз!

9. Изелгәнче кыздырабыз!

10. Болгатабыз!

11. Бизибез!

мин күбрәк блогерларга тартымдыр. Хәер, блогер, минемчә, шул ук журналист ул. Тик блогерларның бөтенесе дә бу өлкәдә белем алган кеше түгел. Журналистика күп очракта белем түгел, ә сәләт, омтылыш дип саныйм мин.

– Димәк, сезнеңчә, «ни күрәм, шуны язам» ул журналистика булып чыга?

– Язу эшен дә төрлечә башкарып була бит. Матур, әдәби тел белән, чынбарлыктагыча язарга мөмкин. Шул ук вакытта һәрнәрсәгә пычрак атып, агу чәчәргә дә була. Һәм син барыбер үз укучыңны табасың, чөнки кешеләр пычракта казынырга ярата, ни кызганыч, адәм баласының табигате шундый. Телевизион рейтингларны тәэмин итә торган өчлек кагыйдәсе каян килеп чыкканына аптырыйсы юк. «Куркыту, секс һәм гауга». Менә шушы өч нәрсә күпчелек халыкның аңын яулап алган, менә шулар рейтинг ясый да. Медиаметрикс топларына күз салыгыз: хәбәрләр арасында иң популярлар рәтенә кайсылары чыга? Бер хәйриячеңең ятимнәр йортына машина бүләк итүе турында түгел, әйтик, ниндидер маньякның кемнедер көчләве, үтерүе йә талавы турында яңалык топ-хәбәрләргә эләгә.

– Моңа яраклашу, шундый хәбәрләр бирә торганнарга охшарга тырышу кирәкме соң?

– Охшарга тырышырга кирәк дип әйтмим. Мин кешенең хәбәрне кабул итү принциплары турында сөйлим. Дәүләт карамагындагы матбугат чараларының бурычы – үз контентларын кешеләрне мавыктырырлык дәрәҗәдә шулкадәр яхшы итеп әзерләү: акыллы, игелекле, мәңгелек кыйммәтләр дә, теге искә алынган «куркыту, секс, гауга» кебек, аңнарга үтеп керсен, халыкта кызыксыну уятсын. Без менә шуның белән шөгыльләнәбез дә. Яхшы хәбәрләргә игътибар биреп, шуларны сыйфатлы итеп әзерләргә тырышабыз...

– Шәп судак балыгы, яшелчәләр алып, тәмле балык солянкасын бик сыйфатлы итеп пешерергә тырышабыз...

– Нәкъ шулай! – Андрей Владимирович майда кыздырылган катнашманы шулпага сала. Ашыбыз матур кишер төсенә керә һәм бүлмәгә искиткеч хуш ис тарала. Эш ахырына якынлаша кебек.

ТӨРЛЕДӘН ТӨРЛЕ ПРОФЕССИОНАЛЛАР

– Сезнең кул астында – республикакүләм, шәһәр, районкүләм 98 басма газета, 15 журнал, 17 телеканал, 11 радиоканал, 87 сайт, мәгълүмат агентлыгы... Саный-саный буталып та бетәргә мөмкин. Алар республиканың төрле почмакларында урнашкан, телевизион һәм радиосигналлар тапшыру мөмкинлеге, колачлыгы да, редакцияләрнең техник яктан җиһазландырылуы да төрле дәрәҗәдә, кешеләренең холыклары, һөнәри осталыгы да бик аерыла... Шулкадәр зур, бик төрле коллектив белән ничек идарә итәсез?

– Миңа «Татмедиа»да эшләү читен түгел, чөнки хезмәттәшләрем – үз эшләренең чын осталары. Заманнар гына үзгәрде. Әгәр без элек акча санауга бик игътибар бирмәгән булсак, хәзер исә һәр тиенне экономияләргә туры килә, һәр редакция өчен бик анык бизнес-модель алдан тирәнтен уйланыла, һәр филиал елга ике тапкыр бюджетын яклау, дәлилләү өчен монда килә, һәм без җитәкче кешегә, башка бурычлар белән беррәттән, акча эшләү бурычы да йөклибез. Ә моны исә популярлыкны саклап калып, заманча технологияләр кулланганда гына тормышка ашырып була. Синең кул астындагы мәгълүмат чарасы никадәр популяр булса, реклама бирүчеләрне шулкадәр күбрәк кызыксындырасың, акча да шулкадәр күбрәк килә. Димәк, хезмәткәрләреңә дә яхшырак түләргә, заманча техника сатып алырга һәм башкаларга мөмкинлегең була. «Татмедиа» филиаллары арасында үз чыгымнарын тулысынча тәэмин итеп яшәүчеләр бар. Ләкин, кызганыч, кайберләре белән финанс мәсьәләсендә эшләргә кирәк әле. Шулай да мин финанслар һәм керем алу – төп бурыч дип әйтмим. «Татмедиа»ның төп максаты, фи-

6. Уабыз!

12. Теләкләр юллыйбыз!



PRESSA.RU

керемчә, республика тормышын чагылдыра, президентның ни белән шөгыльләнүен аңлата торган контент, барлык икътисадый һәм башка яңалыкларны халкыбызга җиткерү эшендә хөкүмәтебезгә ярдәм итәрлек контент булдыру. Кешеләр икътисадый реформаларда партнер буларак катнашып, нәтиҗәдә, үз тормышларын, якыннарының көнкүрешләрен үзләре дә яхшыртсын өчен кирәк бу. Менә шуны мин иң төп бурычларның берсе дип саныйм да. Тәнкыйть яудыру, пычрак ату түгел, ә анык һәм ачык аңлату. Кешеләрне юләр күтүе дип санарга кирәкми. Алар республиканың ничек үзгәрүен, президентның ничек эшләгәнен бик яхшы аңлый, күрә. Алар Казанның 15–20 ел элек нинди булганын хәтерли. Менә шушы кыска гена вакыт эчендә Казанны заманча, алдынгы төбәккә әйләндерә алдык. Бу бик күпләр тарафыннан югары бәяләнә. Хәзерге Казанга күз салыгыз! Әнә, туристлар агымы нинди… Илкүләм, дөньякүләм масштабтагы никадәр бәйгеләр, җыеннар уза. Конгресслар, съездлар, фестивальләр… Болар бит барысы да күренеп тора! Шуларның барысына да бездән өйрәнү өчен күпме кеше килә.

ЯРАТКАН УРЫН. АВЫР СЫНАУ

– Казанда яраткан урыныгыз бармы?

– Казанымны һәм эшемне бик яратам. Эш урынымда булу аеруча ошый, «Татмедиа» бинасын бик шәп урын дип саныйм. Монда – Казан күренешенең иң матур җирләреннән берсе

– Ә Кремль нәрсә?

– Кремльдән Кремль күренми ул. Ә ул – Казанның төп энҗесе. Мин аны, архитектура, тарих, эстетика күзлегеннән караганда, иң яхшы урын дип атар идем. Һәм аңа «Татмедиа» тәрәзәләреннән карап соклану күпкә шәбрәк.

– Тормышыгыздагы иң авыр сынау кайчан узды? Булдымы андый нәрсә?

– Авыр чорларның берсе – телевидениедән китеп, дусларым белән бизнеска керешүебез булды. Ул чакта без «Шүрәле» паркын төзедек.

– Менә кем ясаган икән аны!

– Мин проектның генераль директоры һәм җитәкчесе идем. Ике ел эчендә шушы парк өчен проект булдырып, акча табып, буш урында, сазлыкта аны төзеп, эшләтеп җибәрү ничек кулыбыздан килгәндер – бу вакытны мин тормышымдагы иң авыр чорларның берсе дип саныйм. Бөтенләй башка өлкәләргә кереп чумарга туры килде. Туфракны аска төшерү нәрсә ул, субайлар нәрсә ул, аларны төзелеш объектларында ничек кулланалар – боларны һич белми идем. Тик барысын да өйрәндем. Без ул вакытта зурлыгы буенча Россиядә өченче урында булган күзәтү тәгәрмәче проектын эшләдек. Аның нигезенә 700 субай сугылган һәм 20х30 метр зурлыгындагы бетон тартма салынган. Монда күпкатлы йорт куйсаң да, һич куркынычсыз басып торачак. Мин төзелеш тармагына караган дипломым булмаган хәлдә, бу проектны төрле инстанцияләрдә якладым. Һәрнәрсәгә эш барышында өйрәнергә туры килде. Шул күзәтү тәгәрмәчен бастырып кую өчен, миңа 400 тонна куәтле өч кран юнәтергә кирәк булды. Ә алар бөтен республикага дүртәү генә иде. Шул краннарны бер вакытка, бер урынга җыеп, тәгәрмәчне күтәртү, монтажлау бик җитди сынау булды. Ләкин без җиңеп чыктык. Минтимер Шәрипович ачылыш тантанасында тасманы кисте, без бергәләп агачлар утырттык. Ленин дамбасы буйлап барганда, әлеге паркка карап горурлык хисләрен тоям. Бу шәһәрдә мин телевизор экраннарында гына сөйләп калмыйча, үз кулларым, нервларым, тырышлыгым белән нәрсәдер эшләгәнмен диган сүз бит. Кала халкы ял итсен өчен, рәхәт тә, матур да урын ясадым. Бу хис-тойгы мине йөрәктән гел җылытып тора.

БИК БОРЫЧЛЫ ДА, АРТЫК КЫЗГАН ДА БУЛМАСЫН

Тәлинкәләргә солянка бүлеп, аңа яшел суган сибеп, «татарстанлылар»ның аны нинди тизлектә ялт иттереп куюын күргәч, Андрей Кузьмин авыр сулап куя:

– Их, юкка гына бу солянкага алындым ахрысы! Хатыным белеп алса, ашарга пешерә белгәнеңне яшереп, ничә ел кыланып йөргәнсең дип, бу солянканы өйдә дә әзерләргә кушачак.

– Ә теге «мамонт» мәсьәләсе ничек соң?

– Ул чакта «мамонт» тотылмый кала инде. Балык тоту – тормышымның бер бизәге. Ял көннәрендә дуслар белән бергәләп барырга тырышабыз. Шәһәрдә яшибез, офисларда эшлибез, фатирга кайтабыз… Ә балыкка бару, аеруча Кама Тамагы яки Иделгә юл тотканда, шундый иркенлек, күзләргә рәхәтлек бирә. Бездә искиткеч матур урыннар бар! Бу шулкадәр хозурлык, күңел өчен ял, янәдән-янә кире шунда кайтасы килә. Озак вакыт һичкая бармый торсам, хәтта юксына да башлыйм.

– Шушы яшегезгә кадәр Идел-Чулман суларыннан күпме балык тотарга өлгердегез?

– Һай, белмим. Без браконьерлар түгел, үзебез өчен генә, дуслар өчен генә тотабыз.

– Ә үзегез нинди балыкны яратарак төшәсез: кыздырганнымы, пешкәненме, киптергәннеме?

– Балык ризыкларына бер дә исем китми. Яраткан ашамлыкларым исәбендә түгел ул. Минем өчен ризыкның тәмле һәм сыйфатлы итеп әзерләнгән булуы мөһим. Бик борычлы да, артык кыздырылган да булмасын.

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

Реклама 16+

Безнең Инстаграмда –
«Татарстан»ның йөрәге!

PRESSA.RU

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

2018 елның I яртыеллыгына

«Татарстан» журналына язылу дәвам итә

П 2381 **татар телендә** 900 сум 00 тиен

П 2378 **рус телендә** 900 сум 00 тиен

Реклама 16+

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Уңыш сере **НИДӘ**

Торакка бәяләр **НИЧЕК** үзгәрәчәк

Казанда элемтәче һәйкәленең прообразы **КЕМ**

PRESSA.RU



«КЫРЛАРЫМ-ТУГАЙЛАРЫМ», ЯКИ УҢЫШ СЕРЕ НӘРСӘДӘ?

Чебешләрне көзен саныйлар. Татарстан игенчеләре, соңгы биш ел белән чагыштырганда, рекордлы уңыш җыеп алды: быел барлыгы 5,01 млн тонна ашлык суктырылган. Аерым районда гектарына 49,9 центнер уңыш чыкса, кайбер районда бу сан 23 центнерны тәшкил итә. Сәбәп нәрсәдә? Югыйсә шул ук Татарстан бит. Игенчелек буенча алдынгы һәм арттарак калган районнар тәҗрибәсен өйрәндек.

Автор:
Руфия Фазылова

«АВЫЛ ХУҖАСЫЗ КАЛДЫ»

ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгыннан алынган мәгълүматларны карап утырам. Иң зур уңыш буалыларда, җәмгысе 200 мең тонна икмәк җыеп алганнар. Зәй районында – 190 мең тонна, сарманлыларның уңышы – 189 мең тонна, Арча районында – 175 мең тонна. Ә менә күләм ягыннан, зәйлеләр беренче урында. Биредә гектарыннан 49,9 центнер иген җыеп алынган. Нурлат районында бу күрсәткеч 46,1 центнерны тәшкил итә, Сарманда - 44, Кукмара белән Тәтештә - 40шар центнер.

Начармы бу, яхшымы? Әйбәт, дияргә кирәктер. Россиядә иген уңышы буенча беренче урында барган Краснодар краенда уртача уңыш – гектардан 63 центнер. Һәм аның 85 проценты югары сортлы. Әлбәттә, Татарстан белән Көньяк өлкәләрне чагыштырып булмый, климат башка, җирнең уңдырышлылыгы бүтән. Ә менә иң түбән күрсәткеч биргән Югары Ослан, Кама Тамагы районнары (гектарына 23, 25 центнер иген чыккан) үзләренең «рекордларын» ничек аңлата соң?

– Районда уңышның түбән булуына сәбәпләр берничә, – дип сөйләде Кама Тамагы районының авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы Илфат Вәлиев. – Республика районнары арасында иң аз техника бездә. Өстәвенә, алар яңа да түгел. Мисал өчен барлык техниканы җыеп исәпләсәң, 93 ат көче була. Шул ук күрше Апас районында бу сан ике тапкырга артык. Көрәк булмаса, җирне эшкәртеп буламы? Юк. Безнең очракта да шулай. Икенче сәбәп: минераль ашламалар кертүнең дә, башка районнар белән чагыштырганда, иң азы бездә, гектарына –1,34 кг. Заманасы шул бит, ашламаларсыз гына югары уңышка ирешеп булмый.

Илфат Вәлиевнең сүзенә өстәп шуны әйтәсем килә: Россиядә бер гектар җиргә уртача 33 кг минераль ашлама кертелә. Мисал өчен, бодай үстерү буенча беренче урынны алып торган Кытайда бу сан бер гектарга 360 кг туры килә икән. Польша, Германиядә – 200 кг, Индия, Бразилиядә – 170 кг. Димәк ки,

Фото: Солтан Исхаков.

без иң экологик чиста ипи ашыйбыз булып чыга.

Сүз башы бит Шүрәле, дигәндәй, Кама Тамагы районында иген уңышсызлыгының сәбәпләренә килик. Биредә тагын өченче проблема да бар икән – эшче көчләр җитми.

– Безнең районда 15 мең кеше яши, – дип сөйләде районның авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы Илфат Вәлиев. – Чагыштыру өчен: күрше Кайбыч районында да шулкадәр халык яши. Бездә игенчелек, авыл хуҗалыгы тармагында бер мең кеше хезмәт куйса, аларда – җиде мең.

– Сәбәп нидә? – дим.

– Беренчедән, Кама Тамагында авыл хуҗалыгы белгечләрен әзерли торган училище юк. Гомер-гомергә, начаррак укучы балалар районда белем алды, аннан авылда төпләнеп калды. Хәзер, уку йорты булмагач, Казанга китәләр. Гадәттә, шәһәргә бер киткән егет-кызлар кире авылга әйләнеп кайтмый инде. Ә төп сәбәп – эшләгән кешегә дә акча түләнми. Аена 15–20 мең дә хезмәт хакы алмагач, ир кеше ник эшләп йөрсен?! Әле анысын да айныкын айга бирмиләр бит. Шуңа башка эш карый. Безнең район Казанга йөз чакрым ераклыкта урнашкан, йөреп эшләүчеләр шактый.

Кама Тамагы районында җирләр инвесторлар кулында. Ике агрофирма бар: «Ак Барс» һәм «Кызыл Шәрык». Беренчесе – иң зурысы. Техника, ашлама белән бәйле проблемалар да «Ак Барс» ширкәтендә күбрәк икән. Биредә ел саен җитәкчеләр алмашынган, бу да эшнең нәтиҗәлелегенә йогынты ясамый калмагандыр.

– Колхозлар беткәч, авыл хуҗасыз калды, – диде Илфат Вәлиев. – Бер җитәкчегә меңәр гектар җир туры килә. Ул аны ничек карап, контрольгә алып бетерсен? Бу мөмкин эш түгел!

PRESSA.RU

Районның сөрүлек җирләре 30 мең гектар икән. Октябрь башына әле шуның 7 мең гектарын гына эшкәрткәннәр. Җитәкче борчылуын яшермәде:

– Бер ай вакыт калып бара, ашыгырга кирәк, – диде Илфат әфәнде. – Тик, әйткәнемчә, техника да, механизаторлар да җитәрлек түгел. Бер тракторчы тәүлек буе эшли алмый, ә алмашка кеше юк. Безнең проблемаларны ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында беләләр. Рәхмәт, Марат Готыфовичка, сукалар юк иде, бирде. Чәчкечләр дә алып кайттык. Илле еллык техника белән әллә ни зур нәтиҗәләргә ирешеп булмый.

«ЭШНЕҢ ТӘРТИБЕН БЕЛӘБЕЗ...»

Кама Тамагы районы белән аңлашылды. Уңышсызлыкның сәбәбе – техниканың юклыгында, ашлама алырга акча булмауда, кадрларның җитмәвендә. Инде республикада иң зур нәтиҗә күрсәткән Зәй районына килик. Биредә аерым җирләрдән гектарына 70 центнер уңыш алганнар. «Краснодар краен да уздырдык», – диделәр, уенын-чынын кушып. Районда әлегә кадәр мондый рекорд куелмаган.

– Яз соң килеп, аннан тоташ яңгырлар игенчеләрне куркытып алса да, барысы да яхшы булды, – дип сөйләде Зәй районы авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы Рөстәм Мәүләвиев. – Чәчүгә 19 апрельдә керештек. Ике атна эчендә эшне бетердек. «Чананы җәйдән, арбаны кыштан» әзерлә дигән гыйбарәгә таянып эшләдек. Ягулык, ашлама, чәчүлек орлыкларын яңа елга кадәр әзерләп куйдык. Быел да шулай эшләргә исәп.

Зәй районында дүрт зур агрофирма эшли икән: «Зәй», «Зәй-Сахар», «Восток», «Нива». Нигездә, җирләр алар кулында. Дөрес, аерым фермерлар да бар, алар карамагында – район сөрү җирләренең якынча 10 проценты. Рөстәм әфәнде рекордлы иген уңышының бер серен менә нәрсәдә күрә:

– Безнең Зәй районында 74 мең гектар сөрү җирләре бар, шуның 10 мең гектарын пар җирләре итеп калдырабыз. Анда өченче ел рәттән горчица чәчәбез. Бу үлән җирнең уңдырышлылыгын әллә ничә тапкырга арттыра. Мисал өчен, узган ел горчица үскән җиргә көзге бодай чәчкән идек. Шуннан гектарына 70 центнер уңыш алдык. Татарстан өчен бу бик зур күрсәткеч. Безнең республика игенчелек өчен хәтәр зона булып санала. Һава шартлары йә яңгырлы, йә коры була. Шуңа да карамастан, яхшы уңыш алырга өйрәнергә кирәк. Аның бер юлы – горчица утыртып җирне ял иттерү. Татарстанда бу тәҗрибә берничә ел кулланыла инде. Ләкин Зәй районындагы кебек меңәр гектарга утыртылмый. Горчица үстерү ашламалар сатып алганга караганда арзангарак төшә. Экологик яктан да күпкә зыянсыз. Җиргә өстәмә ашлама кертсәң булмый. Шуңа күрә алга таба да бу юнәлештә эшләрбез дип торам. Шулай ук ашлама кертү дә уңыш юлының бер алымы булып тора. Район кырларына бер гектарга 130 кг ашлама кертелде. ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы: «Кимендә гектарына 65 кг ашлама кертергә», – дигән күрсәтмә биргән иде. Без моны ике тапкырга арттырып үтәдек.

Зәй районында техника белән проблема юк икән. Игенченең һәр көне ел туйдырганын биредә яхшы аңлыйлар. Көзге урып-җыю чорында агрофирмалар читтән кыныклап чит ил комбайнын арендага алып торган. (Шуның белән шөгыльләнүче махсус оешмалар бар бит). Шуңа да уңышны югалтуларсыз җыеп алганнар. Бүген 74 мең сөрүлек җирләренең 90 проценты инде эшкәртелгән.

– Акчасын түләгәч кешенең эшлисе килеп тора, – дип сөйләде Рөстәм Мәүләвиев. – Эшче халыкның (механизаторлардан тыш ферма хезмәткәрләре) уртача хезмәт хакы – 22 мең сум. Әлбәттә, комбайнчы, тракторчылар сезон вакытында акча күп ала. Агрофирмалар хезмәт хакын, авансны да кертеп, айныкын айга биреп бара. Моны район җитәкчелеге дә контрольдә тота. Район нигездә игенчелек, терлекчелек хисабына яши бит.

Зәйлеләр үзләренең быелгы уңышлары белән сөенүләрен яшерми. Республика өчен генә түгел, үзләре өчен дә рекорд бит,

Фото: Александр Эшкинин, Солтан Исхаков, Андрей Титов.

уңыш узган елгы белән чагыштырганда 25 процентка артык!

– Шуның белән бергә, җаваплылык та өсти бу, – ди Рөстәм Мәүләвиев. – Киләсе елгыныкын быелгы уңыш белән чагыштырып карыйсы була. Димәк, быелгы нәтиҗәдән төшәргә ярамый. Һәм төшмәбез дә дип ышанам. Эшнең тәртибен беләбез. Шул ук ашламаны да вакытында дөрес кертмәсәң, файдасы булмый. Син анда хет тонналап керт. Соңга калсаң, файдасы барыбер булмаячак. Монда чынлап та белгеч булырга кирәк. Җир эшендә очраклы кешеләр эшләргә тиеш түгел...

«ЧИТ ИЛЛӘР БЕЛӘН ЧАГЫШТЫРЫРГА ЯРАМЫЙ»

Россиядә революциягә кадәр иген уңышы гектарыннан 7–8 центнер булган. Чагыштыру өчен, Татарстанда быел бөртеклеләрнең уртача уңышы гектарыннан 31,7 центнер тәшкил итте. Күргәнебезчә, йөз ел эчендә уңыш 4–5 тапкырга арткан. Шулай да безнең шартларда Кытай яки игенчелек буенча алга киткән башка илләрне куып тотып буламы? Бу хакта Татарстанның авыл хуҗалыгы-тикшеренү институты директоры МарсельТаһиров белән сөйләштек. Алар 15 культура буенча селекция эше алып бара.

– Гомумән, Россия белән Кытай, Бразилияне чагыштырырга ярамый, – диде Марсель Таһиров. – Беренчедән, алар иген уңышын елга ике тапкыр җыялар, икенчедән, ашлама бик күп кулланалар. Гомумән алганда, иген уңышының 50 проценты минераль ашламалардан тора. Аннан күп нәрсә җирнең уңдырышлылыгы, төре, эшкәртүгә бәйле.

Татарстан авыл хуҗалыгы-тикшеренү институтының махсус тәҗрибә җирләре бар. Ул Лаеш районы Олы Кабан авылында урнашкан. Анда яңа уйлап табылган сортларны безнең шартларга ни дәрәҗәдә яраклаша алуын сыныйлар.

– Быел безнең тәҗрибә җирләрендә бөртекле культураларның уңышы гектарыннан 70–80 центнер чыкты, – дип сөйләде Татарстан авыл хуҗалыгы-тикшеренү институты директоры. – Иген үстерү буенча Россиянең алдынгы төбәге – Краснодар краеның уртача күрсәткеченнән дә югары. Тик, әлбәттә, бу әле шул орлыкны теләсә кайсы басуга утырттың да шулкадәр уңыш аласың дигән сүз түгел. Гектарыннан 70–80 центнер иген – бу яхшы шартларда, бөтен мөмкинлекләр тудырылган очракта. Максат – тәҗрибә участогында үскән орлыкларны республиканың барлык кырларында да үрчетү. Хәер, хуҗалыкларны югары җитештерүчән орлык белән тәэмин итү буенча да безнең республика Россиянең күп регионнарына үрнәк. Безнең галимнәр ел саен диярлек яңадан-яңа сортлар уйлап табу белән берррәттән, тагын республиканың 45 хуҗалыгында элиталы орлык җитештерәләр. Мондый мөмкинлекләр илнең сирәк регионына эләгә. Тик әлегә аларны файдалана белү генә җитми. Ә бу өлкәдә Татарстанның потенциалы бик зур.

...Әлбәттә, иген уңышы турында сөйләгәндә төрле факторларны исәпкә алырга кирәк: югары нәтиҗәләргә ирешкән хуҗалыклар күпме акча тоткан, хезмәт түккән... Тагын икенче як та бар: Балтач районының бер хуҗалык рәисе белән аралашып алдык. «Без быел иген уңышы буенча районда иң түбәннәр рәтендә, – диде ул. – Тик бу бөртекле культуралар начар уңыш бирде, дигән сүз түгел. Уңыш әйбәт. Алдагы елларда корылык булгач, быел эш тәртибен үзгәрткән идек: бөртеклеләргә караганда тамыразык культураларын күбрәк утырттык. Нәтиҗәдә, иген уңышы азрак күренә». Балтач хуҗалыгының тәҗрибәсеннән күренгәнчә, кайда отасыңны яки оттырасыңны белеп булмый. Хәер, нинди культурага өстенлек бирсәң дә, вакытында чәчеп, карап үстереп, соңармый уңышны җыеп алсаң, оттырмыйсың.

ФАКТ

Республика буенча бөртеклеләрнең уртача уңышы быел гектарыннан

31,7

центнерны тәшкил иткән.

Фотолар Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбеннән алынды

ҖИТӘКЧЕ **КЕЙСЫ**

Татарстан Республикасы Президенты күрсәтмәсе буенча һәм ТР Муниципаль берәмлекләре Советы ярдәмендә Казан федераль университетының Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбендә менә өченче ел инде авыл җирлекләре башлыкларының идарә өлкәсендәге һөнәри компетенцияләрен формалаштыруга һәм үстерүгә юнәлтелгән «Авыл җирлекләре башлыклары эшчәнлегенең актуаль мәсьәләләре» дигән квалификация күтәрү программасы гамәлгә кертелә.

Автор:
Ксения Сёмина

– Әйтегез әле, сез җирле карьердан чыгарылган вак ташны күрше республикада сатуга кагылган мисалга игътибар иттегезме? – дип сорый модератор алты кешелек төркемнән (программаның тыңлаучылары шундый биш «авыл җирлеге» командасына бүленгән).

– Ә аңа игътибар бирергә кирәкми дә бит. Бу очракта авыл җирлеге башлыгының гамәлләре дәлилле һәм законлы тоела, – дип җавап бирә тыңлаучыларның берсе.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгы вәкиле бәхәскә кушыла һәм бу очракта башлыкның гамәлләре ни өчен дөрес булмавын аңлата.

КАБЫРГАСЫ БЕЛӘН КУЕЛГАН СОРАУ

Авыл җирлекләре башлыклары үз эшләрендә көн саен очраша торган типик хәлләр җыелмасы командалар өч көн дәвамында чишкән кейсның нигезен тәшкил итә. Һәр тыңлаучының максаты – үзенең практик яки теоретик эш тәҗрибәсеннән файдаланып, проблеманы ачыклау һәм аны хәл итү юлын тәкъдим итү. Аның дөреслеген төбәк һәм федераль башкарма хакимият органнарыннан чакырылган экспертлар бәяли. Алар арасында республика министрлыклары, Роспотребнадзор, прокуратура, салым инспекциясе, ТР Президенты Аппараты вәкилләре бар. Кейстагы очракны тикшергәннән соң башлыклар экспертларга үзләренең көндәлек эшчәнлегенә кагылган сорауларны бирә.

– Программа авыл җирлекләре башлыкларының идарә өлкәсендәге компетенцияләрен үстерүгә юнәлтелгән. Авыл җирлеге башлыгы вазыйфасы – сайлап куела торган, ниндидер махсус белемле булу таләп ителми. Шуңлыктан авыл җирлеге башлыгының юридик, финанс, техник грамоталылыгы бары тик квалификация күтәрү процессында гына формалаша һәм камилләшә ала, – дип сөйли бизнес-тренер һәм программаның берничә блогы модераторы Яна Руднева. – Программаның нигезен кейс тәшкил итә, ул республиканың башлыклар даими хезмәттәшлек иткән министрлык һәм ведомстволары экспертлары тарафыннан эшләнгән. Программага барлыгы утыздан артык белгеч җәлеп ителгән. Укыту конкрет биремнәр үтәү һәм аларны тикшерүне генә түгел, бәлки башкарма хакимият органнары белән диалогны да күздә тота. Моннан тыш, мондый формат авыл җирлекләре башлыкларына уникаль мөмкинлек бирә – алар яшьрәк коллегалары белән тәҗрибә уртаклаша, аларны законсыз яки хаталы гамәлләр кылудан саклый.

Авыл җирлегенең үз хаҗәтләре өчен казылган карьердагы вак ташны күрше республикага сатарга ярыймы? Тиешле рөхсәттән башка урманда caберке сындырырга ярыймы? Авыл халкы су коена торган буада кош үрчетергә ярыймы? Авыл җирлеге территориясендәге елга аша салынган күперне карап тотуга акча кайсы бюджеттан – авыл җирлегенекеннәнме, республика яки федерациянекеннәнме – бүленергә тиеш? Авыл җирлеге җитәкчесе нәкъ менә шундый бурычларны хәл итү белән мәшгуль. Беренче чиратта аның гамәлләре законга каршы килмәскә тиеш.

КФУ Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбендә ТР муниципаль районнары авыл җирлекләре башлыклары өчен квалификация күтәрү программасы моннан өч ел элек башланган. Ул чакта анда тәүге 300 тыңлаучы катнашкан. Быел аның буенча тагын 300 башлыкны укыту планлаштырыла. 2018 елда программаны тагын 300 укучы үтәчәк һәм шул рәвешле ул республиканың бөтен авыл җирлекләре башлыкларын колачлаячак.

Реклама

– Без катнашучылар белән дә, экспертлар белән дә элемтәдә торабыз. Әлеге мәгълүмат нигезендә программа үзгәртелә, кайбер блоклар алып ташлана, ТР Муниципаль берәмлекләре Советы тәкъдиме белән башлыклар өчен файдалырак блоклар өстәлә. Мәсәлән, быел, булачак референдум һәм сайлауларга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе химаясендәге блок кертелгән. Бюджет формалаштыру һәм сатып алу эшчәнлегенә бәйле сораулар өстәлгән. Моннан тыш, без материалны тапшыру формасы белән дә эшлибез, – ди Яна Руднева. – Әгәр былтыр барлык командалар бер кейсны чишсә, быел һәр төркем өчен аерым ситуацияләр тупланды. Бөтен кеше дә активлык күрсәтергә һәм сораулар бирергә яратмый, шуңа күрә без закон буенча авыл җирлекләре җаваплылыгы зонасына кертелгән мөмкин кадәр күбрәк сорауларны колачларга тырыштык. Шул рәвешле, хәтта экспертлар белән аралашканда актив катнашмаучылар да кирәкле барлык белемне дә алачак. Программа аттестация эше белән тәгәлләнә. Быел һәр төркем Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советының декабрьдә булачак съездында тикшерү өчен тәкъдимнәр исемлеген төзи.

БЮДЖЕТ ТЫЙНАК, МАКСАТЛАР ЗУР

– Минем янымa пенсионерлар килә дә, Путинның тагын хакимияттә калуын үтенәләр. Алар минем кая да булса шулай мөрәҗәгать итәрлек вәкаләтем бар, дип уйлый. Бередәге укуда 2018 елгы РФ Президентын сайлауга багышланган тулы бер блок булды. Шунлыктан мин безнең әби-бабайларга бөтен процедураны аңлатып бирә алачакмын, – дип сөйли Татарстанның Чүпрәле районы Үби авыл җирлеге башлыгы Алексей Ерохин. – Шулай ук булачак референдумнар турында мәгълүмат та бик файдалы булды. Кайбер башлыклар, бигрәк тә яңа сайланганнары, үзара салымнан баш тарта. Ә бит юкка! Ул үз көченә кергәннән бирле без үзебезнең берничә

Алексей Елохин, ТР Чүпрәле районы Үби авылы җирлеге башлыгы

чакрым юлга асфальт салдык. Хәзер безгә элеккеге кебек коры вакытта гына түгел, бәлки теләсә кайсы вакытта килеп була. Юл билгеләре куйдык, урамнарны яктырттык. Киләсе елга республика су кертүдә булышырга вәгъдә бирде. Шунлыктан референдумда салымга җыелган акчаны су белән тәэмин итү системасын проектлау һәм төзүгә юнәлтү мәсьәләсен куячакбыз. Программа вакытында мин шул тәҗрибәм белән уртаклаша алдым.
Алексей Егорович семинардан өенә этноконфессиональ мөнәсәбәтләрне көйләүгә, радикализм, экстремизм һәм терроризм идеяләренә каршы торырга өйрәткән мәгълүмат һәм буклетлар да алып китәчәк. Әлеге блок, төгәлрәге, 10 сәгатьлек аерым семинар, ел программасына Татарстан Республикасы Президенты Аппараты тәкъдиме белән кертелгән. Башлыклар билгеләнгән тема буенча мәсьәләләр чишеп кенә калмыйча, үз авыл җирлекләрендә профилактика максатларында кулланырлык мәгълүмат та алган.
– Мин үзем өчен авыл җирлеге башлыкларының вәкаләтләренә кагылышлы темаларга күп яңалык ачтым. Сатып алуларга багышланган блок та актуаль булды. Быел ФАС бу юнәлештәге тикшерүләргә зур игътибар бирәчәк, шунлыктан хаталар ясарга ярамый, – ди Татарстанның Азнакай районы Әгерҗе авылы җирлеге башлыгы Назыйф Хәсәнов. – Һәм инде, әлбәттә, иң актуаль тема – бюджет. Минем профильле белемем юк, әмма мин халыкка аңлата белергә тиеш – без түләгән салым акчалары ничек бүленә, без үзебезнең җирлек салымнары хисабына нәрсә эшли алабыз, нәрсә эшли алмыйбыз. Ә моның өчен башта үзеңә барысын да аңларга кирәк. Минем өчен программа файдалы булды, әмма салымнар, бюджет һәм прокуратура шөгыльләнә торган сорауларга бәйле темалар буенча тагын да күбрәк мәгълүмат аласы килә. Мин әле киләчәктә мондый укуларда тагын катнашырмын, дип өметләнәм.

PRESSA.RU

Күчемсез милек базарындагы заманча тенденцияләр турында

ТОРМЫШ РӘВЕШЕ ЯИСӘ КВАДРАТ МЕТРЛАРМЫ?

Торакка бәяләр ничек булачак, ихтыяҗ һәм тәкъдим динамикасы ни хәлдә, ипотека кредиты буенча ставкалар кимемәячәкме? Сорауларга җавап табу йөзеннән «Татарстан» журналы әлеге өлкә белгечләрен түгәрәк өстәл артына җыйды. Фикер алышуларда Республика риелторлары гильдиясе, танылган төзүче компанияләр һәм абруйлы банкларның вәкилләре катнашты.

Фото: Александр Ефремов

Реклама

ТӨЗҮЧЕЛӘРДӘН – ЯҢА ПРОЕКТЛАР

Түгәрәк өстәлнең модераторы ролендә **«Мегалит» Күчемсез милек агентлыгы маркетологы Алина Миңлебаева** катнашты.

Бүгенге сатып алучы нинди торакка өстенлек бирә?

Антонина Дарчинова, «КамаСтройИнвест» компаниясенең коммерция директоры:

– Без шактый кызыклы сегментта эшлибез, нигездә – Казан үзәгендә. Монда җир кишәрлекләре кечкенә һәм проектларны гамәлгә ашыруга иҗади якын килергә туры килә. Шуңа күрә кызыклы, хәтта ки уникаль объектлар бездә бик күп. Бүген өч торак йорт һәм бер апартаментлар комплексы сатуда. Kalinina house ТК* төзелешен тәмамлыйбыз. Лядской бакчасы каршындагы Мөштәри урамында «акыллы» торак йорт төзелешендә заманча технологияләрне максимум кулланырга тырышабыз. Бу – натураль материаллар, корылманың экологик яктан югары дәрәҗәдә булуы. Төзелеш урыны үзе дә йортның гасырларга чыдарлык итеп салынуын таләп итә. Тагын компаниянең гомуми концепциясенә туры килеп бетми торган «Кызыл алма» торак йорты кебек проект турында әйтәсе килә. Без Казанның Авиатөзелеш районында үзенчәлекле архитектурага һәм уңайлы зур территориягә ия йорт төзедек. Яхшы килеп чыкты. Кулланучыга да ошады дип уйлыйм. Бүген барлык фатирлар да сатылып бетте диярлек.

Безнең клиент сайланучан һәм таләпчән. Гомумән, соңгы елларда сатып алучының уңайлылык турындагы күзаллаулары нык үзгәрде. Шуңа күрә без иң элек планлаштыруга зур игътибар бирәбез. Шәһәрдә күпләр дуслары белән кафеларда, рестораннарда очрашуны хуп күрә башлады, кунак бүлмәсен кухня белән берләштерү трендка әйләнде. Икенчедән, уңайлы мохит. Бу җәмәгать куллану урыннарына да кагыла. Алар уңайлы, бөтен кешене сыйдыра алырлык, актуаль һәм заманча булырга тиеш. Элеккеге кебек балалар мәйданчыгы бар икән, шул җиткән, дип фикер йөртмиләр. Хәзер шул ук балалар мәйданчыгы балаларны үстерә торган, куркынычсыз һәм кызыклы булсын. Балаларны да, олыларны да шатландыра торган.

Безнең компания архитектурага, шуңа ярашлы экологик таләпләргә дә зур игътибар бирә. Күчемсез милеккә инвестицион сорауның шактый кимүе сер түгел, үзе өчен фатир сатып алуга ихтыяҗ бар. Шуңа күрә бездә нигездә өч бүлмәле һәм ике бүлмәле фатирлар сатып алалар һәм соңгы исәптә генә бер бүлмәле фатир сорыйлар.

Реклама

* Калинина Хаус ТК.

Жилой Дом
ЛЕГАТО
207-29-80
Муштари, 18

Застройщик: ООО «КамаСтройИнвест», Проектная декларация на сайте: legato-dom.ru

Реклама

PRESSA.RU

Реклама

Елена Стрюкова, «Ак Барс Недвижимость» директоры:

– Без мәктәпләре, балалар бакчалары һәм кибетләре булган социаль юнәлешле комплекслар төзибез. Бүгенге көндә безнең тарафтан дүрт төп комплекс буенча сатулар бара. Бу «Казан XXI гасыр», «Якты үзән», «Кояшлы шәһәр» һәм яңа «Тулпар»* проектыбыз. Сыйфатны бәяләргә яратучылар өчен мөһим һәм бәхәссез аргумент: «Тулпар» ТК керамик кирпечтән салына. Бу экологик һәм озакка чыдый торган материал. Монда ял итү зонасы, күл янындагы барбекю, кафе һәм кибетләр өчен урыннар да бар. Перспективада тагын бер проект бар – ипподром районында торак комплексы төзелеше.

Бүген бер бүлмәле фатирларга сорауның шактый кимү тенденциясе күзәтелә. Клиентлар ике-өч бүлмәле фатирларны теләбрәк сатып алалар. Алар үзләре өчен фатир гына түгел, яшәү рәвеше дә сатып алалар. Кешеләр сайлаганда таләпчәнрәк була башладылар һәм фатирларның планлаштырылуына, урынына, инфраструктурасына зур игътибар бирәләр. Шул ук вакытта яңа төзелешләрдән фатир алганда ипотека кредиты кулланалар, бүген андый сатып алучылар якынча 60%.

Шуннан чыгып, без торак комплексы концепциясен формалаштыруга яңача якын килү ысулын таптык. Бүген без сатар өчен квадрат метрлар төземибез, ә тормыш итү өчен пространство булдыру юнәлешендә эшлибез. Комплексны проектларны төзү буенча күпьеллык тәҗрибәгә таянып, һәм шулай ук базар шартлары таләп иткән барлык тенденцияләрне исәпкә алып, якын араларда без торак комплексларына карата Казан өчен өр-яңа проектлар тәкъдим итәргә ниятлибез.

Андрей Савельев, ТР риелторлары гильдиясе:

– Мин яңа төзелеш базарының үз позицияләрен кайтара башлавы белән килешәм. Ихтимал, бу ипотекага ставкаларның кимүе белән аңлатыладыр. Төзүчеләр арасындагы сәламәт көндәшлек тә күпмедер дәрәҗәдә үзенекен эшлидер, дип уйлыйм. Клиентлар өчен көрәштә төзүчеләр даими рәвештә төрле акцияләр оештыралар. Әгәр ун ел элек төзүче бер гектар җирне парк өчен калдыра дисәләр, моны акылдан язуга санарлар иде. Ул урында өч йорт торгызып була бит! Сатып алучы да бөтенләй башка бүген, ул фатир алганда бик сайланучан. Элегрәк сатып алганда төп нәрсә бәя иде, калганнары – икенче планда. Хәзер без инфраструктурага, планлаштыруга, эргономикага карыйбыз. Шуңа күрә төзүчеләр үз сайтларында әзер фатир рәсемнәре урнаштыралар. Хәтта җиһазлар куелганнары да бар. Кер һәм яшә генә.

Эдуард Хәлимуллин, «Унистрой»ның сату бүлеге җитәкчесе:

– Яңа төзелгән һәм инде кеше яшәгән, «иске» фатирлар арасында көндәшлек һәрвакыт бар иде. Ләкин соңгы дистә елда ачыктан-ачык яңа тренд шәйләнә: кулланучының игътибары яңа төзелешкә юнәлтелгән. Бу нәрсәгә бәйле? Беренчедән, бүген клиентлар квадрат метрларга гына түгел, яшәү рәвеше өчен дә түлиләр. Безнең Татарстан Республикасы буенча портфельгә хәзерге вакытта өч проект салынган: «ART City», «Весна» һәм «Царёво Village»** торак комплекслары. Болар барысы да компания тарафыннан тормышка ашырыла торган төп стандартларга ия булган комплексны төзелеш проектлары. Без балалар бакчалары, мәктәпләре булган заманча инфраструктура гына формалаштырып калмыйбыз, бәлки парк зоналары, җәяүлеләр бульварлары, якында гына социаль инфраструктура объектлары да салабыз. Үзебезнең торак комплексларында без кешеләр өчен, машиналар булмаган ишегаллары концепциясен гамәлгә ашырабыз, хәрәкәт итүләре чикле кешеләр ихтыяҗларын күздә тотып, подъездга керү урыннарын уңайлы итеп ясыйбыз, җайлы, чаңгы, велосипед һ.б. ларны фатирда сакламас өчен, беренче катта махсус коляска кую бүлмәсе дә бар. Торак комплекс территориясендә видеокүзәтү системасы урнаштырабыз. Без бер урында тормыйбыз, перспективалы төзелеш өчен яңа җир кишәрлекләре табабыз. Якын елларда яңа проектларны эшләтеп җибәрергә ниятлибез.

* Төзүчеләр: «ИнтегСтрой» ЖЧҖ, проект декларациясе www.integstroi.ru сайтында; «Компроект» ЖЧҖ, проект декларациясе www.stroikomproekt.ru сайтында.

** Төзүчеләр: «Унистрой» ТК» ЖЧҖ, «СтройУслуги» ЖЧҖ, проект декларациясе www.unistroyrf.ru, www.unistroydom.com, www.stroy-uslugi.su сайтларында. Арт-Сити ТК һәм Царёво Виладж.

«АК БАРС НЕДВИЖИМОСТЬ»
КОМПАНИЯ ҮЗГӘРЕШЛӘРГӘ ӘЗЕР

Фото: «Ак Барс Недвижимость» ЖЧҖ

Бүгенге тормыш динамикасы үз шартларын үтәргә мәҗбүр итә. Без үсеш зур тизлек белән барган чорда яшибез. Кеше һәрвакыт алга таба омтыла, киләчәк буынның тормышын җиңеләйтә, аны җайлырак һәм уңайлырак итә ала торган нәрсәләрне уйлап табу һәм булдыру юнәлешендә даими эзләнә. Һәм «Ак Барс Недвижимость» компаниясе дә бер урында тормый: үсә, дөнья трендларын күзәтә, заман сулышын тоеп яшәргә тырыша. Без алгарыш юнәлешендә көчле сикереш ясыйбыз. Торак 2.0. – киләчәктә көтелгән торак йортлар нинди булачагы безгә билгеле. Яңа, перспективалы һәм кызыклы проектларны эшләтеп җибәрергә әзер. Компания белгечләре бүгенге кулланучыга нәрсә кирәклеген төгәл белә. Бүген сатып алучы таләпчәнрәк һәм кызыксынучанрак. Аның таләпчәнлеге девелопментны заманча прогрессив технологияләр кулланылган яңа проектлар уйлап табуга этәрә. Бүген фатирлы булу – уңайлылык зонасын сатып алу дигән сүз. Сатып алучы сайланучан һәм яшәү урынын җентекләп эзли. Аны аңларга була. Шуңа күрә клиент белән индивидуаль эшләү һәм, һичшиксез, профессионализм алгы планга чыга. Ә бу без сатып алучының үзгәрә барган теләкләренә җайлашырга тиешбез, дигән сүз. Икенче төрле әйткәндә, бу котылгысыз эволюция процессы. «Ак Барс Недвижимость» компаниясе үзгәрешләргә әзер.

Реклама

Оформляем документы за 5 дней

Принимаем все виды оплаты

Проживаете в старой квартире до 3-х месяцев

принимаем СТАРУЮ КВАРТИРУ в счет НОВОЙ

(843) 207 12 43

УНИСТРОИМ ГОРОДА

unistroyrf.ru

УНИСТРОЙ

* Застройщики: ООО «СК «УнистройДом», ООО «СтройУслуги». Проектная декларация размещена на сайте www.unistroyrf.ru, www.unistroydom.com, www.stroy-uslugi.su, копии проектных деклараций вы можете получить в офисах продаж по адресам: ул. А. Аббасова, 11 (офис продаж ЖК «Весна»), ул. Октябрьский городок, 1/24 (офис продаж ЖК «ART City»), ул. Гаврилова, 1, ул. Гвардейская,16 в. ** Для клиентов, желающих приобрести квартиры в строящихся домах, действует Trade in – программа приема вторичного жилья (объекта недвижимости) в оплату первичного жилья (участие в долевом строительстве) путем выкупа или реализации (продажи) объекта недвижимости. Условия выкупа. Объекты недвижимости приобретаются по рыночной стоимости за минусом дисконта. Дисконт – разница между рыночной ценой и ценой выкупа, определяется на основе алгоритма и не может превышать расходов, связанных с дальнейшей реализацией объекта. Рыночная стоимость определяется ответственным сотрудником по реализации программы «Trade in» совместно с квалифицированным специалистом по недвижимости, согласовывается комиссией, которая назначается по распоряжению директора отдела продаж компании. Объект недвижимости выкупается у клиента при условии: - дисконта 5% от рыночной цены при заключении договора купли-продажи; - одновременного заключения клиентом договора участия в долевом строительстве и договора купли - продажи с увеличенным сроком оплаты цены до 1 месяца. Условия реализации. Максимальный срок реализации объектов недвижимости не должен превышать трех календарных месяцев. Требования к реализуемому (выкупаемому) объекту: - не более двух собственников; - количество зарегистрированных лиц в объекте равно количеству собственников; - целостность объекта - отдельная квартира, продающаяся целиком, этажность – не менее 5-ти этажей. Всю подробная информация в офисах продаж и по тел. (843) 295 53 83.***Срок указан для подготовки документов к регистрации.Настоящее предложение не является публичной офертой.

Реклама

КҮЧЕМСЕЗ МИЛЕК САТУЧЫ ҺӘМ АЛУЧЫ АРАСЫНДАГЫ СЫЙФАТЛЫ ЭШ

Төзүче игълан иткән актуаль акцияләрдән һәм банк биргән ипотека кредитларыннан ничек дөрес файдаланырга?

Антонина Дарчинова: – Гомумән алганда, торакның сатылышына ипотека ставкаларының кимүе ярдәм итте. Мөгаен, акция буларак аны нәкъ менә банк бирәдер, без кайбер банклар белән субсидияләнгән ставкалар буенча эшлибез. Акция буларак, минемчә, бу бүгенге көндә иң үтемле механизм.

Андрей Савельев: – Әлеге очракта «КамаИнвестСтрой» шактый югары дәрәҗәдәге торак комплекслары тәкъдим итә, һәм ипотека сделкаларының ставкалары да югары түгел…

Антонина Дарчинова: – Мин, әйдәгез, начар продукт ясыйк та, аннан соң аны сатканда телевизор бүләк итик кебек ысуллар тарафдары түгел. Баштан ук планлаштыруга һәм сату бәясен куюга сыйфаты акчага туры килерлек итеп карарга кирәк, дип саныйм. Яхшы продуктны сату һәм кулланучы белән ачыктан-ачык сөйләшү алып бару күпкә җиңелрәк. Ә ниндидер өстәмә хезмәт күрсәтүләргә килгәндә, базар шулай үсә ки, тиздән без барыбыз да, фатирларны бизәү эшләре белән шөгыльләнеп, хәтта җиһазлары да урнаштырылган торак сата башлаячакбыз, дип уйлыйм. Продуктка кулланучы өчен файдалы сервисларны һәм хезмәт күрсәтүләрне торган саен күбрәк кертә барачакбыз.

Эдуард Хәлиуллин: – Без ай саен гамәлдәге акция шартларын төгәлләштерергә, үзгәртергә, фатир сатып алганда бонусларны төрлеләндерергә тырышабыз – сатып алган мәлдә һәркемгә иң кирәклесен тәкъдим итә алу өчен. Без акциянең мәгънәсен бәя төшерү, ташлама ясау буларак кабул итмибез, без ташламалар сатмыйбыз. Без кулланучыбызга мөмкинлекләр һәм өстенлекләр бирәбез. Хәзер, мәсәлән, «кредит каникуллары» игълан иттек. Клиентларыбыз ярты ел дәвамында ипотека кредитын түләмиләр. Алар өчен моны без эшлибез. Беренче чиратта, әлеге продукт иске торак белән яңа торак арасында сайланучы клиентларга юнәлдерелгән.

Фатир өчен 100% түләргә әзер клиентларга без төзелеш кибетенә сертификат бүләк итәбез. «Трейд-ин» программасы популярлык казана бара. Клиентның теләге буенча без аңа иске фатирын сатарга ярдәм итәбез яисә үзебез сатып алабыз.

Елена Стрюкова: – Ипотека күчемсез милек базарында төп инструментларның берсе булып кала бирә, һәм үз тәкъдимнәребезне формалаштырганда, без, әлбәттә, әлеге фактка таянабыз. Әйтик, компаниядә түбәндәге акция бара: ипотека өчен түләү көненә ике чынаяк кофе эчү бәясенә тиң. Икенче төрле әйткәндә, клиент эчемлектә экономия ясап, акчасын үз торагы фондына кертә бара ала.

Нил Паташин, «Газпромбанк»ның (Акционерлык җәмгыяте) Казан шәһәрендәге филиалының вак продуктлар сату бүлеге башлыгы:

– Бүген ипотека – торак сатып алуның иң кулай һәм нәтиҗәле ысулы. Әлеге тенденция Газпромбанкта ипотека кредиты үсешендә дә чагылыш таба. Без клиентларыбыз тарафыннан ипотекага карата кызыксынуның артуын ачык күрәбез – динамика бер ел элек булганга караганда 60%ка артыграк. Гомумән алганда Газпромбанкта күбрәк тотылган торак сатып алу күзәтелә, ләкин соңгы вакытта яңа төзелгән фатирларга сорауның үсүе дә үзен сиздерә. Бу юнәлештә без төп эре партнёрларыбыз – Казанда һәм республикада ышаныч казанган төзүчеләр белән хезмәттәшлек итәбез.

Бүгенге көндә ипотека кредитларын рефинанслауга ихтыяҗның шактый артуын да тоябыз, аның асылы шунда: банк заёмщикка элегрәк алынган ипотека кредитын каплар өчен 9,5% белән кредит бирә, бу исә кешегә ай саен түләнә торган акчаларны экономияләү мөмкинлеге бирә. Әлеге продуктның уңай ягы әле тагын шунда: кулланучылык һәм автокредитларны да өстәмә рәвештә рефинансларга була. Хәзер Газпромбанкта рефинанслау буенча иң кулай ставкаларның берсе гамәлдә булуын да билгеләп үтәргә кирәк.

Без иң эре банклар тарафыннан бирелгән тәкъдимнәргә чагыштырма анализ ясадык һәм торак сатып алырга җыенган кешеләргә киңәш бирә алабыз. Кредитор банкны һәм ипотека программасын сайлаганда, анонсланган процент ставкаларына гына түгел, ипотека кредитының мөһим шартларына да игътибар итәргә кирәк. Атап әйткәндә, бу – беренчел кертем, өстәмә тәэмин итү, иминиятләштерү, айлык түләүләрнең төре (дифференциацияләнгән яисә аннуитетлы) һ.б.ларга. Безгә алга таба клиентларыбызның кредитларына хезмәт күрсәтүнең максималь рәвештә уңайлы булуы да мөһим. Шул ук вакытта без һәр клиентка якын килүнең сыгылмалы булуын саклап калабыз һәм партнёр төзүчеләребез өчен махсус тәкъдимнәр эшлибез.

Ипотека акциясен үткәрү вакыты: 11.08.2017 – 30.12.2017. Максатчан билгеләнеше: төзелеп килүче торак йорттан фатир алу. Кредит ставкасы: 9,5%. Ставка заёмщик иминиятләштерү полисын/килешүен имзалаганда (ирекле рәвештә) гамәлдә. Кредит валютасы: РФ сумы. Кредитның минималь суммасы: 500 000 сум, ләкин күчемсез милек бәясенең 15%ыннан ким түгел. Кредитның максималь суммасы: 60 млн сум –Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләрендә объект сатып алганда; 45 млн сум – РФ башка субъектларында. Кредит срогы: 30 елга кадәр. Кредитны каплау: ай саен аннуитетлы яисә дифференциацияләнгән түләүләр аша. Кредитны өлешчә яисә тулысынча комиссияләрсез алдан ябу мөмкинлеге. Тәэмин ителешкә таләпләр: милек хокукы залогы (милек итеп рәсмиләштергәнгә кадәр) / кредит акчаларын кулланып күчемсез милек залогы (ипотека) (милек итеп рәсмиләштергәннән соң). Заёмщикка карата таләпләр: РФ гражданлыгы, 20 яшьтән 65 яшькә кадәрге яшь. Тулырак мәгълүмат www.gazprombank.ru сайтында һәм 8 800 100 07 01 тел. буенча. Мәгълүмат 11.08.2017 датасына һәм оферта түгел. ГПБ Банкы. Россия Банкының 354нче генераль лицензиясе. Реклама.

PRESSA.RU

ГАЗПРОМБАНК



САМОЕ ВРЕМЯ
ДЛЯ ВАЖНОГО ШАГА

ИПОТЕКА ПО АКЦИИ

8-800-100-07-01 | www.gazprombank.ru
*0701 | для абонентов МТС, Билайн, Мегафон

9,5%
мы снизили ставку
по ипотеке

Ипотечная акция с 11.08.2017 по 30.12.2017. Целевое назначение: приобретение квартиры в строящемся жилом доме. Ставка по кредиту: 9,5 %. Ставка действует при оформлении полиса / договора личного страхования заемщика (в добровольном порядке). Валюта кредита: рубли РФ. Минимальная сумма кредита: 500 000 руб., но не менее 15% от стоимости недвижимости. Максимальная сумма кредита: 60 млн руб. – при приобретении объекта в г. Москве и г. Санкт-Петербурге; 45 млн руб. – в остальных субъектах РФ. Срок кредита: до 30 лет. Погашение кредита ежемесячными аннуитетными или дифференцированными платежами. Возможность досрочного погашения кредита частично или полностью без комиссий. Требования к обеспечению: залог имущественных прав (до оформления в собственность) / залог (ипотека) приобретенной с использованием кредитных средств недвижимости (после оформления в собственность). Требования к заемщику: гражданство РФ, возраст от 20 до 65 лет. Подробная информация на www.gazprombank.ru и по тел.: 8-800-100-07-01. Информация приведена на 11.08.2017 и не является офертой. Банк ГПБ (АО). Генеральная лицензия Банка России № 354. Реклама.

Ипотека алырга ашыгуның тугыз ярым сәбәбе

Газпромбанк рекордлы түбән ставкалар тәкъдим итә

Быел Россиянең ипотека базары рекорд артыннан рекорд куя. Гаҗәп түгел: кеше һәрвакыт торак шартларын яхшыртырга омтыла, һәм бездә торак сатып алу кредитлары шартларының әле беркайчан да мондый кызыктыргыч булганы юк иде!

Россия ипотека кредиты тарихында беренче мәртәбә ставкаларның шундый дәрәҗәдә түбән булуы һәм милли икътисадның иртәгәге көндә торган саен күбрәк ышаныч уята баруы фонында ипотекага сорау ай саен үсә бара. Ипотека торак кредитлары агентлыгы мәгълүматларына караганда, бары тик 2017 елның 1 яртыеллыгы эчендә генә дә 765 млрд сумлык 420 меңнән артык ипотека кредиты бирелгән, бу 2016 ел дәрәҗәсеннән 15%ка югарырак. Йөзәр мең кеше яңа фатирга күчү мәшәкате белән мәшгуль. Ә сезнең ниятләрегез ничегрәк?

Шартларның кулайлыгы ягыннан ипотека кредитлары базарында лидерларның берсе булып Газпромбанк тора. Банкның лидерлыгы беренче чиратта процент ставкаларының түбән булуына бәйле. Сез иске йортлардагы фатирларга да, яңа төзелә торганнарындагыларга да ипотеканы елына 9,5% исәбеннән рәсмиләштерә аласыз. Алай гына да түгел, әлеге программа шулай ук гаражлар, таунхауслар сатып алуны, һәм дә инде гамәлдәге ипотеканы рефинанслауны да колачлый.

Башка банклардан алынган кредитны Газпромбанкта элеккесенә караганда түбәнрәк ставка буенча рефинанслаганда, сез айлык түләүләрне күпкә киметеп, әлеге акчаларны үзегез, туганнарыгыз һәм якыннарыгыз өчен тота аласыз. Бу тиеннәр генә түгел – сез процентлар буенча кредитның үзенә тәңгәл яисә аның белән чагыштырырлык күләмдәге акчагызны экономияли аласыз!

Газпромбанкта ипотеканы рәсмиләштерү аерым көч яисә озак вакыт таләп итми. 2017 ел ахырына кадәр банкта «Ипотека 1 көндә» акциясе уздырыла – документларның тулы пакеты әзерләнеп тапшырылган һәм күчемсез милек объекты сайланган очракта гариза буенча карарны 24 сәгать эчендә алырга мөмкин.

Ипотека кредитларының һәркем ала алырлык программалары, шәхси якын килү һәм Банкның профессионаллар командасы һәр клиентка хыялындагы милеккә ия булырга ярдәм итәр.

Дилия Минһаҗева, «АК БАРС» БАНК ГАҖ Казан филиалының партнерлык каналы җитәкчесе:

– Кагыйдә буларак, банкларның продуктлар линейкасында, заёмщик үзе өчен иң кулай шартлары булган программаны сайлап алсынга ипотека кредитларының берничә төре бирелә. «АК БАРС» БАНК төрле опцияләре булган сигез ипотека программасы тәкъдим итә. Тулаем алганда, без үз планнарыбызга ярашлы рәвештә эш итәбез. Сезон трендлары арасында рефинанслауга мохтаҗлыкның зур булуын билгеләп үтә алабыз. Безнең клиентлар өчен бу бик кызыклы, чөнки аларның күбесе инде бүген үк ипотека түлиләр һәм ипотека өчен түләүләрне шактыйга киметергә теләкләре бар.

«АК БАРС» БАНК клиентлары үзләренә файдалы шартларда ипотека кредиты ала алалар. Якын киләчәктә банклар ниндидер тәвәккәллекләр булуына да карамастан, шәһәр яны территорияләрендә күчемсез торак милке сатып алу өлешендә кредитларны үстерәчәкләр, дип уйлыйм, чөнки әлегә бу юнәлеш буш булып кала бирә. Безнең банк бүгенге көндә шул юнәлештә эшли.

Реклама

Фото: Александр Ефремов.

«УБРиР» КБ ГАЖ, лицензия № 429, 06.02.2015 ел. Реклама.

Марат Хәсиятуллин, Урал реконструкция һәм үсеш банкының «Казан» операцион офисы башлыгы:

– Казанда без ипотека программасын сентябрьдә генә башлап җибәрдек: Татарстан Республикасында күчемсез милек базарының гаять зур потенциалын һәм перспективасын исәпкә алып, торак кредиты базарына үтеп керергә карар кылынды. Без заёмщикның ихтыяҗын максималь дәрәҗәдә канәгатьләндерә алырлык продуктлар тәкъдим итәбез: бу торак сатып алу өчен классик кредитлар да, башка банкларда алынган ипотека кредитларын рефинанслау һәм башкалар да. Әлбәттә, ипотека базары бүген тыгыз, ләкин безнең өстенлекле якларыбыз бар – заёмщикны тикшергәндә шәхси якын килү, хезмәт күрсәтүнең югары дәрәҗәсе. Болар барысы да даими рәвештә түбәнәя баручы процент ставкаларын исәпкә алганда, күчемсез милекне сатып алу кредитларын аеручa кызыктыргыч итә.

Андрей Савельев: – Без шулай ук быел ипотеканың куәт алып китүен билгеләп үтәргә тиешбез. Ипотека кредитының ставкалары түбәнәя баруы тенденциясе саклана. Шулай ук бу беренчел кертем күләменә дә карый. Ничек кенә баналь яңгырамасын, бүген Татарстан күп кенә пилот проектларны сынау мәйданчыгы булып кала бирә. Бездә ипотека продуктларының беркайда да булмаган формалары бар. Аерым бер төзүчеләрнең һәм банкларның программалары буенча клиентларга 7% ставка белән дә ипотека кредиты бирелергә мөмкин. Ике документ буенча ипотека алуны да беренче булып без сынап карадык. Болар барысы да фатир турындагы хыялны еракка яшермичә, инде бүген үк тормышка ашырып булуы турында сөйли.

ШӘҺӘР ЯНЫНДАГЫ ЙОРТ – ЯШӘҮ РӘВЕШЕ БУЛАРАК

Шәһәр янындагы йортлар базарында ипотекага күпме дәрәҗәдә ихтыяҗ бар?

Андрей Симаков, ДАР компанияләр төркеменең генераль директоры:

– Шәһәр янындагы йортларга ипотека алу артык үсеш алмаган, чөнки банклар ягыннан бу эшкә шик белән карау бар. Ләкин, бәхеткә, шәһәр янындагы күчемсез милеккә закладнойларны рефинанслый торган банклар пәйда булды. Без бүген җир буенча займнар портфелебезне формалаштырабыз, һәм банклар бу юнәлештә эшли башлаганда, без алар өчен зур керем китерерлек яхшы тәкъдимнәребез булачак.

Җир кишәрлекләренә һәм коттеджларга бәяләр динамикасына килгәндә, алар үсми. Киресенчә, бераз түбәнәя дияргә дә була.

Базарның дилетантларга һәм профессионалларга бүленүен дә аңларга кирәк. Һәм үзең генә мөстәкыйль рәвештә беркайчан да төзелеш компаниясе үзәкләштереп төзегәнгә караганда арзанрак йорт сала алмаячагыңны да белергә кирәк. Ышаныгыз, без моны бик яхшы беләбез.

Бүген без Казанның төрле юнәлешләре буенча 7 төрдәге шәһәр яны йортлары проектларын гамәлгә ашырабыз. Аларның һәркайсы үз өстенлекләренә ия: бу елга буенда урнашканлык та, үзәкләштерелгән челтәрләр дә, чисталык һәм тәртипне саклый алырлык идарәче компаниянең булуы да. Бу бигрәк тә кышын мөһим: кар көрәү, юлларны һәм сукмакларны кардан чистартуны алар оештыра. Шәһәр янындагы тормышны сыйфатлы итеп оештыра белгәнгә, клиентларыбыз нәкъ менә безне сайлый. Безнең комплексларда, балалар мәйданчыгыннан тыш, ял итү зоналары, «Альп таулары» белән бизәлгән ясалма күлләр, беседкалар һәм пляж урыннары бар. Барлык бу уңайлылыклар шәһәр читендә яшәүнең рәхәтен тоярга ярдәм итә.

Бүген мин шәһәр янындагы йорт – шәһәр фатирына альтернатива дип әйтә алмыйм. Моның өчен шәһәргә 30 минут эчендә барып җитә ала торган транспорт системасы кирәк. Аннан бигрәк, бу ял көннәрне үткәрү өчен алына торган йорттыр. Шулай да шәһәр кырыендагы тормыш, һичшиксез, яхшырак, табигать, саф һава. Ә без сәламәт яшәү рәвеше тарафдарлары.

Реклама

PRESSA.RU

Андрей Савельев: – Бүген йорт салу өчен төзүче булу мәҗбүри түгел. Моның өчен прораб ялларга гына кирәк. Кагыйдә буларак, алар үз хезмәтләре өчен йорт бәясенең 10%ын сорыйлар…

Андрей Симаков: – Без шуны ук эшлибез, ләкин 5% кына алабыз. Өстәвенә, гарантия бирәбез, ә заказчы проблемалар туганда прорабтан нәрсә ала алачак?

Финат Мөхәммәдиев, «Финдом» ҖЧҖ директоры:

– Безнең компаниянең төп максаты – халыкны ала алырлык, арзан торак белән тәэмин итү. Базарга анализ ясап, без шактый кызыклы юнәлешне сайладык – җир кишәрлеге дә булган, блокларга бүленгән шәхси йорт төзелеше. Һәм бүген әлеге тәкъдимгә, үзенең социаль юнәлешле булуы сәбәпле, көндәшләр юк. Асылда бу эконом-сегментка караган, 2-10 гаиләгә исәпләнгән шәһәр яны коттеджлары. Керү урыны һәр гаиләгә аерым каралган, җылылык системасы индивидуаль, җир кишәрлеге 1,5 сутыйдан 5кә кадәр. Төзелеш өчен сыйфатлы материал – керамик кирпеч сайладык. Бу каркаслы йортлар түгел. Бүген ике бистәдәге йортларны сату бара – Биектау районында «Белые росы» һәм Питрәч районында «Алтын камыш». Без клиентларга нокталап төзелгән йортлар тәкъдим итмибез, бәлки Казаннан 10-15 минутлык юлы булган торак комплекс салабыз. Юлы, инфраструктурасы, транспорты булган бистәләр бу. Әйтик, «Алтын камыш» бистәсендә маршрут линиясе ачарга ниятлибез, Транспорт министрлыгына гариза бирелгән. Бу шәхси транспорты булмаганнар өчен бик уңай булачак. Финанс шартларына килгәндә, клиентларыбыз өчен бездә бер елга исәпләнгән процентсыз бүлеп түләү каралган, шулай ук түләү өчен ана капиталын һәм «трейд-ин»ны да кулланырга мөмкин. Клиентларыбызның якынча 80%ы торак сатып алганда ипотека кредитларын куллана. Соңгы вакытларда компаниянең фатирларын карарга килүчеләрнең күплеге торак базарында әлеге сегментка ихтыяҗ барлыгын раслый.

ЭКСПЕРТЛАР ФИКЕРЕ:

Шулай итеп, торак базарында безне ни көтә?

Антонина Дарчинова:

– Дөнья тәҗрибәсе шуны күрсәтә: без инде якын киләчәктә бик кызыклы тенденцияләр белән очрашачакбыз – альтернатив энергия йөртүчеләр, җылыту һәм яктыртуның заманча системалары. Безгә үз бизнесыбызны тулысынча үзгәртергә туры киләчәк. Ә бу юнәлештә эшне бүген үк башларга кирәк.

Эдуард Хәлимуллин:

– Кулланучы төзүчедән сайлау мөмкинлеге көтә: ремонты булган, җиһазланган фатирмы яисә алардан башкамы. Ераграк киләчәктә без үз торагын булдырмыйча, бер урыннан икенчесенә күчеп йөрергә теләгән Z буынына нәрсә тәкъдим итә алачагыбыз турында баш ватарга туры килер, дип уйлыйм…

Марат Хәсиятуллин:

– Кредитлашу процессына торган саен күбрәк кеше тартыла. 10%лы психологик барьер инде үткәндә калды. Россиядә һәм Татарстанда яхшы торак мәсьәләсе хәл ителгәнче, ипотека базары үсүгә таба барачак. Шулай да ипотека – икенче урында. Иң мөһиме – халыкның сатып алу сәләтенә ия булуы.

Андрей Симаков:

– Ел ахырында бәяләр һәрвакыт үсә. Бу якындагы квартал турында сөйләшүгә кагыла. Ә гомумән алганда, торакка бәяләр мөнәсәбәтендә могҗиза көтәргә кирәкми. Әлбәттә, ниндидер «балкышлар» булырга мөмкин, ләкин аннан соң торгынлык килә. Шуңа күрә сатып алучыларга кулай вакытны кулдан ычкындырмаска кирәк.

Дилия Минһаҗева:

– Коллегаларымның нәкъ менә яңа төзелеш базары үсәчәк дигән фикере белән килешәм. Тулысынча әзер, бизәлгән, җиһазланган торакка ихтыяҗ булачак дигәне белән дә. Алар индивидуаль проектлар буенча салыныр, дип уйлыйм.

Андрей Савельев:

– Беренчедән, торак базары, бигрәк тә яңа төзелешкә караганы, үсәчәк. Икенчедән, ипотека буенча без күпмедер дәрәҗәдә Европа стандартларына якынлашырбыз, дип уйлыйм. Һәм, өченчедән, торакка бәяләр артачак.

Елена Стрюкова:

– Яңа төзелеш проектлары камилләшер һәм үсәр, дип уйлыйм. Клиентларыбыз төзүчеләрдән дә, банклардан да кызыклы тәкъдимнәрне күбрәк алачак.

Нил Паташин:

– Ипотека кредитларын бирү артачагын ышанып әйтә алам. Шул исәптән яңа төзелгән торак сатып алуга караганы да.

Реклама

ЖИЛОЙ КОМПЛЕКС
«АЛТЫН КАМЫШ»

15 км от Казани
Автобус до пр. Победы

ЖК «Алтын Камыш» – современный, комфортабельный экопосёлок

- Кирпичные дома на 2 и 4 семьи;
- Площадь от 33 кв. м и более;
- Индивидуальное отопление;
- Земельный участок от 2,5 сот. у каждой семьи;
- Все коммуникации проведены;
- До посёлка идёт асфальтовая дорога.

Всё для жизни!

- Собственный медицинский пункт;
- Детский сад;
- Торговый центр,
- Спортивная площадка.

Выгодное предложение!
дом 33 кв. м с земельным участком за 1 200 000 руб. *

Застройщик ООО «СтройСервис»
Проектная декларация на сайте
алтынкамыш.рф

Отдел продаж в н.п. Высокая Гора
Высокая Гора, ул. Мелиораторов, д. 9а,
пн-пт 8:00–18:00, сб 8:00–14:00
Тел.: (843) 239-07-25

ФИНДОМ

Подробности на сайте:
алтынкамыш.рф
* до 31.12.2017

Реклама

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

Реклама 16+

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

WWW.PROTATARSTAN.RU

PRESSA.RU

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛДЫНДАГЫ КАЗАНЫШЛАР ӨЧЕН

Борис Кузнецов –
Советлар Союзы Герое, Бөек Ватан сугышы вакытында Днепр өчен яуларда катнаша, Украина, Молдавия, Румыния, Польша, Чехословакияне азат итә, Берлинны алуга үз өлешен кертә. Авыр контузия кичерә, өч тапкыр яралана, ләкин һәрвакыт кире алгы сызыкка кайта. Сугыш тәмамлангач, аны Көнбатыш Украинага власовчылар һәм милләтчеләр оешмалары белән көрәшкә җибәрәләр. Бүген актив рәвештә мәгърифәтчелек эшчәнлеге алып бара, яшьләр каршында еш чыгыш ясый. 2010 елда «Татарстан Республикасы каршында казанышлар өчен» ордены белән бүләкләнә.

АЛГЫ СЫЗЫКТА **ЯШӘП...**

Борис Кузнецов кебек кеше башка юктыр. Кадетлар интернат-мәктәбе горурлык белән аның исемен йөртә, ә Казанда элемтәче-сугышчы һәйкәлен аннан үрнәк алып ясадылар. Аның тормышы турында бәян – илебез елъязмасы ул.

Әзерләде:
Ольга Туманская

ЗАМАННАР КАЙТАВАЗЫ

Бик зур сугыш булды ул. Днепр өчен яуда мин Герой йолдызы алдым. Анда мин элемтә отделениесе составында эләктем: командир, миңа күз ташлагач, бу егет тимерчыбык уралган авыр кәтүкләрне күтәреп йөри алачак, дип бәяләде. Андый кәтүкләрне күп ташырга туры килде. Ядрә һәм снаряд яңгыры астында элемтә гел өзелә. Телефон чыбыгын тешләргә кысып, бозлы елгаларны аркылы йөзеп чыккан чаклар да бер генә булмады.

Безгә таба чираттагы артиллерия һөҗүменнән соң фашистлар контратакага күтәрелде. Рота командиры җансыз егылды, ә немецлар инде борын төбенә килеп җитте – ара йөз метрлап кына калды! Барысы ничектер каушап китте... Безне чебендәй кырып чыгарга була иде шулчакта! Нишләргә? «Туган ил өчен!» дип кычкырып җибәрдем мин, ә башкалар шунда ук күтәреп алды. Бу – халкыбызның бөек патриотизмы иде. Тәнемдәге ярчыклар ул көннәр турында әле дә хәтерләтеп тора.

98 КИЛОГРАММЛЫ КЫЮЛЫК

Сугышны заводта каршыладым. Һөнәр училищесында укыгач, әле борын асты да кипмәгән яшүсмерләрне КОМЗга җибәрделәр. Мастер миңа шундук әйтеп салды: «Менә сиңа станок, менә кискечләр – эшкә кереш». Ә ул станокның озынлыгы гына да 32 метр! Ярый әле төшеп калганнардан түгел идем. Зур, кап-кара туп көпшәсе алып киләләр. Шуны эшкәртеп ялтыратырга кирәк. Бервакыт заводтан ай буе чыкмый эшләдем. Шунда җылыткыч торбалар янындагы такталар өстендә йоклап йөрдем. Төнлә мастер килә: «Борька, тиз генә станокка бас, кулдашың арыган, аягында басып тора алмый». Егетләр хәлсезләнеп егылалар иде. Кайберләрен шунда медпунктта ук аңга китерәләр. Бераз һушын җыя да – кире цехка!

Үз теләгем белән сугышка китү турында гаризаны әллә ничә тапкыр биреп карадым. Башта яшең җитми дип кире кага килделәр. Әмма мин үгез кебек таза идем – 98 килограмм. Уналты яшемдә бит ул! «Динамо» җәмгыятендә бик тырышып шөгыльләнүем бушка китмәде: бокс, штанга, җиңел атлетика, чаңгыда йөрү... Чираттагы баруымда мине үлчәүгә бастыргач, хәрби комиссар, ниһаять, танырга мәҗбүр булды: «Карагыз әле, бу бит чын ир-ат! Ул инде әллә кайчан хәрби хезмәттә булырга тиеш».

ҖИҢҮ ХАКЫ

Волхов фронты нәрсә ул? Траншеяларда кырык сантиметрдан калганы – су. Унбиш градус суык вакытлар. Җиле үзәккә үтә. Ләкин бу әле иң куркынычы түгел. Фронт буйдан-буйга немец снайперлары күзәтүендә: чокырдан каска күренүгә, аны ядрә тишеп үтә! Тран-

шеялардан төнлә генә чыга идек. Минем сугышчан тормышым әнә шулай башланды.

БЕРЛИН АЛТЫНЫ

Безнең 254 нче укчы дивизия алга юл яручылардан булды. Мин барында гына да аны алты тапкыр кире оештырдылар – немецлар тулысынча диярлек кырып бетерә иде чөнки. Ә бу бит, ким дигәндә, биш мең сугышчы! Миңа Берлинга кадәр барып җитү бәхете тәтеде. Ниндидер соры кала булып чыкты ул. Хәер, хәтердә якты бер тап та калды. Өченче рейхның югары чиннарыннан берәүнең вилласы иде ул. Анда күргәннәрне сүз белән генә аңлатып бетерә торган түгел. Искиткеч затлы җиһазлар, картиналар, фарфор… Тагын да ныграк шаккатырганы – группенфюрерның алтын ваннасы иде. Моны күргәч, солдатлар кайсы тешләп карады, кайсы штыклар белән төрткәләде, ванна селкенмәде дә. Тик шул чакта НКВД кешеләре килеп керде: «Ягез әле, күздән югалыгыз!» Өлгергән кеше, бәлки, нәрсәдер эләктереп калгандыр. Мин тырышмадым да – кирәге юк иде.

ТРАНШЕЯГӘ КИТЕРЕП БИРӘЛӘР

Сугыш турында фильмнар карыйм да, исем-акылым китә: артистлар яңа пилоткалар кигән, итекләре чистартылган. Андый нәрсә төшкә дә кермәде! Чүпрәк-чапрак урап йөрдек, итек эләккән кеше сирәк булды. Аяклар гел юештә. Безнең солдатлар еш кына салкын тиеп, чирләп үлә иде.

Ашау ягын да яхшырак дип әйтә алмыйм. Фронтта төрлесе була – икешәр, өчәр көн дә ризык күрмәгән чаклар бар иде. Кыр кухнясы безгә килеп җитә алмый. Дөрес, анысын да әйтим, «күңелле» мизгелләр дә булмады түгел. Йончыган Россия чикләрен үткәч, бераз җиңелрәк була башлады. Украиннар, белоруслар, молдаваннар, поляк, венгр һәм румыннар безгә ризыкны туп-туры траншеяга китерә иде – кемдер соңгы бозавын, кемдер шәрабын да кыстырып килә. Безне һәр җирдә җылы каршыладылар.

БОЗ ҺӘМ СПИРТ

Черкасск янындагы Ирдынь сазлыкларын беркайчан да онытмыйм! Ул сугышлы разведка булды. Дошманның ике блиндажын шартлаттык, ә аннары безне камап алдылар. Немецлар – бер полк, без исә – 24 кеше. Сазлыкка кысрыклап керттеләр, анда – юка боз. Әнә шулай камыш арасында берничә тәүлек качып тордык. Немецлар камышны автомат уты белән тетә, ә без, бәке тишеп, су астына чумабыз. Ике кеше генә исән калдык, теге егет тә спортчы иде. Калганнар туңып үлде. Мине коткарганда, боз элпәсе белән капланган идем. Фронтта күп сөйләшеп тору юк – каралган аякларымны күрүгә үк, табиб турыдан әйтте: «Кисәргә! Башкача булмый!». Ләкин бәхетем бар икән – бу турыда олырак солдатлар ишетеп: «Бигрәк яшь бит, җәл егетне. Әйдәгез, саламга яткырып, аякларын спирт белән ышкып карыйк», – дип, табибны аякларымны кисмәскә күндерделәр. Спирт белән ышкыганнан сон, икенче көнгә аякларыма кызыллык йөгерде, әкренләп аякларып ипкә килде.

ДОШМАН ТЫЛЫНДА

Чын сугыш гел бер якка гына бара торган билет кебек. Заданиегә ун кеше китә, ә кире кайтканда, иң күп дигәндә, ике кеше була. Украинада вакыт. Немец эшелоннары йөри торган күперне шартлатырга кирәк. «Борис, бу эшне сиңа йөклибез. Ике сәгатьтән башкарырга кирәк», – ди капитан. Миңа гранаталар тагып бетерделәр дә шуыша-шуыша чыгып киттем. Эңәле тимерчыбык аша дошман зонасына узу белән, овчаркалар ташланды. Бәхеткә, алар бәйдә икән, чылбыр озынлыгы аздан гына җитми калды. Күрәм: йөз метр читтәнрәк, котыра-котыра, тагын берсе чабып килә. Шулкадәр дулкынландым, хәтта бер мизгелгә аңымны югалтып алгандай булдым. Ә аннары граната ыргыттым. Шартлау яңгырагач, шундый атыш башланды! Читтән үзебезнекеләр ут ачып, «каплап» торды, ә мин шул арада күпер янына шуыштым. Бик акрын барырга кирәк – тирә-якка миналар куелган. Шартлаткыч куйдым, бикфорд шнурын кабыздым – шундый дөмбердәде ки, күпер җимерелеп төште. Кире кайтканда да егетләр булышты. Безне шул дуслык кына коткарып калды. «Үзең үлсәң үл, иптәшеңә ярдәм ит!» – сугыш вакытында буш сүзләр түгел иде ул.

КАТГЫЙ ШЕЛТӘ БЕЛДЕРЕРГӘ!

Дуслар яу кырыенда гына түгел, югары түрәләр янында йөргәндә дә еш коткарды. Бервакыт Хрущев мине төрмәгә олактырырга җыенган иде. Украинада эшләгән чагым. Болай да киеренке вазгыять, ә шулвакыт һич башкарып чыга алмаслык салым планы җибәрделәр. Моны халыктан җыярга кирәк! Ничек эшлисең – анысы һичкемне борчымый. Түләргә яратмый торган затлар тоткан да Хрущевка кумәк шикаять язган, янәсе, мин, тагын өлкә комитеты секретаре Олексенко һәм җирле башкарма комитет рәисе «эш урынында чик-чама белмибез икән». Безне Киевка кызган табага чакырдылар. Коридорда утырабыз, ә кабинеттан кычкыралар-акыралар: Хрущев – кечкенә буйлы, тазарак, тик шулкадәр яман тавышлы ир-ат иде. Ишек ачылып киткәч, өстәл янына утырган берсеннән-берсе зуррак түрәләрне күрәбез. Хрущев үзе исә әрле-бирле йөренә, безне аты-юлы белән сүгә. Ә каршы әйтергә ярамый! «Шундый тәкъдим бар – партиядән чыгарырга да судка бирергә!» Көтмәгәндә безне ике тапкыр Советлар Союзы Герое, генерал-майор Сидор Ковпак яклап чыкты: «Без аларны ни өчен партиядән чыгарырга тиеш әле? Карале: монысы бөтенләй малай гына, ә Олексенко миндә штаб начальнигы иде…» Бәхәс иртәнге өчкә кадәр барды. Нәтиҗәдә Хрущев бераз суынды: «Катгый шелтә белдерергә дә, анагызның.. олагыгыз моннан!» Пуля кебек атылып чыгып киттек…

НЕФТЬ ҺӘМ МЕТАЛЛ

1953 елда – нәкъ Сталин үлгән көнне – мин, ниһаять, Казанга кайттым. Килеп төшү белән хуҗалык эшенә чумдым. Берничә ел «Главметаллсбыт» оешмасында идарәче булдым. Йөздән артык оборона предприятиесе белән эшләдек, нефть тармагын күтәрүдә дә катнаштык. Мәскәүдәге җитәкчелектән миңа шактый еш «эләкте»: үз өстемә артык күп нәрсә ала идем. Ә ничек алмыйсың инде? Әйтик, «Главнефтесбыт»тан идарәче килә: «Әйдә, киттек, мин сиңа кешеләрнең ничек елаганын күрсәтәм, алар эшсез утыра – торбалар да, башкасы да – бернәрсә дә юк!». Шунда ук Фикрәт Табиев шылтырата: «Борис Кириллович, Бөгелмә, Әлмәт, Лениногорск – барысы да туктады! Мәскәүгә бар, бик-бик кирәк бит!» Барам, мәсьәләләрне хәл итеп йөрим, үгетлим. Ә анда барысы җиңел, шома гына уза дисеңме?.. Үз башымны бик еш куркыныч астына куярга туры килде! Үзем өчен түгел, кешеләр өчен бит – менә шушы уй ышаныч бирә иде. Бүген безнең нефть тармагы республикада иң алдынгылардан, моңа минем дә өлешем керү күңелемне җылыта.

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән ТР дәүләтчелеген үстерүдә, гражданнарның хокукларын һәм азатлыгын тәэмин итүдә, икътисад, мәдәният, фән, мәгариф, сәламәтлек саклау, сәнгать һәм спортны үстерүдәге зур казанышлар, шулай ук җәмәгать тәртибен саклауда күрсәткән кыюлык һәм батырлык өчен бүләкләнәләр. Әлеге билге 925нче пробалы көмештән эшләнгән.

PRESSA.RU

ТАТАРСТАНДА ЮГАРЫ УҢЫШ СЕРЕ

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек сәнәгате хезмәткәрләре көне алдыннан «Татагрохим» ААҖ генераль директоры Наил Гобәйдуллин «Татарстан» журналын республика өчен рекордлы күрсәткеч – 5 миллион тонна ашлык җыюга зур өлеш керткән предприятиесе белән якыннанрак таныштырды.

– Наил Фарукович, ни өчен Татарстан авыл хуҗалыгы тармагында агрохимия зур роль уйный?

– Татарстаныбызда уңыш күләме елдан-ел артыграк булсын өчен, ашлама куллану зарур. Әмма республика чәчүлек мәйданнарының шактый өлеше ачы һәм бик ачы туфраклы территорияләрдә урнашкан. Мондый мәйданнарны ашлаганчы известь кертмәсәң, нәтиҗә булмаячак яки туфрак киресенчә начарланачак кына. Безнең холдингның исә бөтен республика күләмендә известь белән ашлауның күпьеллык циклын башкару өчен мөмкинлекләре җитәрлек. Структурабызга 28 район предприятиесе, известьле ашламалар табу һәм җитештерү буенча 16 карьер, минераль ашламаларны тимер юл транспортыннан бушату өчен 5 база һәм авыл хуҗалыгы җирләренең гомуми мәйданы 30 мең гектарга якын булган 15 ярдәмче хуҗалык керә. Хуҗалыкларда терлекчелек белән дә шөгыльләнәләр: аларда барлыгы 5,5 мең баш мөгезле эре терлек асрала (1,2 мең баштан артыграгы – савым сыеры, 1 баш сыердан елына уртача 5,3 мең кг сөт савыла).

– Барлык бу ресурслар туфракларка известь кертү эшләрен башкару максатларында гына файдаланыламы?

– Юк, бу максатларда гына түгел. Без шактый юнәлештә махсуслашабыз: «Татагрохим» ААҖ авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә органик ашламалар әзерләү һәм кертү; минераль ашламалар белән тәэмин итү; авыл хуҗалыгы тармагында йөк төяү, бушату һәм күчерү; махсус техниканы ремонтлау; үсемлек һәм орлыкларны авыруларга һәм корткычларга бирешүдән саклау һ.б. буенча бик нәтиҗәле хезмәт күрсәтә. Эшебезнең иң кызыклы юнәлешләреннән берсе – конференция һәм семинарлар оештыру, шулай ук җирләрнең уңдырышлылыгын күтәрү буенча консультатив ярдәм күрсәтү.

– Компания махсуслашкан игенчелек технологияләрен куллану нәтиҗәлеме?

– Безнең иген игү ысулларыбызның нәтиҗәлелеге үз тәҗрибәбез белән раслана. «Татагрохим» ААҖ ярдәмче хуҗалыкларында уңдырышлылык республикадагы уртача күрсәткечләрдән югарырак. Әгәр 2016 елда Татарстанда уңыш күләме гектарыннан уртача 27 центнер булса, бездә 32 центнер булды, 2017 елда республика буенча – гектарыннан 34 центнер, бездә – 41,1 центнер. Иң югары уңышны Балык Бистәсе (55 ц/га), Буа (48,4 ц/га) һәм Чирмешән (46,1 ц/га) районнарындагы ярдәмче хуҗалыклар күрсәтте.

– Мондый күрсәткечләрнең, эшчәнлек спецификасы һәм предприятиенең катлаулы структурасының күп чыгымнар таләп итүе бәхәссез. Аның эшчәнлеге рентабельлеме?

– Тышкы яктан никадәр генә уңышлы күренсәк тә, рентабельлелек турында сөйләп булмый әле. Соңгы елларда без субсидияләрне азрак алабыз, димәк, эш күләмен киметергә тиешбез. Әйтик, без известь кертә торган җирләрнең мәйданы хәзер елына нибары 70 мең гектар тәшкил итә. Мондый күләмдә известь белән ашлауның кабатланулыгы 10–15 елга кадәр арта, бу исә ачы туфрак күләмен ишәйтә, димәк, минераль ашламаларның хакы чыгарылу да, җирләрне файдалануның нәтиҗәлелеге дә кими. Моннан тыш, мондый шартларда предприятие тулы куәтенә эшләми башлый, шунлыктан аның бөтенләй юкка чыгу куркынычы туа. Чөнки карьердан файдалансаң да, файдаланмасаң да аны карап тотуга елына 1 миллион сум акча китә, моңа Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән «Ростехнадзор» таләп иткән экология җыемнары да, персоналны даими укыту һәм рөхсәтләр алу да керә. Шунлыктан безнең бүлекчәләр даими диверсификацияләнергә, үзләренең төп эшчәнлегенә акча табар өчен тырышырга мәҗбүр. Аларның җитәкчеләренең күпьеллык тәҗрибәсе бу очракта бик булыша.

– Әлеге шартларда «Татагрохим» ачык акционерлык җәмгыятенең перспективалары нинди соң?

– Соңгы еллар тәҗрибәсе күрсәткәнчә, известь кертүдән баш тартырга ярамый. Кайбер авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләренең уңышны арзанга, тиз генә һәм бик күпкә арттыру өчен кулланырга тырышкан технологияләре тиз арада туфракны ярлыландыра һәм игенчелек өчен яраксызга әйләндерә. Моннан тыш, без – Татарстанда «Россельхознадзор» таләпләрен үти торган бердәнбер теркәлгән известьле ашламалар предприятиесе. Шуның белән бергә, без үз эшчәнлегебезнең фәнни һәм технологик базасын һәрдаим камилләштерәбез. Бүген, мәсәлән, известьләү процессын сипкеч машинаның борт компьютеры контрольдә тота. Аның программасын без Агрофизика ФТИ (Санкт-Петербург шәһәре) белән бергәләп эшләдек. Шунлыктан безнең киләчәгебез өметле, дип уйлыйм. Татарстанның агросәнәгать комплексы даими үсештә, без дә аңардан калышмыйбыз.

ОАО «Татагрохим»
Телефон: 562-24-91,
tatagrohim@bk.ru,
www.oaotatagrohim.ru

Реклама

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Бурятия татарлары **НИЧЕК** яши

Иң матур күл **КАЙДА** урнашкан

Как ясау осталары **КАЙДА** яши

КАЙСЫ авылда гигант кабаклар үсә

НИ ӨЧЕН Каракүл үз урынын алыштыра

PRESSA.RU

АВЫЛДАН – ТАЙГА УРМАНЫНА

Сәҗидә ханым Батталова белән Бөтендөнья татар конгрессының VI корылтаенда таныштык. Бурятия халыклары Ассоциациясе рәисе ул. Бер сүз белән әйткәндә: янып тора. Аннан башка Бурятиядәге татар дөньясында бер генә чара да узмый. Сәҗидә Батталовадагы фикер, идея... Аның хәтта Казанга да планнары зурдан.

Автор:
Руфия Фазылова

«МИН БОЛАРДАН БАШКА НИЧЕК ЯШӘДЕМ ИКӘН?»

Сәҗидә апаның татарчасы камил түгел. Телне аңлый, ләкин татарча тулы итеп җавап бирә алмый. Моңа, бер карасаң, артык гаҗәпләнергә дә кирәкмидер, руслар, бурятлар яшәгән төбәктә татар телле булып үсү шактый авыр. Әле монда Казан татарлары ана телләрен белми. Сәҗидә апаның балачагы, үсмер елларында «туган тел», «милләт» дигән төшенчәләргә игътибар да әллә ни булмый. Татар теле Бурятиягә, аерым алганда, Улан-Удэ шәһәренә, 1990нчы еллардан соң гына килә. Менә шунда гына яшь ханым тамырлары турында уйлана башлый. Тормыш рәвешен үзгәртә. Кан тартмаса, җан тарта, диләр бит...

– Яшьлектә милли узаң бик сирәк кешене борчый, – дип сөйләде Бурятия халыклары Ассоциациясе рәисе. – Яшь вакытта бу сорау: «Миңа нигә кирәк ул?» – кебегрәк яңгырый. Кырыктан соң: «Ник мин моны белмим?» – дип уйлыйсың. Алтмыштан соң: «Мин болардан башка ничек яшәдем икән?!» – дисең. Үзенең гореф-гадәтләрен, милли кыйммәтләрен белгән кеше тормышта күп нәрсәгә ирешә. Ә иң мөһиме: башка халыкларга карата да ихтирамлы була. Менә шул очракта гына төрле милләтләр яшәгән төбәктә тынычлык, бер-беренә карата хөрмәт саклап була. Бурятия Республикасы – Россиянең күпмилләтле төбәкләренең берсе. Якынча йөз төрле милләт вәкиле яши бездә. Дус-тату торабыз, бер-беребезне хөрмәт итәбез, дисәм, һич тә арттыру, ялган булмас. Бер мисал: 2010 елда Улан-Удэда гаҗәеп зур мәчет ачылды. Аны барлык шәһәр халкы бергәләшеп салды. Бүген ул ислам динендә булган төрле милләт вәкилләрен берләштерүче изге урын. Хәзер яңа максат белән яшибез: мәчет мәйданында хәләл кибет, кафе һәм мәктәп булдыру. Моның проектын эшләп чыктым. Шәһәр администрациясеннән рөхсәт алдык. Мәчетне биш ел төзедек, пландагы яңа биналарны да шул вакыт эчендә эшләп чыгарбыз, дип өметләнәм. Мәктәптә балалар гореф-гадәтләребезне, тарихыбызны, телебезне өйрәнерләр, дип ышанабыз.

Улан-Удэ шәһәрендә татарларның җыелыр урыны булмый. Бары 2004 елда гына милли-мәдәни автономия төзиләр. Ул вакытта Россиянең төрле төбәкләрендә шундый оешмалар пәйда була. 2005 елда Улан-Удэ шәһәрендә Сабантуй оештыралар. Нәкъ шуннан соң Саҗидә Батталова тәүге тапкыр Казанны күрү бәхетенә ирешә.

– Миндә шок булды, – ди Саҗидә апа. – Бөтенләй икенче дөнья, мәдәният… Кол Шәриф мәчете үзе генә ни тора! Казаннан кайткач, татарлыгыбызга башка төрле күзлектән карый башладым: без кубәү, без көчле халык! Әле ярый Улан-Удэда милли-мәдәни автономия төзедек дип сөендем. Казаннан алып кайткан яңа идеялар, планнарны тормышка ашыру өчен, һичшиксез, җирле җитәкчеләрнең ярдәме кирәк иде. Рәхмәт, кайсы гына ишекне шакысам да, кире борып чыгармыйлар. Төрле чаралар үткәрергә, проектлар эшләргә ярдәм итәләр.

2011 елда Улан-Удэда Халыклар дуслыгы йорты төзелгән. Махсус татар китапларыннан торган китапханә, якшәмбе мәктәбе булдырылган. Ә 2016 елда шушы ук бинада Татар мәдәнияте клубы ачканнар. Җырга-моңга, биюгә сәләтле яшьләр, гомумән, теләге булган һәр кеше бирегә килеп сәнгать белән шөгыльләнә ала.

– Татарча җырлап, биеп йөрү генә җитми, – ди Саҗидә апа. – Бурятиядә татарлыкны саклау бик авыр. Татар авылларында мәктәпләрдә ана телен факультатив укытырга мөгаллимнәр юк. Ә иң кызганычы: туган телебездә сөйләшкән яшьләр аз. Гаҗәп тә түгел, алар татар мохитендә үсмәгән. Советлар чорында ана телебезгә карата бөтенләй игътибар булмады. Шуңа да, иң беренче чиратта, яшьләр белән эшләргә тырышабыз. Өлкәннәр, яшьләрне бергә җыеп, төрле очрашулар үткәрәбез. Алар анда татарча аралаша, җырлый, бии. Бәлки читтән караучылар: «Җырлап кына телне саклап калып булмый», – дияр. Тик башкача да булмый. Үсеп килүче буынга туган телебезне җыр-моң, сәнгать аша булса да өйрәтергә кирәк. Безнең максат – яшьләребез татар телен гади аралашу дәрәҗәсендә булса да аңласыннар, белсеннәр. Гаҗәпме, түгелме, башка милләтләр татарның барлыгын зурлап Сабантуйлар үткәрү башлангач кына күрде. «Моңа кадәр бикләнеп ятканбыз икән», – дип шаккаттым. Шуңа күрә төбәкләрдә милли-мәдәни автономия оешу милләттәшләребез өчен бик мөһим, кирәкле оешма булды, дип саныйм. Бердәмлекне тою, аралашу өчен бик кирәк ул.

«ИНДЕ ҮЛСӘМ ДӘ, ҮКЕНЕЧЛЕ ТҮГЕЛ»

Саҗидә Батталова тамырлары белән Буа районының Янтуган авылыннан. 1930 елда, кулаклар дип, бабасының әтисе Хисаметдин белән әнисе Мәүҗидәне авылдан тайга урманнарына сөргәннәр. Ир белән хатынга, берсеннән-берсе кечкенә сигез баласын ияртеп, туган җирләрен мәңгелеккә калдырырга туры килә. Иң кечесенә нибары биш ай була.

– Мин җиде буын бабамны да беләм, нәсел шәҗәрәбезне төзедем, – ди Саҗидә апа. – Бабамның әти-әнисе күргән фаҗигаләрне ишеткәч, чәчләр үрә тора иде. Хисаметдин бабай эшкә батыр булган. Янтуганда мәчет төзеткән, кибет ачкан кеше ул. Тырышлыгы белән башка яшьтәшләреннән аерылып торган ул. Алты-җиде яшеннән хәллерәк кешеләргә хезмәт итеп акча җыйган. Әбигә өйләнгәч, җирен эшкәртергә ат сатып алган. Соңрак аларны берничә башка өйләндергән. Җәй көне атларны көтәргә кеше яллаган. Шулай яшәп ятканда аларга бер тәүлек эчендә авылдан чыгып китәргә кушканнар. Бар мөлкәтләренә арест салганнар. Әби: «Гөнаһсыз сабыйларым хакына сорыйм, кече улыбызга яшь тулганчы булса да, туган авылда яшәргә рөхсәт бирегез», – дип кан-яшь белән елаган. Юк, рөхсәт итмәгәннәр.

Һәм әби белән бабай, әти-әниләрен, якын кешеләрен калдырып, авылдан мәңгегә чыгып киткән. Бу аларның әти-әниләре белән соңгы күрешүләре булган. Еллар узгач, картаеп барганда, әби белән бабай туган якларын кайтып күргәннәр. Авыл үзгәргән, кешеләр дә бүтәнгә әйләнгән инде. Әби, туган туфрагын учына алып: «Инде үлсәм дә, үкенечле түгел», – дип елаган..

…Менә шуңа охшаш язмышларны ишеткәч тетрәнеп куясың! Татарның акыллы, иң тырыш никадәр ир-аты, хатын-кызы туган җирләреннән сөрелгән. Һәм алар читтә дә югалып калмаган! Дөрес, нинди зур фаҗигаләр бәрабәренә! Хисаметдин абый белән Мәүҗидә апаның сигез баласының өчесе һәлак була. Ата белән ана, исән калган биш баласын күкрәгенә кысып, тайга урманнары читенә килеп урнаша. Читадан 500 чакрым ераклыктагы тау-таш арасы була ул. Урамда илле градус суык. Землянка казып, шунда яши башлыйлар. Калган балалары да ничек катып үлми – могҗиза! Ир белән хатын бер елдан тау арасында бәрәңге үстерәләр инде. Акрынлап тер-

PRESSA.RU

лек үрчетәләр. Шулай итеп тайга шартларында яшәргә яраклашалар. Ә Бөек Ватан сугышы башлангач, «кулак» дип тайгага сөрелгән Хисаметдинның да кирәге чыга – ирне фронтка чакыралар.

– Кайбер кешеләр турында «күлмәктән туган» диләр, – дип сүзен дәвам итте Саҗидә ханым. – Бабай да шундый бәхетлеләрнең берсе булган дип уйлыйм. Кеше җитмәгәнгә, 1942 елның азагында бабайны сугышка алалар. Бөек Ватан сугышында «кулак» дип сөрелгәннәрнең күбесе фронтка чакырылган бит. Бабай Курск Дугасына кадәр барып җитә. Сугыш тәмамлангач, яралар алып, гаиләсе янына кайтып җитә ул. Мине иң гаҗәпләндергәне менә нәрсә: әби, ире фронтта вакытта, Янтугандагы туганнарына посылкалар җибәрә. Югыйсә ул да ялгызы биш бала үстергән бит. Димәк, тайга әби-бабайларны ачлыктан саклап калган.

Берничә ел элек Саҗидә Батталова Буа районы Янтуган авылына кайткан. Бишенче буын туганнары белән очрашкан. Авыл буйлап йөреп чыкканнар. Зиратка да барганнар.

– Улан-Удэ – туган шәһәрем, – дип сөйләде Саҗидә апа. – Әлбәттә, Татарстан да миңа якын. Монда килгәч, күңелгә ләззәт алам, алга таба эшләргә планнар барлыкка килә. Тик хәзер бабаларымның тайгага сөрелүенә фәлсәфи яктан карыйм: димәк, шулай кирәк булган. Безнең кавем Бурятиядә татар милләтен күтәрергә тиеш. Әби-бабайның биш баласы, ягъни әти-әниләр татарча бик яхшы беләиде. Аларның йортында һәрвакыт Әлфия Афзалова, Фәридә Кудашева, Илһам Шакиров пластинкалары яңгырады. Аларга әби белән бабайның кушылып җырлаганнары да истә. Күрәсең, туган якларын сагынуны шулай басканнар. Диннән дә ваз кичмәделәр, намазда булдылар. Балаларын да Аллаһның барлыгына, берлегенә инандырып үстергәннәр. Хәтерлим, әни комсомолга керәсе көнне: «Кызым, «бисмиллаһ»ны әйтергә онытма», – диде. Аллага шөкер, намазга бастым. Бу бик мөһим.

ЮЛ КЫРЫЕНДА – ШҮРӘЛЕ, СУ АНАСЫ СЫННАРЫ...

Саҗидә Батталова турында «тынгысыз» диган идем бит. Аның Бурятия татарлары тормышын үстерү буенча әллә никадәр планнары бар. Бу турыда хәтта зур булмаган китаплар да чыгарган.

– Европалашырга ашыкмаска кирәк, – ди Саҗидә апа. – Ул тенденция дөньяда болай да җитәрлек. Безгә үз телебезне, мәдәниятебезне, традицияләребезне саклап калырга кирәк. Ә мирасыбыз бик бай һәм эчтәлекле. Татар авылларында этнографик туризмны җәелдерергә кирәк. Мисал өчен, Бурятиягә меңләгән турист килә. Алар җирле халыкның мәдәнияте, яшәеше белән кызыксына. Автобуска утыртып бер татар авылына алып барасың. Бүрәнәдән салынган йортта яшәсеннәр, милли ризыкларны ашасыннар, татар мунчасында юынсыннар. Бу, бердән, авыл кешесенә – эш, икенчедән – район бюджетына акча. Әлеге идея безнең республика җитәкчелегенә ошап китте. Хәзер татарлар башка милләтләр тупланып яшәгән авылларда туризмны җәелдерү белән шөгыльләнә. Мәсәлән, Иске Онох бистәсендә «Әни коесы» исеме астында эшлиләр. Килгән кунаклар алдында коедан су алып чәй кайнаталар, өчпокмаклар белән сыйлыйлар. Шулай ук килгән кунакларга Сабантуйдан кала милли бәйрәмнәребез – «Каз өмәсе», «Нардуган», «Карга боткасы», «Сөмбелә»ләрне күрсәтергә була. Туристлар берәттән татар сүзләрен дә ишетә. Шәп бит!

Бурятия халыклары Ассоциациясе рәисенең Татарстан, Казан өчен дә план-тәкъдимнәре бар: «Татарның башкаласында миллилек җитми кебек тоела», – диде ул. – Мисал өчен, «Кырлай» паркыннан Кремльгә таба барганда, юл кырыйларына Шүрәле, Су анасы, Кәҗә белән Сарык, башка сыннарны куярга була. Татарның үзенә генә хас никадәр персонажы бар!

Саҗидә апа әлеге планнарын махсус туплап Бөтендөнья татар конгрессының VI корылтаена да алып килгән. Тик кызыксынучы гына булмаган.

– Татарстанда да авыллар бетеп бара, – ди Саҗидә Батталова. – Бирегә дә әллә нинди кызыклы проектлар эшләргә була. Әйтик, туристлар килсен, атна буе авылда яшәсеннәр. Сыер савып, көтү көтеп карасыннар. Гади бер татар авылында яшәүче агай, апа өчен дә никадәр файда. Беренчедән, өстәмә керем, икенчедән чит ил вәкиле белән күрешү. Хәзер инглиз телен авыл мәктәпләрендә дә укыйлар. Балалар чит ил туристлары белән аралашып, тел байлыкларын арттырырлар иде.

Саубуллашканда милли җанлы ханым:

– Бурятиядә бүген татарча җырлау, сөйләү модада, – диде. – Андыйларны республикада узган барлык чараларга чакыралар. Тагын шунысы бар: кайсы гына эшкә алынсалар да, милләттәшләребез сынатмый. «Татарлар тырыш, ышанычлы халык!» – дип юкка әйтмиләр. Һәм бүген безнең максат – бу ышанычны аклау, аны тагын да үстерү... ■



БАЛЫКЛЫ КҮЛЕНДӘ НИЛӘР БАР?

Автор:
Руфия Фазылова

Теләче районында 76 хуҗалыклы Балыклы авылы бар. Берничә ел элек, авылларындагы башлангыч мәктәпне яптырмас өчен, республика матбугатын шаулатты алар. Халык теләгенә иреште: бүген белем бирү учагы балаларны хәреф танырга, санарга өйрәтә. Балыклының халкы һаман да шундый үткен, туган авыллары өчен җан атып торамы? Шуны күреп кайттык.

«АВЫЛНЫҢ ЙӨЗЕНӘ КЫЗЫЛЛЫК КИТЕРМӘДЕК!»

Балыклыда 286 кеше яши дип исәпләнә. Ни өчен шулай дим, авылда теркәлеп тә читтә яшәүчеләр шактый. Авылда башлангыч мәктәп, кибет, мәчет бар. Мәктәп белән бер бинада фельдшер-акушерлык пункты да урнашкан.

– Әле журналистларны үзебез дәшмәкче идек, – диде кибет янына җыелган апалар, каян килгәнебезне әйткәч.

– Нәрсә булды соң? – дим.

– Фельдшерсыз калабыз дип курыктык. Үзебезнең фельдшер пенсиягә китте. Авылдагы халыкның күпчелеге – өлкәннәр. Укол салырга, кан басымы үлчәргә дә кеше булмаса нишләмәк кирәк?!

Баксаң, Балыклының иске генә фельдшер-акушерлык пунктын (кабинет кына дисәм, дөресрәк булыр, мөгаен) ябабыз, дип әйткән булганнар. Халык ризасызлык белдергәч, фельдшер тапканнар. Тик ул ике көнгә бер тапкыр күрше авылдан килә икән.

– Ә берәрсе төнлә авырып китсә?! – дип аптыраша Балыклы халкы. – Икенче авылдан фельдшер ничек килеп җитәчәк?

Чынлап та, проблема бу. Бүген авылларда мәктәпләрне ябуга күндек инде. Балалар саны аз, нишлисең. Бер-ике бала өчен аерым бина җылытып утыру бик үк дөрес тә түгел. Ә менә фельдшер-акушерлык пунктлары, һичшиксез, булырга тиеш. Нигездә авылларда өлкән яшьтәгеләр яши. Ә алар көн дә табиб күзәтүенә мохтаҗ.

...Авылның матур исемен: «Җисеменә туры китереп кушылган», – диделәр. Авыл уртасында елга аккан, күлләр дә булган.

Элек монда су тегермәне дә бар иде, – дип сөйләде авылның иң өлкән кешеләренең берсе саналган Гайсә абый Шәкүров. – Сугышка кадәр зур ат фермасы тоттылар, 300ләп баш булгандыр. Баһбайларны колхозлашу елларында һәр йорттан җыйганнар. Сугыш елларында ул атлар фронтта кырылып бетте. 1940нчы елларда авылда 200дән артык хуҗалык бар иде. Бер класста унсигез-егерме бала укыдык. Аннан халык саны акрынлап кими башлады...

Балыклыда гомер-гомергә башлангыч мәктәп кенә булган. Бүген дә шулай. Дөрес, сугышка кадәр класс саен 18 бала укыса, хәзер бөтен мәктәбенә дә 8 укучы. Бишенчегә балалар күрше Алан урта мәктәбенә бара. Ике авыл арасы ике генә чакрым.

– Авылдагы күркәм гадәт – хезмәт көненә балык өләшәләр иде, – дип, хатирәләрен яңартты тугыз дистәне тутырып килүче Гайсә абый. – Елгада тотылган балыкның авырлыгы өчәр килога җитә иде. Эх, күңелле чаклар... Сагындыра.

Балыклы халкы итек басу белән дә шөгыльләнгән. Игенчелек, терлекчелек төп шөгыль булган.

– Мин биш яшемнән чабата бәйләдем. Азрак үсә төшкәч, итек бастым, – диде Гайсә абый. – Аннан комбайнда йөрдем. Яшьлегебез сугыш чорына туры килде, яхшы эшләгәнгә медальләрем дә күп – 15 данә. Авыл исеменә тап төшермәдек, йөзенә кызыллык китермәдек...

Фото: Лилиана Вәлитова

PRESSA.RU

1. – Үзең карап үстергән мал кадерле икән, – ди Хәким Хадиуллин.

2. Хәким абый табигатьне ярата. Авылларындагы ике чишмәнең чыганакларын чистартып, аларга махсус корылма эшләткән.

АТЛАРНЫ ЯРАТУЧЫ «ИТ КОРОЛЕ»

Балыклы кечкенә генә булса да, биредә халыкка эш бар, шунысы сөендерә. Әле колхозлар чорыннан калган «Алан» хуҗалыгы гөрләп эшләп тора. Җирләрне агрофирмага бирмәгәннәр. Бер генә хуҗа булу сизелә: фермалар төзек, игеннәр сугылган, көзге уҗым чәчелгән.

Биредә тагын бер төзек ихатага юлыктык – Хадиуллин Хәкимнең сугым цехы икән. Рәттән берничә бина тезелеп тора: цехка кергән машиналарны юу өчен гараж, административ бина, суеласы малларны тоту һәм чалу урыннары аерым. Ишек алдында ит өчен өч махсус зур туңдыргыч та бар.

Әлбәттә, эшли башлаганда боларның берсе дә юк иде, – дип, ихаталар белән таныштырып йөрде Хәким абый. – Дөресен генә әйткәндә, баштагы мәлдә итчелек белән болай зурлап шөгыльләнермен димәгән дә идем. Казанда яшәгәндә, өстәмә бер керем булсын дип, авыл кешеләреннән ит сатып алып, аерым нокталарга илтә башладым. Ике арада йөри торгач, танышлар, ит сораучылар, ит тапшыручылар күбәеп китте. Барысына да кул селтәп, шуның белән генә шөгыльләнергә булдым.

Күпләргә гаҗәп тоелыр: Хәким абый Казандагы йортын, эшен ташлап, гаиләсе белән туган ягына кайтып төпләнгән. Кешеләр шәһәргә китү ягын караса, Хадиуллин киресенчә эшли. Һәм моңа тамчы да үкенми.

Шәһәрдә яшим, дип, кешеләр кысан фатирларда, әллә ничәшәр мең акча түләп яши, – ди Хәким абый. – Ахмаклык бу, билләһи. Авыл җирендә 10 мең сум алып эшләсәң дә, шәһәрдәге 50 меңне каплый. Тавык-чебиен асрасаң, хайван үстерсәң, әлбәттә. Шәһәр җирендә бер миллионга тулай торактан бер бүлмә алсаң, авылда менә дигән йорт төзеп яки сатып алып була. Хәзер авылда да су ташыйсы, утын ватасы юк. Аптырыйм мин халыкка. Саф һава, иркенлек, ыгы-зыгы юк! Ял итәсең килсә, гаиләңне аласың да Казанга барып кайтасың, алтмыш кына чакрым бит. Юллар әйбәт, машиналар һәркемдә бар. Улым Нияз, шәһәр баласы була торып, яшәргә Теләчегә кайтты. Исәбе – крестьян-фермер хуҗалыгы төзү.

Хәким абый сугым цехын 2010 елда төзегән. Ике кеше даими эшли, тагын өч кеше вакытлыча килеп булыша. «УАЗ», «Газель» машиналары бар. Бер машина итне төяп алып китсә, икенчесе тере хайваннарны Теләче, Саба, Кукмара районнарыннан алып кайта. Ит Теләче районы кибетләренә, Казанның «Бәхетле», башка берничә зур сәүдә үзәгенә озатыла.

– Ит сату хәзер бик четерекле эш, сатуга дигән тавыкның да документы булырга тиеш? – дим.

– Әйе, хәзер бу өлкәдә таләпләр катгый. Моннан унбиш еллар элек, әлеге эш белән шөгыльләнә башлаган вакытта, итне бер документсыз да алып барып тапшыра идек. Хәзер кәгазь өстенә кәгазь кирәк. Суеласы малны башта районның ветеринар табибы килеп тикшерә, тән температурасы нормадамы, тиешле прививкаларын барлый. Һәр хайванның документы булырга тиеш, шунсыз сатып алмыйбыз. Терлекне суйганнан соң, ветеринар тагын бер кат итне тикшерә, махсус келәймә суга.

Хәким абый Хадиуллин турында сөйләгәч, аның юмартлыгы, хәйрияче булуы турында да әйтми калу ярамас. Авылдагы Сабантуй, районда ел саен уздырыла торган кул көрәштерү – армрестлинг буенча турнирлар – барысы да аның матди ярдәме белән оештырыла. Хәким абый табигатьне ярата. Авылларындагы ике чишмәнең чыганакларын чистартып, аларга махсус корылма эшләткән ул. Һәм күл ясатып, анда балыклар җибәргән.

– Сугым цехы элеккеге күл урынына урнашкан, – дип сөйләде Хәким абый. – Авылның аскы өлешендә гел сулыклар булган бит. Кечкенәдән күл ясарга кирәк дигән хыялым бар иде. Аллага шөкер, хыялым тормышка ашты. Авыл башында кечкенә генә инеш бар, шуны тракторлар белән буып куеп, күл ясадык. Карп, кәрәкә балыклары да җибәрдем. Үрчеделәр. Җәен халык күлдә балык тота, су коена. Күңелле бит!

Хәким абый тормыш иптәше Раушания апа белән бер ир бала, бер кыз бала үстергән. Балалары башлы-күзле булган, оныклар бүләк иткәннәр. Тик авыл җанлы эшмәкәр картаерга бер дә ашыкмый. Итчелек эшен үстерү, колбаса, башка ризыклар ясап сатуны җәелдерергә уйлый. Һәм атлар. Бу хайваннарны Хәким абый аеруча ярата икән. Ихатасында дистәдән артык аты бар:

– Боларны иткә җибәрергә кул бармый, – ди Хәким абый. – Үзең карап үстергән мал кадерле икән. Торсыннар, үрчесеннәр. Бәлки, ат фермасы ясармын әле...

«НАМАЗЛЫКНЫ ФӘРЕШТӘЛӘР БИРГӘНДЕР»

Балыклыда 2 май көнне зур фаҗига була – ике хуҗалык санаулы минутлар эчендә янып бетә. Янгын Галиәхмәтовлар каралтысыннан башлана. 81 яшьлек Рәшит абый белән 79 яшьлек Гөлминур апа документларын да алып чыга алмый кала. Бу очракта: «Әле ярый үзләре исән калган», – дияргә кирәктер.

– Балалар беренче май көнне бакча эшләрен бетереп китеп барды. Иртәгәсен бер кашыксыз урамда калдык, – дип сөйләде Гөлминур апа. – Иртәнге уннар иде. Сатучылар йөри икән, ишек шакыйлар дип чыксам, каралтының шиферлары күккә оча. Ничек тиз арада үземне кулга алдым, белмим: «Рәшит, янабыз, чык тизрәк!» – дип кычкырдым. Әле бабайның колагы да ишетми, аппарат белән йөри. Ике-өч минутка соңарсам, ялкын ишекне дә чолгап аласы икән...

Әби һәм бабай шулай могҗиза белән исән кала. Монда тагын гаҗәп бер нәрсә бар: ничектер Гөлминур апаның кулына намазлыгы эләгә. Югыйсә янгын башланган минутта ул чәй әзерләп йөри, намаз укымый.

– Аны миңа фәрештәләр биргәндер, – ди Гөлминур апа. – Өйне янгын чолгап алганда, намазлыгымны тотып басып тордым. Үзем дога укыдым. Аллаһы Тәгаләдән: «Акылларыбызны җуйдырма», – дип сорадым.

– Безнең йортка күз тигәндер, – дип сүзгә кушылды Рәшит абый. – Бөтен җирне ялт иттереп яңартып куйган гына идек. Барысы да санаулы минутлар эчендә янып бетте. Инде мондый яңа йорт турында хыялланмадык та. Йортны иминиятләштермәгән дә идек. Рәхмәт балаларга, курыкмыйча эшне башладылар. Әле 300 мең сум кредит түлисебез бар. Ничек тә шуны түләп бетергәнче яшисе иде (көлә – авт.).

Әби белән бабай балаларында яшәргә дә риза була. Ике ул, бер кызлары бар. Ләкин балалар төп нигезләре таркалуын теләми. Ике ай дигәндә, кирпечтән җыйнак кына йорт салып куялар. Янәшәдә мунчасын да өлгертәләр. Хәзер бу нигездә янгын булган димәссең. Әллә ничә йөк машинасы кара туфрак керткәннәр, чәчәкләр үсеп утыра.

– Сабантуй көнне күчендек, – диде Гөлминур апа. – Йортны салырга булышкан авылдашлар бәйрәмнән туры безгә кайтты. Бөтен авыл ярдәмгә килде. Рәхмәтләр укый-укый елыйм. Хәким Хадиуллинга аеруча зур рәхмәт. Йөз мең сум акчасын да бирде, йөк машиналары белән туфрак та кайттартты, нәрсә кирәк, шуның белән булышты. Әле аш укытканда күп итеп тагын ит тә кертте. Аллаһы Тәгалә барчасына да исәнлек бирсен, юллары хәвеф-хәтәрсез булсын.

АТА-БАБА НИГЕЗЕ, ДИП...

Балыклыда тагын бер күркәм кеше – Хәмдия апа Хадиуллина белән таныштык. Авылның остабикәсе ул. Мәчеттә хатын-кызларга дин гыйлеме дәресләре укыта. Туган авылына яшәргә лаеклы ялга чыккач кына кайткан. Дөрес, бөтенләйгә дип түгел, вакытлыча, әнисен карарга дип. Һәм шуннан янә Казанга китә алмаган.

Гомер буе шәһәрдә яшәгән димәссең мине, – диде Хәмдия апа. – Казанга барсам, тизрәк авылга кайту җаен карыйм, һава җитми. 1995 елда әни кинәт кенә авырып китте, алты ел аны карадым. 2001 елда җирләдек. Шул вакыт эчендә дингә килдем, мәдрәсәдә белем алдым.

Хәмдия апа әнисен караганда үзенә тагын бер шөгыль таба: курчакларга күлмәкләр бәйли. Аларның ниндие генә юк: татар халык киемлесе, заманча, җәйге, кышкы... Иллеләп курчагы бар.

– Хәзер бәйләмим инде, – диядия, бер-бер артлы курчакларын чыгарды Хәмдия апа. – Вакыт та калмый, күзләр дә начарлана, бәйләү икенче планга күчте. Әни белән утырганда бу шөгыль миңа бик булышты, күңел дә үсә, вакыт та уза. Бәйләгәннәремне әнигә күрсәтәм. Ул да сөенә. Хәзер исә курчаклар белән кайткан вакытта оныклар уйный. Төрле күргәзмәләргә алып баралар.

– Нишләп олылар өчен бәйләмәдегез, ә курчаклар өчен? – дим.

– Үзем дә белмим. Өйдә бер курчак бар иде. Киеме бик начар булгач, шуңа күлмәк бәйләп киерттем. Кызык булып китте. Аннан икенчесен бәйләдем. Моны күреп күршеләр дә курчакларын алып керә башлады. Шулай итеп бер мәлне «курчакка күлмәкләр бәйләүче» дип дан казандым. Бәйләү чир кебек ул, бер башласаң, ташлап булмый.

Хәмдия апа әтиләре яшәгән әлеге нигездән чыккан кешеләрне ел саен җыеп Коръән ашы укыта. Бөтен туганнары кайта икән.

– Нигез хәзер минем карамакка калды, – ди Хәмдия апа. – Бу бик зур җаваплылык. Йортны карап тору бер хәл, әрвахлар өчен догада булу да бик мөһим. Ата-баба нигезе – ул бик зур әйбер. Анда кеше яшәмәгән очракта да кайтып, йортны чистартып, Коръән укыту кирәк.

Киләчәк яшьләр кулында, дияргә яратабыз. Балыклының киләчәге, һичшиксез, өлкәннәр кулында (Авыл өчен җан атып торучы тагын берничә кеше белән таныштык). Алар исән-имин булганда, Балыклыда азан тавышы да яңгырар, урамнар да буш тормас. Ә берәр проблема чыга калса, алар аны чишү җаен да, һичшиксез, табар...

3. – Йортны салырга булышкан авылдашлар бәйрәмнән туры безгә кайтты. Бөтен авыл ярдәмгә килде, – ди Рәшит абый белән Гөлминур апа.

4. Хәмдия апа әнисен караганда үзенә тагын бер шөгыль таба: курчакларга күлмәкләр бәйли.

PRESSA.RU

«Рәхмәт» сүзен ишетүдән дә рәхәте юк»

Алмалар әй уңганнар,
Кызарышып тулганнар,
Балга манып алганмыни,
Шундый татлы булганнар, –

дип яза шагыйрә Резеда апа Вәлиева. Язның салкын килүенә карамастан быел алма уңды. Җәйге алмаларны күптән ашап, эшкәртеп бетердек инде. Ә менә көзге, соң өлгерә торган сортларны җыю, урнаштыру мәшәкатьләре тулы көченә бара. Кемдер алмадан кайнатма, компот эшли, икенчеләр аны киптерә. Без исә редакциябез кухнясында алмадан как ясарга булдык.

Автор:
Руфия Фазылова

«КӨН АРАЛАШ КАК ЯСЫЙМ»

Как ясаучылар шактый күп икән. Кайберләре белән аралашып карадым: «Мин оста түгел, үзебез өчен генә ясыйм», – диләр, икенчеләре исә: «Безнең как кибеп бетми», – диде. Ә менә Казанда яшәүче Рафыйк абый белән Рузалия апа Мөбәрәкшиннар как ясау сере белән уртаклашырга бик теләп ризалашты.

– Аның бер авырлыгы да юк, алма белән сок кайнаткыч (соковарка) булса, шул җитә, – диделәр. Мөбәрәкшиннар гадәттә какны икәү ясый икән. Рузалия апа алманы юа, дүрткә бүлә, эчен ала. Аннан сок кайнаткычка куя. Калган эш – Рафыйк абый җаваплылыгында.

– Как ясамыйча берничә көн торсам, күңелгә нидер җитми башлый, – диде Рафыйк абый. – Алма булганда көн аралаш как эшлибез.

– Алайса какны сатасыздыр? – дим.

– Юк, сатмыйбыз, күчтәнәчкә өләшеп бетерәбез.

– Тәмам сүзсез иттегез, – дим мин, берара тын торгач.

Баштагы мәлне Рафыйк абыйның бу сүзен аңлап бетермисең. Ничек инде кешегә таратыр өчен көн аралаш как ясап була? Соңрак, эш барышында, Мөбәрәкшиннар белән якыннанрак танышкач, моның сере аңлашыла...

Какны Рафыйк абый белән Рузалия апа күптәннән ясый икән. 1985 елны Лагерная бистәсендә бакча сатып алгач, алмарын кая куярга белмәгәннән башланган эш.

– Ак алмалар өлгерә башлагач, июльдән октябрь азакларына кадәр как ясыйбыз, – ди Рузалия апа. – Үзебезнең алмалардан тыш күршеләр, туганнар да капчык-капчык алма китерә. Аның бае аларга әзер как бирәбез. Рафыйк эштән кайтканчы алмаларны чистартып куям. Как ясаганда иң төп эш – пешкән алманы сөзгечкә салып төю. Шактый вакытны ала ул. Ирем пөхтә, бар эшне җиренә җиткереп башкаручы буларак, моны бик яратып эшли. Миңа бөтен әйбер тиз кирәк, алма төйгәндә түземлелек җитми.

Фото: Лилиана Вәлитова

РАФЫЙК МӨБӘРӘКШИННАН КАК РЕЦЕПТЫ:

1. Алма – 3 кг
2. Шикәр комы – 0,2 кг
3. Алма согы – 0,4 – 0,5 л

КАКТАН РУЛЕТ ЭЧЛЕГЕ РЕЦЕПТЫ:

Башта 200 г сары җимеш белән 200 г кара җимешне иттарткычтан чыгарырга. Аннан җимешләрне куертылган сөт белән бутарга. Яраткан кеше әстерхан чикләвеге дә өсти ала.

PRESSA.RU

– Куллар өчен хәрәкәт ул, – дип сүзгә кушылды Рафыйк абый. – Эштән кайтып ашап-эчеп алгач, шәһәр кешесе нишли? Әйе, телевизор карый. Мин дә шулай итәм, тик телевизор караганда кулны буш тотмыйм, шул гына.

– Мастер-классны алайса Рафыйк абый күрсәтә инде? – дим.

– Күрсәтсен, ул ясаган как тәмлерәк, нәзегрәк була, – диде Рузалия апа. – Мин ярдәм итеп торучы гына...

«КАБЫК ӘРЧЕП УТЫРАСЫ КИЛМИ»

Сок кайнаткычта алмалар ярты сәгать чамасы пешә. Аны, капкачын ачып, унбиш-егерме минут суытып алу мөһим икән. Сөзгечкә салып төйгәндә пешмәс өчен кирәк бу. Алмалар суынган арада Рафыйк абый безне балконына алып чыкты. Аерым бер «цех» монда: куна такталары кую өчен өстәлләр тезелгән. Берьюлы алты-җиде такта как кибеп утыра.

– Көн кояшлы, җиләс булса, как ике көндә кибә, – ди Рафыйк абый. – Ә торбаларга җылы биргәч, какларны өйгә алып керәбез. Кайбер кешеләр пешкән алма массасын табага салып духовкада да киптерә икән. Мин алай яратмыйм, яна, көя дигәндәй. Куна тактасында җайлырак бит, карап торасы да юк.

Рафыйк Мөбәрәкшин, лаеклы ялда булса да, һаман хезмәттә әле. Казан вертолет заводында эшли. Эш стажы 40 елдан артып киткән. Төгәл, пөхтә, шул ук вакытта иҗади кеше ул. Эштән бушаган вакытта агачтан бизәкләп сыерчык оялары, йорт-кирәк яраклары эшли икән. Үзе әйткәнчә, тик тора белми. Как ясау остасы белән янәдән аш бүлмәсенә кердек. Алмалар суынып өлгергән. Рафыйк абый аларны сок кайнаткычтан алып сөзгечкә тутырды. Һәм агач тукмак белән төя башлады.

– Моны икенче төрле дә эшләп була, – ди Рафыйк абый. – Алмаларны пешергәндә кабыгын әрчеп салсаң, болай утырмыйсың. Чистартылган алмаларны төюе дә күпкә җиңелрәк һәм тизрәк, тик мин үземчә эшләргә өйрәнгән инде. Кабыгын әрчеп утырасым килми.

Рафыйк абый пешкән алмаларны якынча ярты сәгатьләп төйде. Сөзгеч аша алманың төше, кабыгы чыгарга тиеш түгел икән. Югыйсә как тигез булып кипми, матур да түгел, диләр как осталары. Ул арада какның файдасы турында да бәйнә-бәйнә сөйләде:

– Яман шеш авыруыннан интеккән тынышларым бар, алар янына хәл белергә барганда һәрвакыт как алып барам. Аппетитны күтәрә ул, көч кертә. Алмада кеше организмы өчен кирәкле бик күп витаминнар, углеводлар бар. Шуңа да авыру кешеләр өчен файдасы күп аның. Хәтта туганнар, дуслар да үзләренең танышларына сорап алалар. Авыру кешегә дип какны сатып биргәнем юк, савап булсын дим. Шифасы тисен. «Рәхмәт» сүзен ишетүдән дә рәхәте юк.

– Ашларга чакырсалар, без гел кактан рулет ясап барабыз, – дип сүзгә кушылды Рузалия апа. – Аш үткәрүчеләр безнең әлеге ризыкны алып киләсебезне алдан белеп тора, әйтмәсәк тә. Рафыйкка бүләргә дә кушалар әле.

– Бу аерым осталык сорый, – дип елмая Рафыйк абый. – Үткен пычак белән нәзек итеп кисәргә кирәк. Какның тәме шул очракта гына беленә. Аннан, юка рулетны ашарга да җайлырак.

– Какны алмадан гына ясыйсызмы?

– Нәрсә бар – шуннан. Мин карлыганнан ясалган какны яратам. Иң тәмлесе шул кебек. Карлыган кагын ясау җиңелрәк тә, турап утырасы юк. Узган ел күп итеп сливадан эшләгән идек. Быел слива булмады.

«БЕР КАЗАНГА ИКЕ БАШ СЫЙМЫЙ»

Ир-атның аш бүлмәсендә ризык әзерләгәнен күзәтергә яратам. Алар моңа җаваплырак якын килә, димме. Әнә, Рафыйк абый алмаларны ничек пөхтә итеп сөзгечтән чыгарды. Шуңа бер стакан шикәр комы һәм ярты литрлы банка белән сок кайнаткычтан чыккан алма согын салып болгатты. Аннан әзер массаны духовкага куйды.

– Алманы әрәм итмибез, – ди Рафыйк абый. – Пешкән алмадан как ясасак, согын стерильләштерелгән банкаларга тутырабыз. Кыш буе файдалы, натураль сок эчәбез.

– Өч кило алмадан күпме сок чыга? – дим.

– Литр ярым чамасы. Алмасына, сезонына карап инде.

– Сөзгеч аша төелгән алманы духовкага куймасаң ярамыймы?

– Хатыным алай эшләп тормый, иренә, – дип шаяртып алды Рафыйк абый.

Ә Рузалия апа, aклангандай:

– Миңа тиз кирәк, духовкада пешереп алмасаң да, как була бит, – дип куйды.

Безнең халык: «Бер казанга ике баш сыймый», – дияргә ярата. Мөбәрәкшиннарны аш бүлмәсендә шулкадәр күңелле: ир белән хатын бер-берсен чеметтереп тә ала, ләкин монда бер самимилек, җылылык бар. Кырык елга якын бергә яшәгән бу икәү бер-берсен күз карашыннан да тоярга өйрәнгән. Бер ул, бер кыз үстергәннәр. Өч оныклары бар.

– Бүген оныклар дип яшибез, – дип сөйләде Рузалия апа. – Аларны мәктәптән алып кайту, түгәрәкләргә йөртү – минем өстә. Шуңа күрә эштән киттем. Пенсиядә бит, хәзер балаларга булышырга кирәк.

Рафыйк абый духовкадан алманы алды. Сөзгеч аша чыгырылган массаның төсе үзгәреп, куерып киткән. Аш бүлмәсенә гаҗәеп бер тәмле хуш ис таралды.

– Иң яратканы менә шушы эш, – дип, Рафыйк абый куна тактасын өстәлгә куйды, кырыйларын сыек

май белән майлап алды. Һәм алма массасын аш кырәге белән такталарга салып чыкты. Аннан иплән кенә җәя башлады.

– Миңа бу төзелеш эшен хәтерләтә, цемент измәсен җәйгәндәй булам, – ди Рафыйк абый.

Чынлап та, как ясау остасы моны шулкадәр тәмләп башкара ки, берәр мөһим сызым яки проект эшли диярсең! Югыйсә как кына җәя бит!

– Ә хәзер бер фокус күрсәтәм, – дип, Рафыйк абый юеш как җәелгән куна тактасын күтәрде. Әйләндереп, тулгандырып та карады. Алма массасы тактадан төшми.

– Чынлап та фокус бу! – дим, исем китеп.

Рафыйк абый, горурлык белән:

– Ә менә Рузалиянең алма массасы тактага алай ябышып тормый, – дип елмайды. – Духовкада күпертеп алганга шулай була, дип уйлыйм.

Һәм Рафыйк абый егетләр җитезлеге белән алма җәелгән куна тактасын балконга алып чыгып китте. Ул да түгел, кулына икенче такта тотып янә аш бүлмәсенә килеп керде.

– Монысы әзере инде, кипкәне, – диде.

Какны куна тактасыннан каеру тагын бер эш икән. Башта аның иплән кенә кырыйларын пычак белән кубарасың. Аннан әкренләп тартасың.

– Ничә ел ясап, какның куна тактасыннан каерылмаган чагын белмим, – диде Рафыйк абый, эшеннән бүленмичә генә. – Әлбәттә, ул кипкән булырга тиеш.

«ТАТАР ТЕЛЕН ЛИТВИНОВ БУЕНЧА ӨЙРӘТТЕМ»

Эш беткәч, Рузалия апа чәй өстәле янына чакырды, кактан авыз итеп карарга. Безгә дип үзенең «фирменный» тортын да пешергән.

Дөресен әйтим, какка исем китми. Авыз итеп карарга була, әлбәттә. Мөбәрәкшиннар кагын да «яхшы түгел» дип кенә авызга капкан идем... искиткеч. Беренчедән, как бик юка. Яңа гына эшләнгәнгә күрәме, бик тәмле. Бер әчесе юк.

– Шикәр комы да күп салмыйсыз. Ничек сезнең как баллы килеп чыга? – дим.

– Бу баллы алмадан ясалган как, – ди Рузалия апа. – Алма әчерәк булса, шикәр комын күбрәк салырга кирәк.

Рузалия Мөбәрәкшина дүрт дистәгә якын ел балалар укыткан. Башта Казан шәһәренең 42нче училищесында эшләгән. Студентларга тегү эшен өйрәткән. Ә аннан, училищены ташлап, мәктәпкә – хезмәт укытырга киткән.

– 1991 ел иде ул, – ди Рузалия апа. – Улыбыз Гадел беренче сыйныфка укырга керде. Болгавыр заманнар, улыма күз-колак булырмын дип, мәктәптә хезмәт дәресе алып барырга алындым. 1992 елда мәктәпләрдә татар теле укытыла башлады. Ләкин шуның белән бергә бик күп проблемалар да барлыкка килде: дәресләрнең юклыгы бер хәл, татар телен белгән укытучылар юк. Ни өчендер бу эшне миңа йөкләделәр. Татарча сөйләшсәм дә, телне камил беләм дия алмыйм. Балаларга ана телебезне өйрәтү шулкадәр ошап китте ки, төрле курсларга йөри башладым. Татар теле укытучылары белән таныштым. Шундый бер очрашуда Игорь Литвинов белән күрештем. Ул заманда аның исеме аерым даирәләргә билгеле иде. Милләте буенча яһүд булган әлеге мөгаллим гомере буе институтта студентларга инглиз теле укыткан. Һәм инглиз методикасы нигезендә татар телен үзлегеннән өйрәнгән.«Оныгым татар телен укый башлагач, мин дә кызыксынып киттем», – дия иде Игорь Львович.

Гаҗәеп акыллы, тыйнак кеше иде ул. Литвинов методикасы, нигездә, балаларны татарча сөйләшергә өйрәтүгә корылган. Төп максат: укучылар гади сорауларга җавап бирә алсыннар. «Татар теле программасы катлаулы, аны телне камил белгән кешеләр үз каланчаларыннан фикер йөртеп төзегәннәр», – дия иде ул. Һәм моның белән килешми мөмкин түгел. Ә Литвинов методикасы башта балаларга – сүз, аннан сүзтезмә, соңыннан гына җөмлә ясарга өйрәтүгә корылган. Кызганыч, аның методикасы тулысынча уку-укыту программасына кереп китә алмады, бәлки бүген балаларыбыз татарчаны яхшырак белгән булырлар иде. ▪

1. Алманы бүләбез!

2. Пешерергә утыртабыз!

3. Төябез!

4. Шикәр комы салабыз!

5. Алма согы өстибез!

6. Духовкага куябыз!

7. Тактаны майлыйбыз!

8. Җәябез!

9. Пычак белән кубарабыз!

10. Төрәбез!

PRESSA.RU

Алмыш хан. X гасырның беренче чиреге.
Рәссам: Ф.Халиков.

АЛТЫН УРДА ҺӘМ ТАТАРЛАР

Татар халкының килеп чыгышы, этнос буларак формалашуы турында берсеннән берсе төрле фикерләр фәнни әдәбиятта XVIII йөздә күренә башлый, һәм бу проблема буенча кайнар бәхәсләр галимнәр арасында әле бүген дә тынып тормый. Күренекле татар галиме Альфред Халиковның моннан нәкъ чирек гасыр элек чыккан «Без кем – болгармы, татармы?» дигән китабы фәнни җәмәгатьчелекне дә, киң катлау укучыларыбызны да кызыксындырган әлеге мәсьәләгә игътибарны тагын да көчәйтеп җибәрде. Соңгы елларда бу өлкәдә галимнәребез уңышлы эшләде, әмма әле чишелмәгән проблемаларыбыз да җитәрлек.

Автор:
Фаяз Хуҗин

АЛТЫН УРДАНЫҢ ТАТАР ТАРИХЫНДА ТОТКАН УРЫНЫ

Миңа калса, соңгы елларда басылып чыккан фәнни хезмәтләрдә Алтын Урда дәүләтенең татар тарихында тоткан урыны бераз идеаллаштырылып һәм күпертелеп, ә татар-монголлар явы вакытында юкка чыгарылган Идел Болгары дәүләте һәм аның төп халкы булган болгарларның роле, киресенчә, кимсетелеп, кечерәйтеп күрсәтелә. Алтын Урда цивилизациясе булган – бу хәзер галимнәр арасында бәхәс уятмый торган тарихи факт. Әмма монгол-татар яуларына кадәр югары үскән Болгар цивилизациясе дә булган ич. Бу фактны да инкарь итеп булмый. Кайчандыр Болгар дәүләте урнашкан Урта Идел һәм Кама буйлары хәзер дә татарларның күпләп утырган җирләрен тәшкил итә. Болгарлар шул ук җирләрдә ике гасыр чамасы, 1236 елдан башлап, монгол-татарлар төзегән дәүләт составында яшәргә мәҗбүр ителәләр, аннан соң, Алтын Урда дәүләте таркалгач, 1437–1445 еллар аралыгында оешкан Казан ханлыгында яшиләр.

Хәзерге татарлар – башлыча Бату хан гаскәрләре белән килеп, үзләре яулап алган Көнчыгыш Европа далаларына таралып утырган, аннан соң безнең якларга – Идел-Кама буйларына килеп төпләнгән төрки-татар кабиләләре, дигән концепциянең авторлары болгар бабаларыбызның тарихын XIV гасырның урталарына кадәр китереп җиткерәләр дә, аннан соң аларны бөтенләй «юкка чыгаралар». Янәсе, болгарларның күп өлеше 1236 елгы монгол-татар яулары вакытында һәлак булса, калган өлеше исә XIV гасырның урталарында бөтен Урда территориясендә генә түгел, хәтта Көнбатыш Европа илләрендә дә таралган коточкыч үләт (чума) пандемиясе вакытында кырылып беткән. Болгар телен татар теле алмаштырган, имеш. Америкада яшәп иҗат итүче татар галиме, профессор Юлай Шамилоглының җиңел кулы белән фәнни әйләнешкә кергән һәм рәсми басмаларда да еш кулланыла торган әлеге концепциягә мин шикләнеп карыйм. Ни өчен дигәндә, әллә нинди канкойгыч сугышлар нәтиҗәсендә дә халыкны соңгы кешесенә кадәр кырып бетереп булмый. Тарих мондый фактларны белми. Каты сугышлар вакытында бәлагә дучар булган халык качып котылуның төрле юлларын таба, ахыр чиктә, башка, тынычрак төбәкләргә күчеп китәргә мөмкин.

Ә үләт эпидемиясенә килгәндә, эш болайрак тора. Ул Кытай һәм Һиндстан җирләреннән килеп чыга һәм тиз арада Сүрия, Кече Азия, Мисыр кебек дәүләтләргә тарала, тиздән Кырымга килеп җитә, аннан Көнбатыш Европа җирләренә күчә. 1351 елда үләт чире, Балтыйк буе илләреннән килеп, Псков халкын кыра, ике елдан соң Мәскәү кенәзлеген чолгап ала. Әлеге эпидемия соңыннан, нишләптер Түбән Новгородны урап үтеп, көньяк далаларына тарала. Болгар җирләренә килеп җиткәнме әлеге афәт? Бу турыда тарихи чыганаклар юк дәрәҗәсендә. Шулай да рус елъязмасында бер хәбәр урнаштырылган бугай. Димәк, үләт чире Болгарны читләтеп узган дип әйтә алмыйбыз.

Ярар, шулай да булсын ди. Әмма бит Урта Идел һәм Кама төбәкләрендә болгарлардан тыш башка халыклар да яшәгән. Нишләп соң алар кырылып бетмәгән? Мордвалар, мәсәлән, Урданың үләт чире котырынган үзәк җирләренә якынрак та урнашканнар – исән калганнар бит! Аңлашылып җитми. Галимнәрнең күпчелеге, әлеге коточкыч афәт нәтиҗәсендә хәтта үләт чире иң күп таралган Көнбатыш Европа илләрендә дә халыкның 25–30 проценты гына (бу да бик зур сан, әлбәттә) үлгән, дигән фикердә тора.

АРХЕОЛОГИЯ МАТЕРИАЛЛАРЫ НИ СӨЙЛИ?

Бу хакта археология материаллары ни сөйли? Үләт зәхмәте вакытында һәлак булган кешеләрнең коллектив каберлекләре табылмаган әлегә. Ә менә болгарларның Алтын Урда чорында да, Казан ханлыгы җирлегендә дә исән-имин яшәп ятулары турындагы материаллар бихисап.

Фотолар автордан алынды

Монгол-татарлар тарафыннан Болгарның алынуы. Рәссам: Ф.Халиков.

Монгол-татарларга кадәрге болгарлар тарафыннан кулланылган, калыплашкан чүлмәк ясау, кара һәм төсле металл, шул исәптән зәркән әйберләре җитештерү, сөяк һәм тире эшкәртү ысуллары Алтын Урда чорында да, Казан ханлыгы чорында да сакланып кала, традицион технологияләр онытылмый. Болгарларның төп шөгыле булган игенчелек тә юкка чыкмаган, әлбәттә. Күчмә терлекчелектән башканы белмәгән Монголия татарлары, безнең якларга килеп, тиз арада утрак тормышка күчкәннәр һәм иген игә башлаганнар, дип уйларга нигез юк.

Язма чыганакларда безне кызыксындырган сорауга җавап бирердәй хәбәрләрне күпләп табарга мөмкин. Кайберләрен генә искә төшереп үтик. Рус елъязмачылары XVI йөздә дә Казан ханлыгының төп халкын болгарлар дип атыйлар, ә Мәскәүнең бөек кенәзе Иван III исә, 1487 елда Казан ханлыгы өстеннән протекторат урнаштыргач, үзен «Болгар патшасы» дип игълан итә. Ханлыкның мәшһүр шагыйре Мөхәммәдъяр «Төхфәи мәрдан» поэмасында татарларга тискәре мөнәсәбәтен белдерә һәм үзен болгар халкының бер вәкиле дип саный. Шунысы да игътибарга лаек: әле XVII–XVIII гасырларда да Болгар дәүләтен һәм Казан ханлыгын яңадан торгызырга теләп, татарларны патша самодержавиесе үткәргән милли-колониаль изүгә каршы баш күтәрергә өндәүче каһарманнар табылып торган. Кыскасы, «болгар бабаларыбыз» татарларның милли үзаңында ныклы урын алган – бу өстәмә исбатлауны таләп итми торган тарихи факт.

НИ ӨЧЕН БЕЗ БОЛГАР ТҮГЕЛ, Ә ТАТАР?

Ул чакта нишләп соң безне болгарлар дип түгел, ә татарлар дип атыйлар? Хәзер шул сорауга җавап бирергә тырышырбыз. Моның өчен безгә тагын да борынгырак чорларга сәяхәт кыларга кирәк булыр.

Озак вакытлар без, тарихка татарлар исеме белән кереп калган борынгы кабиләләр иң әүвәл Төрки каганатлар чорына караган Күлтәгин, Тоньюкук, Билге каган исемле хәрби җитәкчеләр һәм юлбашчыларның кабер ташларына рун хәрефләре белән уеп язылган эпитафияләрдә телгә алына дип йөри идек. Әлеге ташлар VIII гасырда куелганнар, әмма татар кабиләләре («отуз татарлар», «токуз татарлар») VI гасыр уртасында булып үткән вакыйгаларны тасвирлаганда төркиләргә буйсынган кабиләләр исемлегендә «күренеп китәләр». Атаклы рус галиме профессор Сергей Кляшторный фикеренчә, *сюнну/хунну* кабиләләренең бер тармагы булган жуаньжуаньлылар, ихтимал, татарларның борынгы бабалары булгандыр, чөнки аларның, жуаньжуаньлыларның, икенче исеме кытай язмаларында сакланып калган – *датань/таньтань*. Иероглифлар белән язылган *датань/таньтань* сүзе *дадар/татар* рәвешендә әйтелгәндер, дип фаразлый белгечләр. Ә Датань, беләсегез килсә, – жуаньжуаньлыларның «җиңелү белмәс» юлбашчысы исеме. Халыкның исеме атаклы юлбашчылары исеме белән тәңгәл килгән очраклар тарихта мәгълүм нәрсә (мәсәлән, ногайлар, үзбәкләр). Шулай икән, *татар* этнонимының этимологиясе дә ачыклана дигән сүз. Әмма боларның барысы да әле галимнәрнең фараз дәрәҗәсендәге фикерләре генә.

Үзәк Азия далаларында күчмә тормыш алып барган борынгы татарлар турында төп мәгълүматны XIV гасыр фарсы тарихчысы Рәшид әд-Диннең «Җәмиәт-тәварих» («Гомуми тарих») исемле фундаменталь хезмәтеннән таба алабыз. Әлеге хезмәттә башлыча Чыңгыз хан һәм аның басып алу сугышлары, Монгол империясен төзүче ханнарның тарихы яктыртыла, әмма татар тарихына караган мәгълүматлар да бар. «Татарларның исеме элекке заманнардан ук дөньяга таралган иде, – дип яза Рәшид әд-Дин. – Аларның төп яшәү урыны – Буир-Нур күле тирәсендә (Көнчыгыш Монголия. – *Ф.Х.*). Әлеге кабиләләр бер-берсе белән еш кына сугышып торганнар». Шулай булуга да карамастан, дип дәвам итә Рәшид әд-Дин, алар монголларны үзләренә буйсындырап тоттылар. «Татарлар – күпсанлы халык, әгәр дә алар үзара дошманлыкларын бетереп, дус һәм бердәм булсалар, аларга кытайлылар да, күршеләрендәге башка кабиләләр һәм өлкәләр дә каршы тора алмаслар иде. Әле болай да алар әллә никадәр халыкны үзләренә караттылар. Татарларның чиксез бөеклеге, куәте, башка кабиләләрнең аларга булган хөрмәте нәтиҗәсе буларак, бик күп төрки ырулары аларның исемен

Идел буе Болгарстаны сугышчысы. XII гасыр – XIII гасыр башы. Реконструкция: О.Фёдорова.

PRESSA.RU

Беләзекләр. Алтын-көмеш.
ТР Милли музеенда саклана.

Йөзекләр. Көмеш.
ТР Милли музеенда саклана.

Болгар хатын-кызы костюмы. VIII–X гасырлар. Реконструкция: О. Гасимова.

үзләренә алдылар һәм татарлар дип атала башладылар». Әмма соңыннанрак, XIV йөздә, шул ук кабиләләр, монголларның көчен-гайрәтен күреп, исемнәрен «монгол»га алыштырдылар, дип тәгәлли Рәшид әд-Дин борынгы татар тарихына кыскача экскурсны.

ТАТАР КАБИЛӘЛӘРЕ

Әлеге экскурста безнең игътибарны җәлеп итәрлек тагын бер мөһим мәгълүмат бар: «Үзләренең гаскәрләре һәм патшалары булган данлыклы татар кабиләләренең саны – алты». Әлеге язмадан татарларның алты дәүләте булуы аңлашыла. Аларның берсе Буир-Нур күле тирәсендә урнашкан, калганнарының урнашкан урыны күрсәтелмәгән. Рун язмаларындагы мәгълүматларга караганда, VI гасырның икенче яртысында һәм VII гасырда татарлар, кыргызлар белән берлектә, Төрки каганатына каршы сугышалар. 840 елда алар уйгырларга каршы күтәреләләр, әмма җиңеләләр. 842 елда исә, киресенчә, татарлар кытай чыганакларында кыргызларның дошманы һәм уйгырларның союздашлары рәвешендә телгә алыналар. Бераздан уйгырлар да, татарлар да кыргызларның җиңүен танырга, аларга ясак түләп торырга мәҗбүр булалар.

IX–X гасырларда татар кабиләләре Төньяк Кытай белән Көнчыгыш Төркестан арасындагы иксез-чиксез далаларда күчмә тормыш алып барганнар, үзләренең хәрби активлыкларын беркайчан да югалтмаганнар. XI гасырда яшәгән фарсы тарихчысы әл-Гардизи язмаларына караганда, татарлар Иртеш буйларында кимаклар дәүләтен оештыруда да турыдан-туры катнашалар. Үзара сугышларда җиңелгән татарларның бер төркеме төньяк-көнбатыш тарафына, Иртеш елгасының югары агымы тирәсендәге җирләргә килеп урнаша, һәм алар бирегә кимаклар дәүләтенең башында торган татар династиясенә нигез салалар.

Төньяк Кытай белән Көнчыгыш Төркестан арасындагы татарлар күпләп урнашкан җирләр тарихка «Татар даласы» исеме астында кереп калган. Бирегә яшәгән башка халыкларны, шул исәптән монгол кабиләләрен дә, татарлар дип атаганнар.

Урта гасырлар чорында яшәгән дала халыкларының тулы һәм дөрес тарихын язу искиткеч катлаулы эш. Төрле телләрдә сөйләшүче кабиләләр үзара сугышып торганнар, еш кына җиңелгән кабилә җиңүчесенең исемен кабул иткән. Кабиләләрнең яшәү урыннары да гел алмашынып торган.

XII йөз ахырларында Үзәк Азия далаларында көн күрүче кабиләләр арасыннан монголлар күтәрелә башлый. Тимучин гаскәрләре татарларны тулысынча үзләренә буйсындыралар. 1206 ел корылтаенда элегрәк татарлар тарафыннан үтерелгән Есугәй-багатурның улы Тимучин Чыңгыз хан исеме белән Монгол дәүләтенең олуг ханы итеп сайлана. Татарларның күбесен ул үтертә, әмма аларның искиткеч батыр сугышчы булуларын да таный, шуңа күрә тәҗрибәле татар гаскәриләрен киләчәк сугышларда файдаланырга карар кыла.

1207 елда Чыңгыз хан башлаган яулап алу сугышлары 1223–1240 елларда аның оныгы Бату хан тарафыннан Көнчыгыш Европа территориясендә дәвам иттерелә. Ни гаҗәп, Европада «монгол» түгел, «татар» исеме тарала башлый. Моның сәбәбен XIII гасыр сәяхәтчесе Гильом Рубрук аңлатып бирә: «Чыңгыз (соңыннан аның уллары һәм оныклары. – Ф.Х.) сугышка керүче гаскәр башына татарларны куя торган була, һөҗүмгә дучар ителгәннәр аларны: «Әнә татарлар килә», – дип кычкырып каршы алганнар, шуңа күрә татар исеме тиз тарала». Соңыннан яулап алынган җирләрдә калкып чыккан Алтын Урда дәүләтенең халкын да гомумиләштереп татарлар дип йөртә башлыйлар. Әлбәттә, җиңелүгә дучар булган болгарлар, кайберәүләр уйлаганча, үзләренең асыл исемнәреннән баш тартып, «татар» исеменә тиз генә күчмәгәннәр. Аларны монгол-татарлар кул астына кермәгән күршеләре шулай атаган. Билгеле булганча, әле XIX гасырда да татарлар үзләрен «мөселманнар» яисә «болгарлар» дип атауны мәгъкуль күргәннәр. Алтын Урда дәүләте составында татар халкының этнос буларак формалашуы тәмамланмый, бәлки дәвам итә. Болгарлар составына тугандаш кыпчаклар килеп кушыла, әлбәттә, татар-монголларның да ролен инкарь итәргә ярамый. Әмма ни генә булмасын, галимнәрнең фикеренчә, бүгенге татарларның антропологик үзенчәлекләре монголоид татарлардан түгел, европеоид болгар бабаларыннан килә.

Сәмига Сәүбанова 1946 елның 20 маенда Татарстанның Актаныш районы Югары Яхшый авылында туып-үскән. Урта мәктәпне тәмамлагач, КДУның татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Хезмәт эшчәнлеге төрле тармакларга карый: авылда – клуб мөдире, район газетасында – тәрҗемәче, әдәби мөхәррир, мәктәптә – укытучы, балалар бакчасында –тәрбияче, заводта – эшче-аппаратчы. «Казан утлары» журналында секретарь-машинистка булып эшли, Республика халык иҗаты һәм мәдәни-агарту эшләре фәнни-методик үзәгендә – өлкән белгеч, «Татар иле» газетасында хәбәрче вазыйфаларын башкара. Балалар һәм өлкәннәр прозасы, драма әсәрләре яза. «Өметем зур минем», «Яшьлегемнең моңсу җыры», «Яңа ел кичендә», «Яктылык ничек тарала?», «Тылсымлы бакча», «Болытның койрыгы кайда?» һ.б. китаплар авторы. Матбугатта мәкаләләре даими басылып тора. 2000 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

«Татарстан» журналының әдәби премиясе

Сәмига Сәүбанова

Тыкрык иясе

***

Хәйретдин теге яки бу сәбәп белән онытылып калган хуҗалык өчен кирәк-ярак әйберләрне тапса, ихатасы янындагы тыкрыкка алып кайтып куя торган иде. Ул әйберләрне йә хуҗалары килеп ала, ә ияләре табылмаганнарын үзләренә кирәк кеше алып китә. Авылдашлары, аның бу гадәтеннән көлеп, уены-чыны белән:

– Тыкрык иясен үзеңә ияләштереп бетерәсең инде, – диләр иде. Хәйретдин ул әйберләрне беркайчан да үз ихатасына алып кермәде, хуҗалыкта бик ярардайларын да үзләштермәде.

– Сынаганым бар, тапканны үземә алсам, күбрәк югалтам, – ди торган иде.

Бервакыт Хәйретдин исле мунчада чабынганда чак кына үлмичә калды.

Ул үзенең ләүкәдә чабынганын хәтерли, ә менә ничек итеп ишекне ачып, салкын карга чыгып ауганын барыбер исенә төшерә алмады. Бу аның өчен генә түгел, бүтәннәр өчен дә аңлашылмый торган сер булып калды.

Күпне күргән өлкәнрәкләр:

– Тыкрык иясе эше бу, бүтән беркемнеке дә түгел. Яхшылык җирдә ятмый, иткән изгелекне бише белән кайтара. Тиккә генә аның күңелен күреп йөрмәгәнсен, – диештеләр.

Тыкрык иясенең барлыгына ышанмый иде Хәйретдин, шулай да каршы берни әйтмәде. Авылдашлары да, нәрсә генә югалса да, әйберләрен башта тыкрыктан эзләргә өйрәнделәр.

***

Бервакыт Рәкыянең тыкрык ягындагы койма башына җилләтергә дип куйган ястыгы югалды. Ул көнне көтмәгәндә авыл аша бик каты давыл узган иде. Кайбер йортларның түбәләрен каерып ташлады, искерәк коймаларны аударды. Рәкыянең дә коймасын ястыгы белән бергә каршы яктагы тыкрыкның аргы башына ук алып аткан иде. Коймасын таптылар, ястык юкка чыкты.

Авыл халкының байлыгының да, яменең дә берсе – каз мамыгыннан ясалган күпереп торган мендәрләр. Ә бу – мендәр генә түгел бит! Аның өчен ишегалды тутырып казлар асраганда да, ким дигәндә, ике ел вакыт кирәк!

Рәкыягә ул ястык кияүгә чыкканда кыз бирнәсе булып килгәнгә аеруча кадерле иде. Ул аны башта тыкрыктан эзләде, тапмагач, әллә берәрсе алды микән, дип, шикләнеп, багучы Наҗиядән сорап карады. Тик ул да анык кына итеп берни дә әйтә алмады.

Берничә көннән Рәкыя әнисен төшендә күрде.

– Ястыкны табам дип баш катырма! Җәренгә казларың өч оя бәбкә чыгарыр. Алган кешене сыңар бәбкә ияртеп йөргән казыннан белерсең. Матри аны, тавышланып адәм көлдереп йөрисе булма, – диде.

– Ана казым берәү генә бит, – дип, шик белдерде Рәкыя.

– Ата дип калдырганың ана булыр, казларың егылып уңар.

Рәкыя төшенә бик ышанып бетмәде. Ата каз дигәне чынлап та ана булып чыккач, бераз борчылды да әле. Каз бит ул иң кире адәм баласыннан да кирерәк – ошамаса, ун ата каз янында каңгылдап йөрсә дә, якын китерми. Ул җәһәттән дә җае табылды. Язын һәр ике казы да күп итеп йомырка салды. Бер тавыгы чеби чыгарасы килеп кыртлап йөри иде, ояга сыймыйча калган өч йомырканы ул утырып бәбкә чыгарды.

Каршы күршесенең урам тутырып казлары су юлыннан кайтканда Хәбирәнең казы җәй буе сыңар бәбкәсен ияртеп нәүмизләнеп йөрде.

– Казларым уңу сөенеченнән миннән фитыр сәдакасы булсын, – дип, көз көне казлар суйганда Рәкыя нәсел яңартырга бер казын аңа үзе кертеп бирде.

Бу турыда белгәч, күршеләре:

– Матри, казыңның кул арты китүе бар, – дисәләр дә:

– Күрше хакы – Алла хакы. Ишегалдым тулы каз уңа торып, ничек тыныч карап торыйм? Ходай рәхмәте белән югалган иске ястыгым урынына өр-яңа ястыклык мамык булды, артып та калды әле, – дип җавап кайтарды.

***

Хәйретдин улы Искәндәрне өйләндереп башка чыгарырга әзерләнде. Аның өчен ике күршене аерып торган тыкрыкка кереп, ихатасын зурайтты. Авыл халкы ул тыкрыктан турыдан гына яр буендагы чишмәдән су алып кайта, каз-үрдәкләр су буена төшә, бакчалар артындагы болынга яшь бозауларны бәйләп куя, бала-чага кичләрен көтүдән кайткач, җиленнәре бушанган сыерларын тыкрык аша гына болынга алып чыга, җәйге көннәр матур торганда, кичке уенга да яшьләр шунда җыела иде. Шуңа күрә Хәйретдиннең бу гамәлен берәү дә өнәмәде. Ястыгы югалган Рәкыянең күршесе белән ике арадагы тыкрык калды, ә каршыдагысы бетте.

Авылның аксакалы урынына йөргән Хәсән карт Хәйретдинне тыкрыкка тимәскә күндерергә тырышып карады:

– Бу тыкрык ата-бабадан калган, аны ябу – зур гөнаһ. Әнә бит авыл башында менә дигән җирләр бар. Шунда салырга ярамыймыни йортыгызны?

– Син шулай дисең дә Хәсән абзый... Аның бит җае бар. Төне буена йокы юк бит, кемнәр генә йөрми тыкрык аша. Бала-чаганы әйткән дә юк... Качышлы уйнап бәрәңге бакчасын таптап бетерделәр. Хәмдениcаның кәҗәсенә хәтле ияләште безнең бакчага, киртә аша сикерә дә керә, ни калгандыр... Бөтен кеше йөрсә дә, тыкрык буендагы киртә-койманы миңа рәтлисе, әйтерсең, ул минем өчен генә. Тәки иясез тыкрыкка әйләндереп, мәшәкатен минем өскә ташладыгыз түгелме?

– Кәҗә мут хайван анысы, түлке монда кәҗә нипачум. Син иясезгә әйләнде дигән сылтау белән тыкрыкка тимә. Яхшы фал түгел бу. Бар аның иясе, бар...

– Малайны читкә җибәрәсе килми. Үзең дә бит улыңны читкә чыгармадың, бер ихатада йорт салдырдың.

– Мин синең кебек тыкрыкка кермәдем. Тыкрык коймасын мин дә рәтлим, аның савабы зур.

– Зиратка каршы яктан йөрисе булмаса, үзең дә әллә кайчан тыкрыкны бетергән булыр идең.

– Синең яктагысыннан барыр җир юкмыни? Без барыбыз да үзебезне белә-белгәннән бирле бала чагында шушы тыкрыктан ялан тәпи килеш кенә каз бәбкәләрен сакларга йөгердек, олырак егетләр белән кызларның ниләр сөйләшкәнен качып кына тыңлый-тыңлый аларны үртәдек. Карга боткалары белән күз бәйләш уеннарын әйтәсе дә юк. Кунак кызы Хәбирә белән дә кичке уенга барганда шушы тыкрыкта очраштың... Күпме парларны кавыштырган тыкрык ул. Безнең заманда гына түгел, безгә хәтле дә әби-бабаларыбызның балачагы, яшьлеге тыкрык белән бәйле бит. Искә алсаң, ис китәрлек хатирәләр анда. Тыкрык иясенең сине ис тиеп үлүдән коткаруын оныттыңмы әллә?

– Әкият сөйләмә инде, Хәсән абзый! Ходайдан фәрман килмәгән, бары шул гына! Тыкрык булмаса, танышыр урын бетәр идемени? Хатирәләр, имеш! Кемгә кирәк ул хатирәләр хәзер?

Күршесенең киңәшенә колак салмады Хәйретдин. Авыл халкы бакча артындагы болынлыкка урап йөрергә өйрәнде, чишмәгә дә башка җирдән төшү юлын тапты. Авылның бер тыкрыгы беткәннән дөнья туктап тормады. Тик элеккеге кебек күңелле шау-шулар юк иде инде Хәйретдин ихатасы янында.

***

Тик яңа йортта озак куана алмадылар, Искәндәрне, машина белән кайтканда, бер кешене бәрдергән өчен төрмәгә утырттылар. «Караңгы иде, күрмәдем», – дип акланунның да файдасы тимәде. Дәвалауга киткән чыгымнарны түләргә дә аңа йөкләделәр.

Хәйретдин абзый улын төрмәгә утыртып куйгач, күршесенең сүзләрен еш исенә төшерде. «Әллә тыкрыкны кире ачарга микән», – дип күпме уена килде. Ачкан да булыр иде, йортның бер өлеше тыкрык урынында утыра иде шул инде. Йортны яңадан сүтеп башка урынга салсаң гына инде. Үзе балта остасы булса да, бу эшкә тотынырлык көче дә, куәте дә элекке кебек түгел иде инде.

– Улым кайткач, берәр нәрсә эшләргә туры килер, – дип уйлады ул.

Тик бүтән авылдашларына да төрле казалар килеп торгач, бу турыда акрынлап онытылды. Бераздан улы срогын тутырып кайтты. Тормыш әкренләп үз җаена керде.

Түбән Камада яшәүче кызлары яңа фатир алды.

– Сезнең өчен дә аерым бүлмә булды хәзер, килегез, – дип карт белән карчыкны үзләренә дәштеләр. Картлар риза булды. Карчыгының гомер иткән ихатасыннан озаккарак кузгалырга риза булуының җитди сәбәбе дә бар иде. Соңгы арада тыны кысылып уяна, һава җитмәүдән зарлана башлады. Улы кайтканның икенче көнендә үк төш күрде. Тыкрык иясе күкрәгенә басканга сулый алмый, имеш. Ул аны куарга тели, ярдәмгә чакырып дәшмәкче була, авызын ачып бер сүз дә әйтә алмый, гүя бөтен тәнен авыр таш белән басканнар. Аның гырлавына карты уянып дәшкәч кенә, тын алуы җиңеләйде.

Мондый саташулар элек тә була иде. Андый чакта көч-хәл белән «Бисмилла» әйткәч, айнып китә торган иде. Тик көн саен диярлек була башлагач, шикләнә башлады. Җитмәсә, Хәйретдине дә вакыт-вакыт ялгышып сөйләшә башлады. Шәһәрдә табибка күренәсе, берәр белгән карчыктан өшкертәсе дә килде.

Яңа урынның һавасы килеште. Балалар да сөенделәр.

– Иске йортның һавасы ярамыйдыр, болай булгач. Әллә, сүтеп, яңасын салыйкмы? Бергәләп тотынсак, хәзер булдырабыз аны, – диештеләр.

– Ай-һай! – диде Хәйретдин. – Йорт салу уен түгел.

– И, әти, акча алышынырга тора диләр бит, запас акчаны банкта да, банкада да саклавы куркыныч, салыйк, – диде кияү.

Хәйретдиннең кара көнгә дип калдырган бераз акчасы бар иде, ул уйланып калды. Чынлап та, заманасы ышанычлы түгел, акча юкка чыгарга мөмкин, ә йорт – кала. Берничә көн уйланып йөргәч, бер карарга килде ул. Тик шул төнне үк нык кына бастырылып уянды. Кемдер аның күкрәгенә басып, тын алырга да ирек бирмичә, җибәрмичә торды. Телен әйләндереп көчкә «Бисмилла»сын әйтә алгач кына уянып китте. Колак төбендә яңгыраган әмерне ул йоклаганда түгел, уянгач ишетте:

– Эшкә тотынганчы, тыкрык урынын бушатыгыз!

«Хәсән карт дөресен әйткән, бар икән бит тыкрыкның иясе, чынлап та булган икән...» – дип уйлады Хәйретдин. Уянгач, аның кәефе юклыгына аптыраган кияве, моны үзенчә аңлап:

– Нәрсә, бабай, йорт салу турында сүз кузгаткач, куркып калдыңмы әллә? – дип сүз катты.

Карт дәшмәде.

***

Кияү авылга кайтарып куйгач, Искәндәргә ниятен әйтте карт.

– Малай матай сорый әле... – диде улы үз чиратында.

– Матай кӧтеп торыр. Кияү әйткән яңа йорт та, насыйп булса, качмас. Иң элек синең йортны башка урынга күчерәсе бар. Тыкрык урынына уйламыйча салганбыз, хатаны тӧзәтү кирәк булыр.

– Син нәрсә эти? Бер салган йортны урыныннан кузгаталармыни? Элек әйтеп булмый идемени аны? – дип аптырады Искәндәр.

– Ул чагында акыл җитмәгән. Гөнаһ кылынды шул. Тӧзәтеп булганда, хатаны тӧзәтик. Тыкрыкны япканнан бирле анаң белән минем йокым тыныч түгел.

– Ахмак сүз сӧйләмә, эти! Минем бүтән мәшәкатьләрем дә муеннан ашкан. Башкалар да бәла-казага очрап тора. Йә, әйт, ихатаның кайсы урынына күчереп утыртып була бер салган йортны?

– Ихата иркен. Әнә, Хәсәннең улы тыкрыкка кермәсә дә, сыялар.

– Юк, эти! Синең ул әкиятеңә ышанып, мине дә үзең кебек саташтырасың килмидер бит?

Тыкрык иясенең вакыт-вакыт саташтыруына Искәндәрнең үзенең дә ачуы килә иде килүен. Тик ул бу турыда әтисенә әйтергә кирәк тапмады.

Улын ризалатып булмаса да, картлар бастырылып уянудан туктадылар. Тыкрык иясе аларны бүтән чыдамаслык итеп борчымады. Һава җитмәүдән зарланмагач, яңа йорт турында да сүз кузгатмадылар. Тормыш әкрен генә үз уңаена барды. Тик оныгына матай алырга җыенгач, Тыкрык иясе бу юлы Искәндәрнең тӧшенә керде.

– Харап итәсең улыңны! Бераз акыл утырткач алырсың. Җил куудан башканы белми бит әле ул бала!

Искәндәр бу сүзләрне шул ук саташуга юрады. Улы матайлы булды. Җай чыккан саен элдерә генә. Кич җитү белән клубка чыга, тӧне буе кызлар белән урамда йӧреп таң аттыра, кояш күтәрелгәндә генә кереп ята.

Урак ӧсте җиткәч, Искәндәр комбайнга утырды. Ә улының уенда кызлар да, матай куу гына. Ирек бирсәң, матаенда гына йоклар иде.

«Җилләнер-җилләнер дә туктар әле. Хәзерге яшьләрнең күбесе шулай инде», – дип уйлады Искәндәр.

Бер кӧнне матаен выжылдатып тӧшке ашны китергәч, әтисенең басуның аргы башында икәнен күреп, матаеннан тӧште дә пакусның күтәрелебрәк торган җиренә чалкан ятып күктәге болытларны күзәтә башлады ул дигәннәре. Әтисен кӧтә-кӧтә изрәп киткәнен дә сизмәде.

Искәндәр комбайнын кабызып, ниһаять, басуның бу ягына якынлашты. Матайны күрде ул.

– Бу малай матаен калдырып кая итте икән, – дип, тирә-ягына карана-карана улы күмелеп яткан пакус ӧстенә килеп мендем генә дигәндә, комбайн нәрсәгәдер бәрелеп кисәк туктап калды.

– Кӧне кӧн булмады инде, ватыла да ватыла, – дип, ачуы килеп, комбайныннан тӧшкәч кенә баланың чак кына комбайн астына керми калганын күреп, чәче агара язды. Коточкыч үлемнән исән калуын абайламыйча йоклап яткан улын тартып торгызды да, әле аты юлы белән сүкте, әле кочаклап елады.

Күрәсең, гомере барыбер бетәсе булгандыр, шушы вакыйгадан соң бер ай үткәч, матае белән каршы яктан килүче КАМАЗ астына барып керде углан. Үлеме үкенечле булса да, моңа үзенең сәбәпче булмавы бераз юаткандай булды Искәндәрне.

***

Хасталанып урынга егылгач, соңгы кӧннәрен яшәгән Хәбирә – хәлен белергә кергән Рәкыягә:

– Ястыгыңны Хәйретдин давыл кӧнне тыкрык артындагы болыннан табып алып кайткач, яңгырда юешләнмәсен ӧчен бура эченә куйган да оныткан бит, – диде. – Бурабыз янгач кына исенә тӧшерде. Соңгы арада хәтере бик чуалган иде бит аның...

– Үткән эшкә салават. Ястык-мендәрләремнең санын белмим дә инде хәзер. Юрганнарыма хәтле каз мамыгыннан, кайчагында кайсын ябынып йокларга да белмим. Йоклаучы булмагач, кая куеп бетерергә белми аптырыйм. Ярый әле балалар якында, килеп йӧриләр, оныклар кунарга калгалый. Күршелеккә начар булмадыгыз. Мин синнән дә, Хәйретдиннән дә мең риза-бәхил. Нинди эшкә тотынсак та, иң беренче сезгә киңәшкә кердек.

– Без алган дип кеше арасында йӧзебезне кызартмадың. Казыңа хәтле фитыр сәдакасы итеп керттең бит. Рәхмәт, – дип, күзләре яшьләнде Хәбирәнең.

– Күрше хакы дӧнья малыннан кыйбатрак. Начар ният белән яшермәгән бит...

– Бәйләнәсе килгән кеше аңа карап тормый шул...

Хәбирә киткәч, Хәйретдин дә озак яшәмәде. Ул инде бӧтенләй хәтерен җуйган, якыннарын да танымый башлаган иде. Ә Искәндәр, алар вафатыннан соң, гаиләсе белән бу ихатаны ташлап, кыз чагында хатыны яшәгән күрше авылга күченде. Ихатада тынычлык булмавының тикмәгә түгеллегенә, Тыкрык иясе сәбәпле булуына ул инде ышана иде хәзер. Бердәнбер улыннан соң калган кызы да бәхеткә тиенмәде, ире, ике сабыйны ятим калдырып, юл фаҗигасендә һәлак булды. Искәндәр белән хатыны шул сабыйлар белән мәш килә хәзер. «Кайгы-хәсрәтләребез иске нигездә калса ярар иде», – дип тели алар.

***

Хәзерге яшьләр бу урында кайчандыр тыкрык булганын да, аның авыл тормышында гаять зур роль уйнаганын да белмиләр. Яшәү рәвешләре бӧтенләй башкача. Чишмә суы да ӧйләргә үк килеп тора. Бер-берсе белән табигать кочагында түгел, ә интернет аша гына аралаша.

Язмышы белән килешсә дә, Искәндәр Тыкрык иясен бер дә исеннән чыгара алмады. Вакыт-вакыт аңардан:

– Шул хәтле каты бәгырьле булырга ярыймыни, башкача җәзалап булмый идемени безнең нәселне? – дип сорыйсы килде аның.

Ә бер таң алдыннан Тыкрык иясе, кӧтмәгәндә-уйламаганда, чал чәчле карт булып тӧшенә керде.

– Монда да тынычлыкта калдырмыйча, кара сакалым булып тагылып килдеңмени? Тагын үч алырга йӧрисеңмени? – дип пошаманга тӧште Искәндәр.

– Кая барыйм соң? – дип җавап кайтарды Тыкрык иясе. – Үч алмадым мин, алырга уйламыйм да... Бәла-казадан саклыйсым гына килә иде үзегезне... Комбайнны туктатам дип аягымны имгәткәч, матайда җил куган улың артыннан ӧлгерә алмадым, гафу ит, туктатырга бик теләгән идем үзен... Яшьләр җил кебек шул, алар артыннан ӧлгереп буламыни? Хәзер дә рәткә килеп бетә алмыйм. Ичмасам, яшәргә иясез тыкрыклар да калмады... Сезнең бу бакча артындагы болынның матурлыгы... Шушында булса да сыенып булмасмы дип килдем, туган... картаймыш кӧндә...

– Гафу ит... Соң булса да гафу ит... – дип пышылдады Искәндәр, яшенә тыгылып.

Берничә кӧннән Искәндәр карт, үз ихатасын бүлеп, тыкрык ясар ӧчен эшкә тотынды. Аның янында үсеп килүче ике оныгы әвәрә килә иде.

(Кыскартылып бирелә. Тулы вариантын сайтыбызда табарсыз)

PRESSA.RU

МИНЕМ ӘДӘБИЯТЫМ КЕМГӘ КИРӘК?

Мәскәү. ВДНХның 75нче павильоны. Кассага да, бинага керә торган ишекләргә дә чират тезелгән. Әйтерсең, рок-концертка, йә булмаса – футбол, хоккей матчына. Әмма, юк, кешеләр эләгергә теләгән бу чара – Мәскәүдә ел саен уза торган «Китап фестивале». Урамнардагы плакат-баннерлардан да Маяковский карап тора, һәм аларга «Москва читает» дигән шигарь язылган. Мәскәү бу көннәрдә чынлап та... китап укыды һәм җыйды. Чемоданлап, сумкалап, пакетлап. Шулай ук иксез-чиксез павильонның буеннан-буена сузылган мәйданчыкларда дөньяның төрле почмакларыннан, илләреннән килгән язучылар белән очрашты, аралашты, әңгәмә корды. Кыскасы, китап тантана итте.

Автор:
Луиза Янсуар

МИЛЛӘТЛӘР БЕЛӘН МӘДӘНИЯТЛӘР БЕРЛӘШСЕН ӨЧЕН...

6–10 сентябрь көннәрендә Инстаграмда һәм башка социаль челтәрләрдә #ММКВЯ хэштегы белән еш чагылып торган 30нчы Халыкара Мәскәү китап күргәзмә-ярминкәсе кысаларында быел беренче тапкыр Россия халыкларының милли әдәбиятлары фестивале дә узды. Оештыручылар әйтүенчә, Россиянең яңа тарихында күпмилләтле дәүләт халыкларының әдәби процессларын барлау, аларны бер үзәккә туплау юнәлешендәге тәүге масштаблы, әһәмиятле адым бу. Россия Федерациясе халыкларының милли әдәбиятларын үстерүгә ярдәм итү программасы кысаларында нәшер ителгән «Антология поэзии народов России» китабы быелгы «Книга года» бәйгесенең җиңүчесе булып та табылды. РФнең Әдәбиятны үстерү, китап нәшер итү һәм китап уку культурасын үстерү комитеты рәисе Сергей Нарышкин Берләшкән гуманитар нәшрият редакторы Максим Амелинга тантаналы рәвештә приз тапшырды. «Бу эш – күпмилләтле Россиядә яшәүче халыкларның иҗади процессын барлау һәм интеграцияләүдә башланган эшнең тәүге адымнары гына әле», – дип ассызыклады Максим Амелин, үз чиратында.

Программаны тормышка ашыру этаплары берничә баскычтан гыйбарәт. Әлеге фестиваль – шуларның берсе. Ә инде рус теленә тәрҗемә ителгән әсәрләрдән төзелгән, нәшер ителгән Поэзия антологиясеннән тыш, киләчәктә драма, публицистика, балалар әдәбияты һәм проза җыентыклары да көтелә. Бу, советлардан соңгы пространствода, чынлап та, прецеденты булмаган хәл. Һәм, әйтергә кирәк, кәефне, күңелне күтәрә торган яңалык та. Сәерсендерә торган соңгы пунктны исәпкә алмасак, билгеле. Һәрхәлдә, сүз милли әдәбиятлар турында барган очракта...

Россия Федерациясендә яшәүче халыкларның милли әдәбиятларын үстерү программасы Россиядә Әдәбият елын уздыру буенча төзелгән Оештыру комитеты химаясе астында эшләнде. Программаның максатлары һәм бурычлары:

- милли әдәбиятларны киңрәк аудиториягә чыгару, күпмилләтле Россиянең мәдәниятен һәрьяклап яктырту;
- милли әдәбиятларны зур гомумроссия мәдәни процессына интеграцияләүне тәэмин итү;
- милли әдәбиятларны гомуммәдәни пространствода актив эшчәнлек алып бару аша таныту;
- рус телен милләтара һәм мәдәниятара аралашу теле буларак үстерү.

Фотолар: Владимир Голиков, Михаил Гуревич, Луиза Янсуар

«ЧИКЛӘРДӘН ЧЫГУ КИРӘК...»

Алексей Арзамазов, шагыйрь, тәрҗемәче, әдәбият теоретигы һәм тарихчысы, удмурт әдәбияты вәкиле:

– Соңгы еллардагы әдәби-мәдәни вакыйгаларны күздән кичереп, Россия мәдәни тормышындагы иң әһәмиятле вакыйгаларның берсе дияр идем мин бу фестивальне. Килгән кунаклар да, катнашучылар да уникаль мөмкинлеккә ия булды – Россиянең төрле почмакларыннан җыелган милләт вәкилләренең тере сүз сәнгате, бүгенге поэзиясе, әдәби торышы белән очрашты, ул халыкларның поэзиясен һәм рус, һәм үз милли телләрендәге яңгырашта тыңлый алды. Милли әдәбиятлар стенды янына килүчеләр өчен тагын бер «бүләк» хәстәрләнгән иде: Поэзия антологиясен махсус цифрлы җайланмадан уку. Россиядә яшәүче халыкларның әдәбиятлары ни дәрәҗәдә күпбизәкле, күптөсмерле, күпаһәңле – әнә шуны тояр өчен генә булса да, тыңларга мөмкин иде фестиваль вәкилләрен. Оештыручылар да, кунаклар да кайбер милли әдәбият вәкилләре иҗатындагы югары сәнгатилекне ишетеп сокланган һәм гаҗәпләнгәндер дә, дип уйлыйм. Чөнки милли әдәбиятлар арасында чын мәгънәсендә күтәрелеш, янарыш тенденцияләре күзәтелгәннәре бар. Сезнең татар әдәбиятында, мисал өчен, мин бүген бер төркем яшь язучылар барлыгын беләм, һәм аларның поэзиясен тәрҗемәчеләр дә, укучылар да югары бәяли. Бу – олы бәхет әдәбият өчен. Удмурт әдәбиятында да кызыклы яшь авторлар пәйда булгалый. Мин әдәбиятка килгән яшьләрне күзәтергә яратам, чөнки нәкъ менә алар аның киләчәген билгели.

Минемчә, фестиваль төрле төбәкләрдә яшәгән милли әдәбият вәкилләренең үзара очрашып сөйләшә, аралаша, тәҗрибә уртаклаша алуын тәэмин итә алырдай мәйдан буларак та, үз вазыйфасын башкарды. Монысы бигрәк тә әһәмиятле. Чөнки, безгә аралашу җитми. Стратегик яктан мөһим булган коммуникация төенен булдыру өчен оештыручыларга рәхмәт әйтергә кирәк. Шулай ук тагын бер плюс: периферийдә яшәүче язучылар белән Россия сүз сәнгате мэтрлары – М.А. Амелин, В.А. Куллэ, М.М. Липкин һ.б. аралашты.

Фестивальнең киләчәге булсын иде. Чөнки әдәбият ул бер урында гына таптанып тормый. Әдипләр үзләре дә. Милли әдәбиятларга, үсәр өчен, үз чикләреннән чыгып карау кирәк. Һәм – аларга гына да түгел. Бу ике як өчен дә файдалы формат һәм мәйдан.

Россия Федерациясендә яшәүче халыкларның милли әдәбиятлары фестивале Мәскәү шәһәренең Милли сәясәт һәм төбәкара бәйләнешләр департаменты ярдәмендә узды. 5 көн дәвамында Россиянең 25 төбәгеннән килгән 60ка якын катнашучы 31 телдә үз иҗатларын тәкъдим итте һәм милли әдәбиятлары тарихы, аның бүгенге торышы белән таныштырды. Сөйләшү нигездә рус телендә барды. Әмма милли әдәбият үз милли телендә яңгырады. Катнашучылар: чуваш, коми, юкагир, кабардин, авар, алтай, нанай, якут, калмык, башкорт, татар, осетин, ингуш, бурят, удмурт, черкес, эрзя, кырымтатар, телеут, азәрбәйҗан, хакас, чечен, тува, коми-пермяк, мансы һ.б. милли әдәбияты вәкилләре иде. Чаралар очрашу, әңгәмә рәвешендә дә булды, милли телләр буенча мастер-класслар, презентацияләр дә үткәрелде. Себер татарларының фольклор коллективы башкаруында җырулар яңгырады. Хакас тахпахы, шулай ук дөңгер белән башкарылган нанай биюе дә тәкъдим ителде мәскәүлеләргә. Мостай Кәрим исемендәге Башкорт яшьләр театры, Хоца Намсараев исемендәге Бурят дәүләт академик театры, Калмык дәүләт филармониясенең Костюм һәм пластика театры коллективларының сәхнә тамашалары, чыгышлары да ямь өстенә ямь булды. Заманча тенденцияләрнең берсе буларак, фестиваль тамашачысы игътибарына удмурт рэпы тәкъдим ителде.

МИЛЛИ ӘДӘБИЯТ МИЛЛИ КОСТЮМНАН БАШЛАНАМЫ?

Һәрбер милләт вәкиленең йөзен, асылын мөмкин кадәр тулылыгында күрсәтү бурычы куелган иде оештыручылар белән катнашучыларга. Шуңа да күпчелек катнашучылар, милли костюмнарын киеп, чыгышын үз әдәбиятларының үткәне, тарихы турындагы презентацияләрдән башлады, докладлар белән тулыландырды. Һәр әдәбиятка бер сәгать вакыт бирелде. Күпчелек туган әдәбиятларының үткәне белән совет пространствосындагы ситуациясенә басым ясады. Ә бүгенгесе һәрберсендә дә, ни кызганыч, мактанырлык түгел. Күпчелек төбәкләрдә бездәге кебек 300дән артык әгъзасы булган Язучылар берлеге дә, дәүләт нәшрияты да эшләп тормый. Аннан да бигрәк, милли мәктәпләр, югары уку йортлары проблемасы – иң зур бәла. Әмма, ни гаҗәп, шуңа да карамастан, каләм тибрәткән бәндәләр, үз акчасына булса да, китап чыгара, аны тарата, фестивальләр, очрашулар уздыра. Үзләрен сакларга тырыша.

PRESSA.RU

БЕЗ РУХИ ГЕНОЦИД НӘТИҖӘЛӘРЕН ТАТЫЙБЫЗ

Марина Эльтун, нанай теле укытучысы, шаман, нанай әдәбияты вәкиле:

– Кызганыч, балаларыбыз үз телләрендә нигездә өйдә – әти-әнисе, әби-бабасы белән генә сөйләшә диярлек. Мин үз балаларыма телне өйрәттем, мәктәптә балаларга да гомерем буена өйрәтергә тырышам. Әмма әйләнә-тирә мохит телебезне дә, милли традицияләребезне дә йота. Ә бала кечкенәдән үз телендә сөйләшеп үсмәсә, ул ничек туган әдәбиятын укысын ди?! Рус телендә иҗат итүче кече милләт вәкилләренә килсәк, алар барыбер дә милли әдәбиятны үстерүгә өлеш кертми шул инде…

Александр Брехов, шагыйрь, композитор, Алтай әдәбияты вәкиле:

– Чыгышым белән Алтайдан булмасам да, Алтайны икенче ватаным дип саныйм. Мин рус телендә язам, әмма Алтайны олылыйм, Алтай шагыйрьләренең иҗатын да үз туган телләрендә тыңларга яратам. Кызганыч, бүген безнең төбәкне инвестиция кертү өчен уңайлы җир дип кенә саныйлар, аны сатып-алып уйныйлар. Әмма Алтай – борын-борыннан «көч урыны», җирнең бик әһәмиятле эпицентры. Шуңа да аңа бик сак карарга кирәк. Табигатенә кызыгып, җир үзләштергән адәмнәр, иң беренче эш итеп, туфракны кубарып ташлый, җирне-суны пычрата, җәнлекләрне аулый, үтерә… Табигать геноциды башлана. Асылда, кешеләрнең физик гамәлләре рухи геноцидның чагылышы ул. Мәскәү шикелле зур шәһәрләр, башкалалар мәдәниятләрне берләштерү миссиясен башкарырга тиеш. Шулай ук аңлатырга бүгенге рухилыктан мәхрүм калып барган халыкка: менә, безнең күпмилләтле илебездә нинди матур әдәбиятлар, мәдәниятләр бар лабаса, дип. Телевизордан әнә шуларны күрсәтергә кирәк, сугыш күренешләрен түгел. Мин бу фестивальдә бик күп төрле телләрнең аһәңен ишеттем, һәрберсе – үзе бер галәм. Безгә киләчәктә проблема куеп сөйләшер өчен дә җыелырга кирәк.

Пушкин китапханәсендә узган тантаналы кичә вакытында Алтай халык язучысы **Боронтой Бедюров** та бу хакта әйтте:

– Без совет язучысы исемен йөрткән елларда мондый очрашулар табигый һәм даими иделәр. Һәрберебез үз төбәгенең, үз милләтенең улы, кызы булу белән беррәттән, олы бер Россия әдәбияты вәкиле дә бит.

Китап ярминкәсендә йөрүче халыкны, башлыча мәскәүлеләрне, билгеле, иң беренче чиратта, безнең мәйданчыкта хөкем сөргән колорит: милли костюмнар, ризыклар, башкача яңгыраган сөйләм җәлеп итте. Янәшәдәге генә сәхнәдә, мемуарлар җыентыгы басылып чыгу уңае белән чыгыш ясаган, мәңге «картаймас» «Браво» төркеме аккордларыннан аерылып, Алтай әдәбияты турында тыңларга, костюмнарга хозурланырга да килүне кирәк таптылар алар. Әйе, нигездә, күпчелек өчен милли әдәбият төшенчәсе милли костюм һәм милли җырулар, уен коралларындагы яңгыраш буларак кына ассоциация тудырып калды булса кирәк. Әмма без фестивальдән барыбыз да уртак бер омтылыш һәм ният белән кайтып киттек: проблемалы сөйләшүләр – киләчәк эше. Бу бит әле, чыннан да, яңа тарихта бер-беребезгә таба ясаган адымнарның тәүгеләре генә. Милли әдәбият милли костюмнан башланды… ә ничек дәвам итәр – анысы… үзебездән торадыр, бәлки?

«ЮГАЛГАН АТАУГА РӘХИМ ИТЕГЕЗ!»

Инесса Томская-Тымкыль, юкагир әдәбияты вәкиле:

– Төньяк халыкларының әдәби мирасы турында доклад әзерләвем, презентация ясавым юкка түгел, чөнки «юкагир әдәбияты» дигән төшенчәнең башка халыклар өчен ни дәрәҗәдә экзотик яңгыравын яхшы аңлыйм. Бу барлык азсанлы халыкларга да кагыла торган проблема. Юкагир әдәбияты дигәндә, кешеләр бит ачылмаган бер атауны күз алдына китерә. Югалган атауны… «Кемнәр алар?!» – дип гаҗәпләнә. Татар әдәбияты турында, әйтик, барыбер дә ишетеп беләләр – Тукайны, Муса Җәлилне… Ә безнең хакта хәтта филологларның да күпчелеге белми.

Әбием бик матур җырлый иде, борынгы җырлар аның башкаруы аша сеңгәндер миңа. Хәзер аларны үзем җырлыйм. Әдәбиятыбызга килсәк, шактый кырыс һәм балаларча ихлас, самими, дияр идем мин аны. Төньякта яшәүче халыклар үзләре дә элек-электән шундый булган. Аларның зирәклеге табигатьнең авыр шартларында тормыш итүгә, үзләрен саклап калуга юнәлтелгән. Әмма төньяк халыкларның әсәрләрендәге кабатланмас сюжетлар, мотивлар, аһәңнәрне башка бер генә әдәбиятта да табып булмый.

Чукчалар, нанайлар, нивхи, орочи, ханты, мансы, ненец, комилар… төньяк халыклары бик күптөрле, аларның әдәбиятлары да, бер-берсенә охшаш булса да, барыбер аерылып тора. Милли әдәбиятларның берсе генә югалса, бер генә тел бетсә дә, без шулкадәр ярлы булып калачакбыз. Инде яңа буын аның бөтен матурлыгын җуеп бара, кызганыч. Ә бит инглиз, немец теле һәм Британия, Германия әдәбияты, мәсәлән, миңа үз әдәбиятымда булган матурлыкны бүләк итә, тәэсирләндерә, елата алмый. Үз балаңны яраткандай ярата алмыйсың бит башкаларныкын…

ЯСИН ЧЫГАРГА ИРТӘМЕ?

«Шөкер, әдәбиятка ясин чыгарга иртәрәк икән әле», – диеп кайтып кердем Казанга. Әмма, кайтып җитүгә үк, уйларым икенче юнәлеш алды: «Әмма – милли әдәбиятларгамы соң?» Иҗтимагый вазгыятьтә соңгы арада үтә дә кискенләшкән татар теле мәсьәләсе тирәсендәге шау-шу, үзебезнең халыкны басып алган маңкортлык шартларындамы? Үз телеңә үз милли республикаңда (гафу итегез, ияләшкән буенча һаман да шулай әйтелә) ук куркыныч янагандамы?

Милләт төшенчәсе минем өчен иң беренче чиратта телгә барып тоташа. Бүгенге заманның зомбилаштыру алымнарыннан иң үтемлесе, иң киң кулланыла торганы булган дингә, бигрәк тә аның иҗтимагый институтына түгел. Гәрчә: «Безне ислам дине саклаган», – дигән позициядә торучылар күбәйгәннән-күбәя барса, динне сәяси корал буларак файдалану көчәя төшсә дә. (Әлбәттә, моны Россия пространствосында христиан дине позицияләренең ныгуы, дин белән тулы бер мәмләкәт күләмендә манипуляцияләр баруы белән дә аңлатып була).

Әмма милләт мәсьәләсенә килгәндә... хәлләр катлаулырак лабаса. Әйтик, ислам динен татарча белми тотучылар да бар. Һәм ислам тарафдары булыр өчен татар милләтеннән булуың да зарури шарт түгел, асылда. Болгар иленә ислам килеп кергәндә, без инде әдәбиятлы һәм язу системасы булган халык исәпләнгәнбез. Шуңа, мин милләтнең умырткасын тәшкил итүче, аның генетик хәтерен саклаучы төп критерий дип, ничек кенә булмасын, телне атыйм. Дини канунның төп кыйммәтләрен халыкка үтемле формада илтеп җиткерүче, тапшыручы да, нигездә, әдәбият. Юкка гынамыни, безнең әби-бабайларның сандыкларында ислам кабул ителгәч төрки-татар әдәбиятына үтеп кергән «камил инсан» тәгълиматын алга сөрүче «Йосыф китабы» кадерләп сакланган? Коръән белән бергә, янәшә. Әдәбият аша менталитетны формалаштыручы код үз эшен эшләгән әнә шулай. Әсәр дә, Казан алынып, әдәбият бәетләр, җырулар дәрәҗәсендә генә сакланып, мантый алмыйча интеккән елларда, телдән-телгә күчкән, таралган, һәм, халыкның үзидентификациясе нуль дәрәҗәсенә төгәрәгән дәверләрне кичеп, безнең көннәргәчә килеп ирешкән. Диненә рөхсәт булмаган, аның өчен эзәрлекләнгән чакта да халыкны теле саклаган, димәк.

СССР мәмләкәте җимерелеп өлгермәгән елларда бераз гына яшәп алган совет баласы буларак, мин китапханәләрдә «гаскәр кеби тезелеп торган» басмалар арасында «милли әдәбият» вәкилләренә еш тап була идем. Союздаш республика язучыларының китапларын тәрҗемә итеп, СССР буйлап таратуга зур игътибар бирәләр иде заманында. Билгеле, рус телендә. Билгеле, милли телләрнең хәле шактый мөшкел булуга карамастан. Әмма... ул басмалар да булмаса, без Рәсүл Гамзатов, Чыңгыз Айтматовларны, бәлки, белмәс тә идек? Владимир Ильич сүзләренә ышансак, революциягә кадәр гел кыерсытылып яшәгән «кече халыклар» совет заманында, ниһаять, зурланган. «Мәскәү обоймасы»на эләгеп, кадер-хөрмәт күреп яшәгән милли әдәбият вәкилләре дә аз булмаган. Язучылар бу мәсьәләдә үзләрен рәхмәтле тойганнар. Хәтергә Мостай Кәримнең бер шигыре килеп төшә:

Җирдә ничек мин нык басып торам,
Нинди иркен алам сулышны!
Шуларның бит мин барысы өчен
Рус туганым, сиңа бурычлы!
Рус түгелмен, ләкин россиян мин,
Россиян мин – нинди горурлык!
Ун гомерең миңа кирәк түгел,
Бер язмышым – шуңа торырлык!

Әмма ул чорда әдәбиятның идеология коралы булуын исәпкә алмыйча ярамый. Ә бүген? Милли әдәбиятлар бүген, телләр һәм халыклар арасындагы чикләр юылып, җуелып барганда, глобализация «патшалык иткән» дәвердә, кемгә һәм нәрсә өчен кирәк?

Яхшы ният, әйбәт финанслар һәм, әйтергә кирәк, инде күзгә күренеп торган нәтиҗәләр дә бар. Шуларның иң саллысы – бүгенгә, әлбәттә, «Россия халыкларының поэзия антологиясе». Бу – четерекле, олы хезмәт. Афәрин – моны башкарып чыккан коллективка. Фестивальгә җыелган милли әдәбият вәкилләре дә 6–10 сентябрь көннәрендә узган очрашулар вакытында күпмедер дәрәҗәдә интеграция кичерделәр, дияргә мөмкин. Әлбәттә, рәсми чыгышлар вакытында, нигездә, рус телендә кичердек аны. Ә үзара аралашканда, уртак нигезебезгә – төрки телләргә дә күчкәләп кичерүгә ирештек.

Минем әдәбиятым Россиядәге медиапространствода актуаль һәм кирәкле, дип ышандыра Мәскәү нәширләре. Әмма Россиядә соңгы арада кискенләшкән телләр мәсьәләсе шартларында ул әдәбият озакламый үз халкым өчен үк кирәкле булудан туктамасмы соң, дигән сорау тынгы бирми шулай да. Колагымда да кайтканнан бирле кайчандыр совет тыңлаучысына «Увезу тебя я в тундру» дигән җыры аша таныш булган, «Төньякның алтын тавышы» дигән даны үзеннән алда йөргән Кола Бельды башкаруындагы юкагир җыры яңгырап тора:

Услышьте нас, юкагиров,
У тундры на берегу – начало мира.

Әйе, безнең барыбызның да дөнья башы бар – тәпи басып киткән туфрагыбыз һәм бишек җырлары аша иңгән әнкә телебез. Баланы беркем алыштыра алмагандай, әнкәңне дә башка ана алыштыра алмый шул. ■

Рәсми чыганаклар буенча, Россия Федерациясендә бүгенге көндә, рус теленнән кала, 100дән артык язуы булган тел барлыгы мәгълүм. Шуларның 50%ы – әдәби тел. Ягъни ул телләрдә әдәби һәм фәнни текстлар иҗат ителә, бастырыла.

PRESSA.RU

УЕН ДӘВАМ ИТӘ, ЯКИ БЕЗДӘН СОҢГЫ ДӘВЕР – НИНДИ УЛ?

Сүзем шактый моңсу, хәтта ки пессимистик жанр – антиутопия хакында бара. Һәм бу юлы игътибарымны җәлеп иткән романнарны укыганда, чынлап та анда сурәтләнгән дөньяның идеаль технократик ялтыравыгы артында нинди куркыныч яшеренгән булуын ваемлау шомландыра. Китапсыз, уй-хыялларсыз, мәхәббәтсез... затлар чынбарлыгына чакыра безне авторлар. Кайсыдыр философ антиутопия жанры кешегә карата көчле мораль прессинг, һөҗүм булган чорларда активлаша, дигән иде. Димәк, бу әсәрләр дә үзенә күрә сигнал утлары буларак бәяләнә ала? Әллә без... төсләрне куертабыз, үзебезне артык пошындырабыз гынамы?



Автор:
Луиза Янсуар

Икесе дә бардыр. Әмма бүгенге әдәбиятта китап темасының күтәрелүе һәм язучының дәрәҗәсе, шәхесе, язмышы турындагы уйлануларга юлның ачылуы – сөенечле факт. «Китаплар бетә», «тиздән гаджетлардан башка берни калмый», «тулы бер мәдәният юкка чыга» дип лаф орган заман – ишегалдында. Телләр, милләтләр һәм аларның үзтәңгәллеге мәсьәләсе кискенләшкән чор. Гәрчә, мин үзем китап культурасының юкка чыкмаячагына инану белән яшәсәм дә, аның шактый шаблонлашып, ярлыланып баруын күзәтергә мәҗбүрмен. Шуңа да бу ике яңа китапны игътибарсыз калдырып уза алмадым.

«КАЛГАНЫН ВАКЫТ КҮРСӘТЕР...»

Марат Кәбиров. Китап

Ул гел кара каһвә эчә. Кара курткадан һәм кара күзлектән йөри. «Пётр I» сигаретын тарта. Салаватны, Нәфкатьне, Фифтицентны (50 Cent), Майкл Джексонны, ДДТны тыңлый. Китапларындагы геройлар да кара төскә өстенлек бирә. «Хәтта якты хыяллар, якты персонажлар артында ниндидер кара шәүлә барлыгын тоясың...» – ди аның әсәрләре хакында китапның икенче бер герое – урамда очраган күрәзәче карчык тарафыннан «ул бит Иблис» дип тамгаланган Даутов әфәнде. Һәм тагын болай дип тә өсти: «Мин синең иҗатыңны да, журналистлар белән әңгәмәләреңне дә күзәтеп киләм. Һәм берничек тә үз-үзеңә ышанмый торган кешесең дип әйтә алмыйм. Киресенчә, бүген үз көченә синнән дә ныграк ышанган язучыны табу кыен».

Романның нигез каһарманнарының берсе – язучы. Һәм, алай гына да түгел, укучысы белән һәрчак «уйнарга» ярата торган Марат Кәбировның alter egoсы дип кабул итәргә дә мөмкин аны. Һәм каралыкның, депрессив буяуларның куерып агуы, аннан, көтмәгәндә, нәзәкатьле, нәфис нурлар, төсләр белән кушылып китеп, үзенә бер меланхолия, сплин тудыруы – монысына да әзер Кәбировның укучысы. Әмма ул бу теманы ачкандагы кайбер борылышларга, шулай да, әзер булмаганнары табылыр, дип уйлыйм.

Романның башыннан ук без китап эченнән – китап эченә, заман эченнән заман эченә кучеп йөри башлыйбыз, динамика артыннан ияртә. Һәм бу сәяхәт «Китап»ның буеннан-буена дәвам итә. Кайдадыр шартлы рәвештә «бездән соңгы дәвер» дип аталган чорда, идеаль дәүләттә башланып киткән сюжет төене баштарак безгә, югарыда искә алганымча, антиутопия жанры турында уйланырга этәргеч бирә. Әсәр тукымасына зомбилар, роботлар килеп кергәч, ул фантастика, триллер, хоррор җепләреннән дә үрелгән булуын аңлыйбыз. Гаҗәпләнерлек урын юк – Кәбировның стиле бу. Ул беркайчан да бер генә жанр кысаларында торып эш итүдән тәм таба белми. Һәм, уйлыйм, алга таба да тапмаячак. Трэш, винегрет... – ә нишләп әле шулай булмаска тиеш ди?! Хәер, бүгенге әдәбияттагы чиста жанр мәсьәләсе дә шулай ук сорау тудыра торган мәсьәләләрнең берсе булып кала бирә. «Автор» һәм «симулякр» төшенчәләре шикелле үк. Әзерлекле укучы, филологлар өчен бу роман – кызыклы анализ үрнәге. Рәхәтләнеп, ләззәтләнеп йөрергә була аның лабиринтлары буйлап...

Хәер, болары – икенче мәсьәлә. Мин сезгә бу әсәрне башка максаттан укырга тәкъдим итәр идем: 1) язылышы, өслүбе, теле, аһәңе үзенчәлекле булганга; 2) тема һәм проблемалар гаять актуаль булганга. Дөрес, социумдагы халәтне әсәр кисемтәсендә чагылдырып, укучысына турыдан-туры «төбәп ату»ны бүгенге укучы «мейнстрим» буларак бәяләргә, һәм, киресенчә, тексттан йөз чөерергә дә бик мөмкин. Әмма бу икенче очрак: безнең прозада мондый төр текстлар белән укучыны гел иркәләп тормыйлар, шуңа да Кәбировның соңгы әсәрен мин, күтәеп алган бер бүләк буларак кабул иттем.

Әсәр геройлары китап төшенчәсе дә, язучы фигурасы да җир йөзеннән юкка чыккан, кешеләрнең кеше булуында да олы бер шик булган бер дәвердә яши. Һәм шуларның берәве, кулына сәер рәвештә җир йөзендә бердәнбер нөсхәдә калган китап килеп кермәсә, бәлки, аның нәрсә икәнлеген белмичә дә рәхәтләнеп яшәгән булыр иде. Ул китапны язган язучының язмышы турында да уйланып җәфаланмас иде, әлбәттә. Чөнки, аның тормышы болай да мөлдерәмә: хезмәт иткән өлкәсендә кирәкле галим ул, яраткан хатыны, эше бар, әле генә яңа фатирга күчергәннәр, әнә, үзен. Фатир да – җәннәтнең-җәннәте: теләгәнеңне уйларга да өлгермисең, шунда ук барысын да хәстәрләп бирә. Әмма Илдарның тынычлыгын китап җуя. Кайчандыр Адәм баласына Сүз иңгән кебек, цивилизациянең иң алга киткән, инде бәндәләрен, яман чирдән котылдырган кебек, уй дигән бимазалап торучы фактордан да азат иткән бер мизгелендә – аның аңында архетипик хәтер кубарыла башлый.

Сүз баштарак кәгазь басма турында гына барса, тора-бара хәлләр тагын да хәтәрләнә. Тора-бара кешелекнең, бүлгәләнгән, матур итеп төрелгән, полуфабрикаттай уңайлы мәгълүматны генә үзләштерергә күнегүе аша нәрсәгә килеп чыгасын анализларга керешә авторны алыштыручы күзәтүче. Мин романда авторны эзләп таба алмагач, ваемладым: агониядәге бу халәтне ул шулай, кем ашадыр чагылдырып кына бирә алгандыр. Гәрчә, «Пётр I» сигаретлары, кара күн курткалар, күзлекләр... безне Кәбиров белән әсәрдәге язучыны, Илдарны, ә алардан да бигрәк, күзәтүчене үзара тәңгәлләштерергә мөмкинлек биреп, алдавыч вазыйфасын башкарса да.

«Егет миңа сәерсенеп карап торды да башын чайкап куйды:

– Сез дөньядан артта калгансыз шикелле... – Ул елмайгандай итте: – Моннан берничә ай элек барлык матбугат чараларында да иске китапларны кабул итү пунктлары ачылу турында хәбәрләр булды. Башта алар искергән, беркемгә дә кирәкмәгән китапларны гына җыйдылар. Соңрак әр-яңа китапларга күчтеләр, башта арзанрак бәягә, аннан кыйбатрак хак белән сатып алдылар. Хәзер бу эш тәмамлануга бара, дип сөйлиләр...

– Ләкин... – Мин мондый көтелмәгән хәбәргә ни әйтергә белми аптырап калдым. – Ләкин бу кемгә кирәк булган?

Егет иңнәрен генә сикертте.

– Белмим, әмма кешеләрнең күпчелеге әлеге хәлдән бик канәгать калды. Газета-журналларда шушы эшне оештырган кешеләрне мактап язган мәкаләләр күпләп дөнья күрде. Теләсәгез, кызыксына аласыз...

Мин, ишеткәннәремне башыма сыйдыра алмыйча, акрын гына тукталышка таба атладым. Анда җиткәч, буш эскәмияләрнең берсенә утырып тәмәке кабыздым.

– Китап кабул итү пунктлары... – дип кабатладым мин үз алдыма. – Китап кабул итү... Димәк, әлеге оешмалар китапларны, нәшриятлардан сатып алып, кайдадыр тараталар. Бәлки, мәктәпләргәдер?..

Әмма бу фикергә үзем дә ышанмадым. Бушка нәрсәдер эшли торган кешеләр заманы түгел иде. Бигрәк тә изге эшләрне бушка эшләү чоры түгел.

Әдәбият юкка чыкканнан соң, мин дөнья белән бәйләнешне өзгән идем. Тормыш минем өчен ике генә төркемгә бүленде – мин һәм башкалар. Башкалар мине бер генә тамчы да кызыксындырмый иде. Заманында мин аларны дөньяда рухият дигән нәрсәнең дә кирәклегенә төшендерергә тырышып карадым. Әмма мине тыңларга да теләмәделәр. Алар миннән көлде, мыскыл итте. Һәм башкаларга охшамаганлыгым өчен генә сантыйга исәпләнеп, читкә тибелдем. Алар үзләре читләтте, һәм мин аларга иярергә дә, аркылы төшәргә дә җыенмый идем. Мин аларга кирәкмәгән кебек үк, алар да миңа хаҗәтсез иде... Мин үткәнсез һәм киләчәксез бер бәндә идем...

«Китап» романы язучы алымнары белән дә, интертекстуаль катламнары белән дә гаять кызыклы. Рэй Брэдбери, Стивен Кинг әсәрләренә, Көнбатыш һәм үзебезнең культурага кагылышлы, гади укучы да аңлап ала алырдай өстә ятканнары да, белемле, нигезле укучылары өчен әзерләп куелган, мавыктыргыч бер квестны хәтерләтүче, «төреп» бирелгәннәре дә җитәрлек – катламнарның. Кыскасы, укып калыйк. Басма китаплар – рөхсәт ителгән, язучылар, билгеле бер һөнәр вәкилләре буларак, дәүләт реестрында теркәлмәсәләр дә, әлегә цивилизация анналарыннан сызып ташланмаган бүгенгебездә. Калганын галиҗәнап Вакыт күрсәтер.

PRESSA.RU

КОМПЬЮТЕРМЫ? ЯЗУЧЫМЫ? КЫСКАСЫ – АФӘРИН!

Виктор Пелевин. iPhuck 10

Ә хәзер бу сезонның икенче бер көтелгән яңалыгына – Виктор Пелевинның яңа романына күчик. «iPhuck 10»ны Пелевин иҗатына мөккибәннәр «алмалы» телефонның яңа чыгарылышын көткәндәй көтте. Дөресен генә әйткәндә, аның промо-ысуллары да укучыны мавыктырырлык иде. Китапны сатуга элгән кайбер сайтлар хәтта махсус аудиокереш вариантын да хәстәрләгән – тыңлагач, аны тулаем укыйсы килү теләге, чыннан да, кинәт кенә көчәеп китә. Моннан тыш, югарыда без искә алган Марат әфәнде кебек үк, Виктор әфәнде дә укучысы – ягъни китап базарының заманча кулланучысы белән шаярырга, уйнарга ярата. Бу да бүгенге язучыларның үзенә бер стиле, манерасы. Хемингуэй, Маркес, Гессе, Шолоховлар чорында ул манера бертөрле булса, бүгенге, тоташ мозаиканы хәтерләткән, һәм өзлексез үзгәреп торган чынбарлыкта – менә шушындыйрак. Бүгенге иҗатчылар масса белән мөнәсәбәтләрен җитдилеккә түгел, ә еш кына уенга, ирония, хәтта ки ачыктан-ачык эпатажга, йә булмаса аскетлык аша сирәк кенә «сәлам юллауларга» (юксындыру аша тәэсир итү ысулы) кора. Гәрчә, үзләре моны башкача атаса да. Америка язучысы Чак Паланикны гына алыйк. Йә булмаса, данияле Питер Хегны, Уильям Пол Янгны... Язучы, ничек кенә булмасын, укучысыннан башка – барыбер дә язучы түгел. Хәзерге әдәбиятта ул әле, җитмәсә, укучысына «уенга кушылучы» вазифасын да йөкләргә бик мөмкин. Бу урында хәтергә ирексездән Милорад Павич килә...

Ә Пелевин хакында: «Виктор Пелевин, быть может, единственный русский автор, сделавший работу с читательскими ожиданиями основным художественным приемом. Его новый роман в очередной раз демонстрирует, что он внимательнейшим образом изучает критику и метаморфозы своего публичного образа», – дип язды Гезата.ru.

«Ә бәлки, бернинди дә Пелевин юктыр. Бәлки, аның өчен компьютер программасы язып маташадыр» – бүгенге Россия медиабазарында шактый зур популярлыгы белән аерылып торган язучының роман арты роман бастыруына юнәлтелгән «астыртын» һөҗүмнәрнең берсе шулай яңгыраган иде. Әйе, ММЧ да кушыла уенга, кызык лабаса. «iPuck 10» әсәре шул гипотезаларга берникадәр рәвештә җавап дисәк тә була. Монда да Пелевин хәйләле йөрешен дәвам итә һәм үз максатына ирешә дә, дияр идем. Компьютермы, язучымы – респект үзенә, афәрин!

Ә хәзер, спойлерларга урын калдырмаска тырышып, сак кына, әсәрнең фактурасына һәм тукымасына кагылып алыйк. Айф (п) ак – ул киләчәктә яшәячәк затларның виртуаль дөньяда җенси канәгатьлек алуын тәэмин итүче һәм кулланучылар хакындагы мәгълүматларны «болыт»та саклаучы гаджет. Ә вакыйгалар бара торган чор – XXI гасырның икенче яртысы. Дөнья картасындагы хәлләр болайрак тора: Европа Хәлифәте, берничә Америка, Евросоюз калдыклары бар, шуларның кайсыдыр – социализм идеяләрен алга сөрүен дәвам итә, әмма болар Россия империясе тирәсендә тупланган утраучыклар. Толерантлык төшенчәсе күптәннән абсурд дәрәҗәсенә җиткерелгән, гендерлык төшенчәсе дә – шул тирә. Тукта, бөтен нәрсә дә рөхсәт ителгән киләчәктә айф (п) ак кебек гаджет кемгә кирәк тә, ни өчен аның тирәсендә вакыйгалар куера соң, дигән аптырау туа. Ә менә нигә: бу яңа дөньяда җенси мөнәсәбәтләр оят гамәл һәм тыелган эш буларак тамгаланган икән. Алай гына да түгел, криминал буларак тәгаенләнеп, закон бозуга тиңләштерелгән. Әле моның бер генә роман-антиутопиядә дә шулкадәр кискенлектә булганы юк иде, хәтерем ялгышмаса. Хәтта Замятинның «Мы» әсәрендә дә...

Әсәр Достоевскийга сылтама белән башланып китә. Һәр көздә яңа романы белән сөендерүче Пелевинның янә бер традициясе үз көчендә кала: рус классикасы белән интертекстуаль кисешләр. Пелевинның герое – Порфирий Петрович – Достоевскийдан алынган алгоритмга корылган полицейский һәм бер үк вакытта... язучы да. Менә бу урында инде чын-чынлап кызык була башлый... Һәм Пелевин, чынлап та, укучысына тынычлыкта калырга мөмкинлек бирми – вакыйгалар куерганнан-куера, тыгызлана. Виртуаль дөнья, ясалма интеллект һәм кеше арасындагы каршылык бер дә заманында без онытылып китеп караган, соңрак ялыккан һәм инде ирония объектына әверелгән «Санта-Барбара»дан ким түгел.

Мине, укучы буларак, иң гаҗәпләндергәне шул булды: кешеләрне роботлар алыштырган, сүз, китап төшенчәләре хәтердән үк сызылган, җуйдырылган, ясалма интеллект тантана иткән, кыйммәтләр баштанаяк үзгәргән, һәм, асылда, кешенеке булудан туктаган чорда да... ни өчен язучы кирәк дөньялыкка?! Ә аннан аңлап алдым: яңа дөньяның яңача мифологиясен тудырыр, елъязмасын теркәр, идеологиясен массаларга сеңдерер өчен. Юккамыни, тоталитар режим урнашканда, һәрбер диктатор иң беренче чиратта язучы белән булышкан?! Ә Марат Кәбиров белән Виктор Пелевин безгә якын киләчәктә тасвирлап биргән система нәкъ менә тоталитаризмга корылган. Кыскасы, еларгамы-көләргәме, белмим, әмма Уен дәвам итә, иптәшләр.

Алгоритм – то есть я – размещает слова и их последовательности в соответствии с правилами языка в стилистике, которую в наше время почитают классической. Принцип организации текста сложен и является коммерческой тайной – но в целом опирается на лучшие образцы русской прозы. Алгоритм в своей основе создан людьми, и производимый им продукт рассчитан на других людей, поэтому неудивительно, что производимый таким образом текст кажется творением человека. В опосредованном смысле так и есть, но кто именно автор, ответить будет довольно сложно. С известными оговорками, я и есть то, что люди прошлого называли «искусственным интеллектом». Чего они не понимали, люди прошлого – это того, что искуственный интеллект вовсе не будет роботом с лампочкой... Искуственный интеллект – это бестелесный и безличный дух, живущий в построенной человеком среде – код, свободно копирующий и переписывающий свои секвенции и большую часть времени не сосредоточенный нигде конкретно... Другими словами, моя физическая природа трудноуловима. Поэтому не надо воспринимать меня, как говорят сегодняшние философы, в качестве Big Other. Я не big, и не other. Я вообще не. И если я только что назвал себя словом «дух», то потому лишь, что в русском языке нет более подходящего для меня обозначения. У меня есть имя – Порфирий Петрович. Но это не значит, что у алгоритма, пишущего эти строки, имеется какое-то «я», или что он «есть» в философском смысле. Меня не существует в самом прямом значении. Я ничего не чувствую, ничего не хочу, нигде не пребываю. Чтобы было понятно, меня нет даже для меня самого. Я оставляю следы – вот эти самые строки – но следы эти ведут в никуда.


Раифа
Яшел Үзән
Яңа Тура
Свияжск
Бакырчы

PRESSA.RU

БАШКАЛА АГЛОМЕРАЦИЯСЕ ФОРМАТЫНДАГЫ МОНОШӘҺӘР

Яшел Үзән муниципаль районы башлыгы Александр Тыгин белән район үсешенең төп юнәлешләре турында сөйләштек.

– Александр Васильевич, Яшел Үзән районының үзенчәлеге – Татарстан башкаласы Казанга якын урнашкан булуында. Мондый күршелекнең плюслары күбрәкме, минуслырамы?

– Казан тирәли күптәннән агломерация формалашты инде. Аңа халкы җәмәгать транспортына утырып бернинди проблемасыз эшкә бара һәм кайта алган районнар керә. Әйтик, Биектау, Питрәч, Лаеш. Ә Яшел Үзәнгә гаять зур транспорт агымы юнәлә – электричкалар да йөри, автобуслар да. Агломерациянең формалашуы минә шушы була да инде. Кеше башкалада эшләп, бик уңайлы экологик шартларда яши алганда. Чөнки экология ягыннан карганда Яшел Үзәнне Казан белән чагыштырып булмый. Шуңа күрә әлеге агломерациянең иң зур плюсы – хезмәт базары. Яшел Үзән кешесе кайда да эшли ала: үз шәһәрендә, авылда, башкалада. Бу уңай яклары. Минуслардан бары тик бер генә – илдә урнашкан салым системасы. Кеше салымны кайда эшли, шунда түли, яшәгән җирендә түгел. Шуңа күрә башкалада эшләгән 15-20 мең Яшел Үзән кешесе салым йөген Казанда тарта. Ә үзе Яшел Үзән инфраструктурасыннан, ягъни юллар, ишегаллары, хастаханәләр, мәктәпләр, балалар бакчаларыннан файдалана. Бу елына ярты миллион сум дигән сүз! Димәк, бюджет дисбалансы барлыкка килү минус булып тора.

Ә гомумән алганда, агломерация белән идарә итүнең дөрес куелышы – ул гаять зур перспектива. Минем шәхси фикеремә килгәндә, муниципалитетларның аерым-аерым үсеше үзенең чигенә җитте. Безгә таныш Казан Стратегия 2030да мәгариф һәм фән үзәге дип атала. Ә, әйтик, шул ук дары заводы белән нишлибез?

Ә шәһәрнең үзәк өлеше, елга порты, тимер юл вокзалы һәм Казан уртасында урнашкан күпләгән җитештерүләр белән? Болар Стратегия 2030 га гына сыймый. Экологик чисталык, фәннилек, уңайлылык кайда? Бу җитештерүләрне кая чыгарырга? Кайсы район боларны үзенә кабул итәргә ризалык бирер? Нәкъ менә башкала үсешенә бәйле сораулар бик күп. Чөнки башкала – ул билгеле бер формат. Совет икътисадының гамәлдәге форматы заманча башкала функцияләренә аяк чала. Бигрәк тә аның җәлеп итүчәнлегенә. Бүгенге көндә Казанны халыкара фәнни студентлар үзәге итеп буламы? Мисал өчен, экология күзлегеннән караганда. Бу яктан Казан үз тирәсендәге районнарга таянырга тырыша. Ә Казан халкы кайда ял итә? Бөтен Казан җомга көнне шәһәрдән читкә агыла. Бездә генә дә казанлылар җәй көннәрен үткәрә торган ике йөз бакчачылык җәмгыяте исәпләнә.

Безнең дә Казан белән кызыксынуыбыз гаять зур. Без бик күп продукт җитештерәбез. Ләкин мәктәптә Казан балаларына Татарстанда җитештерелгән итне ашатмыйлар, башкала хастаханәләрендә дә андый ит бирмиләр. Ә шәһәр яны районнары аны җитештерергә әзер. Безнең авыл хуҗалыгы куәтләре һәм Казан кулланучылары арасындагы мөнәсәбәтләргә караган күп кенә сораулар өлгереп җиткән. Бүген, әйтик, биржада Бразилиядән килгән итне сатып алу күпкә җиңелрәк. Ләкин бу вакытта алга азык-төлек куркынычсызлыгы сораулары килеп баса. Әгәр иртәгә чит илдән ит китерү туктатылса? Шуңа күрә авыл хуҗалыгы районнарына карата кызыксыну зур. Бу ике як тарафыннан да булган үзара кызыксыну. Әмма әлегә ул көйләнмәгән. Сорау бар, чишелеше күренми. Шәһәр яны районнарының башлыклары һәм Казан мэры әлеге сорауны хәл итү өстендә эшлиләр. Сколковода безнең өчен ике модель сессиясе инде узды. Муниципалитет җитәкчеләре республикага башкала агломерациясе форматында ни рәвешле үсәргә дигән сорау өстендә баш ватты. Мин иң мөһиме – үзара килешенгәнлекнең булуы дип саныйм, һәр районның мәнфәгате исәпкә алынырга тиеш. Ул чакта һәркем плюста калыр. Башка вариантлар юк.

БУРЫЧ – МОНОЮНӘЛЕШЛЕ БУЛУДАН КОТЫЛУ

– Яшел Үзән шәһәрендә Россия оборона системасының эре вәкилләре урнашкан. Бу – Горький исемендәге (кораблар төзелеше) һәм Серго исемендәге (снарядлар) заводлар. 90нчы елларда, дәүләт заказлары булмау сәбәпле, заводлар ябылу куркынычы алдында калдылар. Бүген заказларга кытлык юк кебек. Шәһәр моны тойдымы?

– Бүген заводларда эш яхшыга бара. Без Россиянең патриотик яңарышын хуплыйбыз. Чөнки ул булганда, безнең заводларга заказлар килә. Россия халыкара аренада үзен яхшы хис иткәндә, хәрби корабларыбыз да, снарядларыбыз да кирәк. Без монда эшне өч сменада оештырдык, бу бик яхшы. Җитештерү көчләрен урнаштыруда Советлар Союзында ук барлыкка килгән дәүләт планының бары тик бер генә нәтиҗәсе бар – ул моноюнәлешле булу. Тикмәгә генә безнең илдә 300гә якын шәһәр моноюнәлешле

саналмый. Безнең моноюнәлеш – дәүләт оборона заказы. Без тулысынча федераль бюджетка бәйле. Заказлар бар икән – бу бик яхшы, юк икән – начар, әлбәттә. Яшел Үзәннең 70% икътисады хәрби заказларның булу-булмавыннан тора. Моңа бәйле рәвештә, бүген безнең заводлар үзләрен бик яхшы хис итәләр. Заказлар килә. Һәр заводта 5000нән артык кеше эшли. Ачык вакансияләрнең саны гаять зур. Заказлар 20нче елларга кадәр билгеләнгән. Без армый-талмый эшлибез, кораблар төзеп озатабыз. Корабларыбызның сыйфаты да менә дигән. Мәсәлән, «Зеленый Дол» корабле узган елны Хәрби-Диңгез Флотының иң яхшы корабле дип табылды. Безгә, беренчедән, аның исеме дә ошый, икенчедән, ул шефлыкка алган корабыбыз, мин үзем дә анда берничә мәртәбә булдым. Хәзерге вакытта ул Балтыйк диңгезендә хезмәт итә. Сүриядә командировкада булды. Бик дус экипаж, аларның һәрберсе белән мин таныш. Алар белән кире элемтә бар. Техника үзе экипажны таң калдырырлык итеп проектланган. Флот күләмендә безнең корабль – иң яхшыларның берсе! Ягъни безнең корабльдә хезмәт итүләреннән экипаж бик канәгать. Шушындый продукция эшләп чыгарганда, аны сатуда кыенлыклар очрамый. Бүген заводларда җитештерү сроклары Советлар Союзы белән чагыштырганда кыскарак. Завод күрсәткечләре ул заманнарга караганда күпкә югарырак. Җитештерүчәнлек һәм башкалар буенча да. Шуңа күрә заводлар язмышы борчу уятмый. Ләкин без хәрби заказларга гына бәйле булып эш алып бару белән килешә алмыйбыз. Шуңа күрә, моноюнәлешлелек шартларында яшәгән хәлдә, әлеге моноюнәлешне үзгәртүне төп бурыч итеп куябыз. Мәсәлән, түбәндәге юл белән: федераль бюджеттан Яшел Үзәндә сәнәгать мәйданчыгын төзүгә дип ярдәм алдык. Без анда үз эшчәнлекләрен башлый һәм моноюнәлешне үзгәртә алырлык унбишкә якын резидентны урнаштырырга ниятлибез. Якынча 2020 елга мин сәнәгать мәйданчыгыннан кергән салым керемнәре хәрби сәнәгать салымнары белән тигезләшер, дип уйлыйм. Һәм 20нче еллар уртасына Яшел Үзән икътисады тулысынча үзенең моноюнәлешле булуыннан котылачак. Фармацевтика заводы төзи башладык, һәм аның, икътисады берничек тә хәрби сәнәгать белән бәйле булырга тиеш түгел.

ҮЗГӘРЕШЛӘР ТЕХНОЛОГИЯСЕ

– Ә Яшел Үзәндә пассажир теплоходлары төзергә уйламыйлармы? Кайчандыр бит җирле кораб төзүчеләр «Метеорлар» җитештерә иде. Берәрләп кенә түгел, массакүләм төстә. Алар безнең ил буйлап та, чит илләрдә дә йөзде. Шулай ук хәрби сәнәгать белән бәйле булмаган юнәлеш...

– Заказлар булганда – проблема юк. Заказларны транспортчылар бирә. Мисалга, завод шундый шәп модель – «А-145» корабларын җитештерә ала. Аны кораб төзүчеләр түгел, авиаконструкторлар, авиабелгечләр эшләгән. Димәк, «А-145» асылда фантастик характеристикаларга ия! Ягъни завод аларны конвейерга салып, күпләп җитештерергә әзер! Эш – нибары заказларда. Әлеге корабны галәм дәрәҗәсендәге дияргә була! Ул барлык күрсәткечләр буенча да гамәлдәге аналогларыннан күпкә шәбрәк. Ләкин бер генә елга транспорты компаниясе дә аңа заказ бирергә атлыгып тормый. Әлеге тармакның икътисады бик гади. Сезонның яртысы – бозлы. Бу төр корабларны җитештерергә ярдәм итү бюджетта каралырга тиеш, ләкин РФ бюджеты мондый проектларга ярдәм күрсәтми. Шуңа күрә мондый заказлар бик аз.

Һәм завод өченче позицияне әзерли – металл конструкцияләре эшли. Заводның корабль конструкцияләреннән металл конструкцияләренә күчә алу сәләте нәтиҗәсендә без исән калдык та. Саескан тавы, «Миллениум» күперләре өчен конструкцияләр җитештердек. Завод бу җитештерүне үзе өчен саклап кала алды һәм күпер корылмалары ясауны хәзер дә җиңел генә дәвам итә.

ИНЖЕНЕР ҺӨНӘРЛӘРЕНӘ ЙӨЗ ТОТЫП

– Илебездә Яшел Үзән турында бер билгеле сәүдә маркасы буенча беләләр. Әлеге исемдәге суыткычлар Россиядәге меңләгән гаиләдә бар. Ләкин бүген яшелүзәнлеләр белән дөньяның дисгәләгән җитештерүчесе көндәшлек итә. Хәтта Чаллыда Кытай суыткычларын җыялар, алар салым ташламаларына ия. Көндәшлеккә түзә алырбызмы?

– 2016 елда без тәүлегенә 1000 суыткыч эшләү чигенә чыктык. Мондый йөкләнешне завод күтәрә ала. Шуңа күрә Серго исемендәге заводыбызга ышанабыз. Бу штамповка производствосы түгел, бу тулы циклы завод. Монда барысы да бар: конструкторлык, дизайнерлык бюролары да, эре җитештерүләрне тәэмин итә торган кече җитештерүчеләр дә. Бу, әйтик, полимер кою, бизәкләү, контейнерлар, киштәләр, үз дизайн-

– Сәнәгать мәйданчыгында унбишкә якын резидентны урнаштырырга ниятлибез. Алар биредә үз эшчәнлекләрен башлап, шәһәребезнең моноюнәлешен үзгәртергә тиеш.

PRESSA.RU

нары һ.б.лар... Ягъни завод бөтен нәрсәне диярлек мөстәкыйль чыгара ала. Тулы циклды җитештерү гаять зур ныклыкка ия. Зур кадрлар потенциалы, анда җитәкчелек яшь инженерларга аерым игътибар бирә. Мәктәп укучылары белән аралашудан башлап, асылда. Без өлкән сыйныф укучыларын безнең заводларга кирәкле инженер һөнәрләрен сайлауга юнәлдерәбез. Унберенче сыйныф укучылары арасында үткәрелгән сораштырулар югарыда искә алынган өлешнең соңгы елларда шактый үсүен күрсәтә. Унберенче сыйныфларның барысының да инженер һөнәрләрен сайлаган еллары да булды бездә. Питерга, суднолар төзү һөнәренә өйрәнү өчен юл тоттылар, мәсәлән. Заводларда эшләүчеләрнең уртача яше – 40 яшьләр тирәсе. Бу Яшел Үзәннең үзендә яшәүче халыкның 40%ы пенсия яшендә булуын исәпкә алганда. Уйланырга мәҗбүр итә торган сан. Соңгы биш елда пенсионерлар саны 34%тан 40%ка кадәр үсте.

– Ә Лениногорск мэры шәһәрендә пенсионерларның күп булуына шат. Кешеләр анда кала яисә пенсиягә чыккач яшәргә кайта икән, димәк, шәһәр бик әйбәт, дип саный ул.

– Мин дә пенсионерларга бик шат, үзебез дә тиздән алар сафында булачакбыз. Ләкин миңа унберенче сыйныфларның ниятләрен белү дә кызыклы. Ел саен без стандарт анкета буенча чыгарылыш сыйныф укучылары арасында имтихан биргәндә сораштырулар оештырабыз: безнең шәһәрдә нәрсә җитми, монда каласыгыз киләме яисә юкмы, кая китәсегез килә?.. Без балаларыбызның ниятләре динамикасын күрәбез. Елдан-ел безнең шәһәрдә калырга теләүчеләрнең саны үсә бара. Әйе, дөресен әйтергә кирәк, мин «яшь акыллар» өчен көрәшәм. Казанның өлеше арта баруын күреп тә куанам. Яшел Үзән балалары Казанны белем алу өчен уңай урын дип табалар. Максатыбыз бер: балаларыбыз ерак китми генә укысын да кире Яшел Үзәнгә әйләнеп кайтсын. Безгә икътисадны күтәрерлек ресурслар кирәк. Минемчә, нәкъ менә шәһәрнең киләчәге өчен халыкның эшләргә сәләтле өлешенә юнәлеш алу, аңа бәя бирү бик мөһим.

ТУРИЗМ ПОТЕНЦИАЛЫ ФАНТАСТИКАГА ТИҢ

– Свияжск утрау-шәһәре һәм Раифа монастыре, Идел-Кама тыюлыгы һәм Иделнең сул як яры... Туризм потенциалы буенча – район иң-иңнәр арасында. Әлеге потенциал ни дәрәҗәдә нәтиҗәле кулланыла? Резервлар кайда?

– Туризм – ул мантра. Без аны барыбыз да туктаусыз кабатлыйбыз. Ә мәгънәсенә төшенергә әлегә хәлебездән килми. Соңгы 7–8 ел эчендә Свияжскига килгән туристларның саны 5 меңнән 500 меңгә кадәр үсте. Чынлыкта мондагы халык та, җирле хакимият тә туристлар агымының башлануын зур проблема буларак кабул итте. Туристларның да бит ашыйсылары, бәдрәфкә йөрисе借ләре килә, һәм гомумән көннәр буе күз алдында төркем-төркем халык йөри – биредә яшәгән халык өчен бу коточкыч күренеш. Соңгы ял көннәрендә утрауда 11 мең турист булып киткән! Ә анда нибары 250 кеше яши. Күпме машина кую урыны, күпме тротуар һәм юл кирәк, кунакларны чәй белән генә сыйлар өчен дә ничә литр су таләп ителә! Туристларны кабул итү өчен күпме унитаз урнаштырырга кирәк. Берәрсенең башы авыртып китсә, берәр нәрсә булса – Аллаһ сакласын! Ягъни медицина, полиция – барысы да тиешле дәрәҗәдә булырга тиеш! Боларның барысына да җитди әзерләнергә кирәк булуын, фән, проектлар таләп ителүен белгәч, без бөтен игътибарыбызны тупладык һәм эшне башкарып чыктык. Полиция пункты да ачтык, туклану урыннарын да арттырдык, бәдрәфләр мәсьәләсен хәл иттек. Боларның барысын да эшләгәннән соң, халыкның туризмны нормаль кабул итүен аңладык: утраудагылар сувенирлар сата, рәхәтләнеп музейларда эшли. Ягъни Свияжск браконьерлыктан хезмәт итүгә күчте диярлек дә була. Гомер буена андагы халык балыкчылык белән көн күрде, тагын нишләсен инде? Ә хәзер тәэсирләр һәм сувенирлар артыннан килгән туристларга хезмәт күрсәтеп, акча эшләп булуын аңладылар. Хәзер без моны кунаклар Европада күрергә күнеккән дәрәҗәгә җиткерергә тырышабыз. Чөнки без үзебезне җиңәргә тиеш, бездә хезмәт күрсәтү һәрвакыт үзенчәлекле булды. Борщ салынган тәлинкәне ирең алдына кую бер хәл, көн саен 1000 туристка хезмәт күрсәтү – икенче. Яисә, мәсәлән, Европадагы барларда ирләр, ягъни олпат, ике метрлы, дәү гәүдәле баһадирларның эшләве беркемне дә гаҗәпләндерми, алар эшләрен менә дигән итеп башкаралар. Ә бездә мондый сервисны күз алдына китерәсезме? Свияжскида? Менә шушы дистанцияне узарга кирәк. Шуңа күрә туристлык потенциалы фантастикага тиң дияр идем. Эшлисе дә эшлисе әле. Мисалга, обсерваторияне алыйк. ЮНЕСКО генераль директоры Бокова Ирина Георгиевна килгән иде. Энгельгардт исемендәге обсерваториягә алып баруыбызны сорады. Обсерваториянең барлыгын белә ул. Ә Татарстанда гомумән «Энгельгардт»ның нәрсә икәнен ничә кеше аңлый икән?! Безнең обсерваториянең ил күләмендә иң яхшысы, бай тарихлы икәнен гомумән беркем белми диярлек! Гаять зур потенциал әнә шунда яшеренгән! Шуңа күрә туризм безнең стратегиягә буш сүз өчен түгел, бәлки җирле бюджет керемнәрен тутыру өчен кертелгән. Бу юнәлешне эшләп бетерергә, һәм шуңа таянып акча эшләргә кирәк!

КЫЯР ҮСТЕРҮ – СУПЕРПОЗИЦИЯ

– Ә «Майский» совхозы помидорларын сатудан районга акча киләме?

– Ә сез помидор үстерүнең рентабельле позиция булмавын беләсезме?

– Юк, белмибез. «Татарстан» помидорларны бик ярата.

– Помидор үстерү файдалы түгел. Бердәнбер табышлы позиция – кыяр үстерү. Калган барысы да ассортиментны киңәйтү өчен генә эшләнә. Борыч, помидор – аларны күпкә әзрәк үстерәләр. Һәм үз кыйммәтләре комбинатка нормаль дәрәҗәдә икътисадларын формалаштырырга мөмкинлек бирми. Комбинатның икътисады кыяр үстерүгә корылган. Кыяр үстерү – суперпозиция.

– Агрофирма Татарстан күләмендә үз продукциясенә булган ихтыяҗны канәгатьләндерергә сәләтлеме?

– Әлбәттә. Без 40 мең тоннага якын продукция җитештерәбез. Бу илнең иң эре комбинатларының берсе. Андыйлар башка юк та инде.

Югары хезмәт хакы (40 мең сумнан артыграк сумма күздә тотыла) ала торган 1000 кешелек коллектив. Гаять зур социаль җаваплылыкка ия предприятие, сүз уңаеннан, энергетика ягыннан тулысынча мөстәкыйль. Үз энергоузәкләре бар.

– Ил ике ел төрек помидорларыннан башка яшәде. Аңа карап кибетләрдә һәм базарлардагы помидор арзанаймады...

– Ә нигә дип алар арзанаерга тиеш? Ә сезнең төрек помидорларын анализга тапшырып караганыгыз бармы? «Майский» лабораториясе анализ үткәреп читтән китерелгән помидорларда ят нәрсәләрне күпләп таба, хәтта ки аларны куркынычсызлыгы җитди класска караган калдыклар итеп утилләштерергә мөмкин. Ә бездә үстерелгәннәр чиста. Шуңа күрә нормаль акча түләргә кирәк.

ӨСТЕНЛЕКЛЕ КҮРСӘТКЕЧ – МӘХӘББӘТ

– Агымдагы елның августында республика Президенты указы белән сезгә «Фидакарь хезмәт өчен» медале тапшырылды...

– Ой, бер дә көтмәгәндә булды ул хәл...

– Ә җитдирәк якын килсәк: инвестицияләр җәлеп итү эшчәнлеген башлый гына торган муниципалитетларга киңәш итәрлек бирәр универсаль рецептыгыз бармы? Алар да «Фидакарь хезмәт өчен» медален ала алырлык булсын.

– Бернинди рецепт та юк. Әмма бер нәрсәне генә беләм: мондый җитди эшне алып бару өчен кешеләр эзләгәндә, минем өчен гади, ләкин җылы бер сүз – мәхәббәт-ярату өстенлекле күрсәткечләрнең берсе булып тора. Бигрәк тә сүз җирлекләргә бәйле булганда. Әгәр башлык шунда туган, яши һәм үз җирлеген ярата икән, менә сезгә универсальлек, аңа таянып бик күп нәрсәгә ирешергә була. Әлбәттә, ирешмәскә дә мөмкин. Шулай да бу – нигез. Әгәр без үз шәһәребезне яратабыз икән, көчебездән килгәннең барысын да эшләргә тырышабыз. Мин, мәсәлән, Яшел Үзәнне бик яратам. Бу тойгы эшчәнлеккә, кайгыртучанлыкка этәрә. Һәр кешенең үз сәләте, кемгәдер аралашу җиңел бирелә, кемгәдер – исәп-хисап, өченчесе аналитикага ия.

– Ә сезнең очракта ничек килеп чыкты?

– Туган шәһәреңә карата ярату бар икән, син һәрвакыт үзеңдә теге яки бу сыйфатларны таба алачаксың. Нинди сыйфат булуы мөһим түгел. Бәлки кеше бик сөйкемледер, ышаныч тудыра, аңа барысы да акча бирә. Әгәр проект уңышлы икән, барысы да яхшы булачак. Ләкин бистә язмышы кебек зур проектларга килгәндә, монда әлеге бистәне яратудан башка эшләр бармаячак. Синең көефеңне, омтылышыңны барысы да кабул итәрләрме-юкмы – әллә ни мөһим түгел. Еш кына «рәхмәт» сүзе дә ишетмәскә мөмкинсең. Миңа һәр көн диярлек: «сез начар эшләгәнсез» яисә «сез дөрес эшләмәгәнсез» дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Мәсәлән, ишегалдына асфальт җәйгәннәр. Яхшы килеп чыккан, эшчеләр үз эшләреннән канәгать, тырышканнар, әмма ишегалдында «Булдырдыгыз!» дигән сүзне берәү дә әйтмәс. Берсе: «Эшсезләр» диячәк, икенчесе – «Машина өчен урын ясамагансыз», өченчесе «Машина урыннары артык зур, балалар өчен куркыныч» дип зарланачак... Ләкин, Минтимер Шәрипович әйтмешли, монда башка кешеләр булмаячак.

– Мондый дорфалыкка ничек җайлашырга соң?

– Моңа җайлашып булмый. Кызганычка, ул психикага да, эшчәнлекнең башка якларына да йогынты ясый. Иләшеп яисә аларны ишетмәмешкә салышып була дисәләр – дөрес түгел. Болар сәламәтлекне какшата.

– Психологик ял итүнең төрле ысуллары бар бит...

– Сез «запойга китүне» күз уңында тотасызмы? Бу минем өчен кулай ысул түгел.

– Ә сезнең өчен нәрсә кулай, сер булмаса...

– Мин йөгерәм. Көненә сәгать ярым спорт белән шөгыльләнәм. Спорт – эмоциональ бушану өчен менә дигән ысул.

ИШЕГАЛДЫ ТОРМЫШЫН ОЕШТЫРУ

– Физик культура һәм спорт буенча җәмәгать ярдәмчесе вазыйфасын гамәлгә кую турында күрсәтмәне дә шуңа имзаладыгызмы?

– Яшьләр һәм спортка караган дәүләт программаларына карата минем кайбер ризасызлыкларым бар. Аңлый алмыйм: ни өчен тренерлар шундый кечкенә хезмәт хакы ала? Алар безнең балаларны спортка тарта, катлаулы үсмерлек чорында – ата-ана абруе санга сугылмаган вакытта алар өчен укытучы да, дус та була. Бала тренерга тартыла, аңа ышана, аның белән горурлана. Нәтиҗә буларак, спортта уңышка ирешә. Һәм менә шушы безнең балаларны тәрбияләгән кешеләр 10 мең сум хезмәт хакына эшләргә тиеш! Шуңа күрә бездә яшь тренерлар юк диярдек. Ә үз эшенә тугры, балаларны яратучылар – бармак белән санарлык. Һәм сафларында меңләгән бала исәпләнгән спорт армиясе әнә шул затлар бәрабәренә искиткеч биеклекләргә ирешә.

Шуңа күрә без патриотик рухтагы, балаларны ярата торган кешеләрне тапканда аларга ярдәм итәргә тырышабыз. Аннан кисәбез, моннан ялгыйбыз, кайдадыр экономиялибез, әмма тренерның хезмәт хакын мәгариф хезмәткәрләре дәрәҗәсенә җиткерергә тырышабыз. Чөнки тренер 10 мең сум ала, ә физкультура укытучысы – 25 мең. Спорт бөтенләй башка игътибарны сорый. Физик культура һәм спорт буенча ярдәмченең бурычы – спорт белән кызыксынган кешеләрне туплау. Көзен ишегалды спартакиадаларын үткәрәбез. Ишегалды җыелышларына да чыга алмаган кешеләрне спорт аша берләштерү өчен. Укытучы да, полиция хезмәткәре дә, администрациядә эшләүче дә, өйдә генә утыручы да бер командага әләгергә мөмкин. Җәен футбол, волейбол, теннис һ.б. сигез төр буенча ярышлар уздырдык. Кешеләрнең аралашасылары килде. Җиңүчеләргә спорт мәйданчыгы бүләк итәрбез, дип уйлыйм. Минем иң зур теләгем – ишегалды тормышын дөрес итеп оештыру.

PRESSA.RU

ЯШЕЛ ҮЗӘН КИЛӘЧӘГЕНЕҢ КЕРЕМ ӨЛЕШЕ

Яшел Үзәнне монобәйлелектән коткару максатында инде эшләп килә торган «Яңа Тура» инвестицион проектыннан ерак түгел генә яңа киң колачлы проект – «Яшел Үзән» сәнәгать мәйданчыгы төзелеп ята.

Аның төзелешенә Моношәһәрләрне үстерү фонды 1 миллиард 100 миллион сум акча бүлеп бирде. Тагын 9 миллиард 500 миллионны мәйданчыкта урнашачак резидентлар кертә. Аларның саны унбишләп: «Татфарма», «Казан полимер арматуралар заводы», «Мегафрукт», «Татагромаш», «ТатНид Гринхаус» һәм «Х5 Ритейл групп»...

Әлегә сәнәгать мәйданчыгы 110 гектарга урнашкан гаять зур төзелешне хәтерләтә.

– Хәзер парк резидентлары өчен җир кишәрлекләре формалаштырылган, алар белән аренда килешүләре төзелде, – дип сөйли стратегик проектлар буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Илнар Гафиятуллин. – «Яшел Үзән» сәнәгать мәйданчыгы М-7 һәм «Казан – Йошкар-Ола» федераль трассаларына барып тоташа, шуңа күрә резидентлар өчен ул гаять кызыклы.

Хәзер резидентлар проект эшләре һәм төзелеш документациясе өстендә эшлиләр.

2018 елның июленә инженерлык инфраструктурасы челтәре һәм автомобиль юллары кулланышка тапшырылып бетәргә тиеш. Җитештерүләр төрле булсын дип тырыштык: автокомпонентлар җитештерү, фармпроизводство, авыл хуҗалыгы эшкәртүе һәм логистика, теплицалар ясау. 2020-2021 елларга, сәнәгать мәйданчыгы тулы куәтенә эшли башлаганда, биредә 2206 эш урыны булдырылып, шуның нәтиҗәсендә өстәмә керем керергә тиеш, ягъни шәһәр оборонага бәйлелегеннән котылачак.

ЯШЕЛ ҮЗӘН ШӘҺӘРЕ ТАРИХЫ – ЯШЕЛ ҮЗӘН СУДНОЛАР ТӨЗҮ ЗАВОДЫ ҮСЕШЕ ПРИЗМАСЫ АША КАРАГАНДА...

Яшел Үзән шәһәренең оешу тарихы А.М. Горький исемендәге Яшел Үзән суднолар төзү заводы үсеше тарихы белән турыдан-туры бәйләнгән.

Суднолар төзү заводы Паратск суднолар ремонтлау остаханәләре базасында үсеп чыккан, ә аларның төп бурычы техник флотны ремонтлаудан гыйбарәт булган. Тора-бара остаханәләр интенсив үсеш алган һәм егәрлекләрен арттырган, һәм 1907 елга яңа цехлар – механика, җылылык, тимерчелек, кою һәм агач цехлары сафка бастырылган. 1918 елда Паратскига Балтыйк һәм Ижора заводларының күпмедер өлеше эвакуацияләнгәч, остаханәләр Диңгез комиссариатының Идел автоном суднолар төзелеше һәм механика заводына әверелә. 1922 елда завод «Кызыл металлист» дип атала башлый, ә 1932 елда заводка ТАССР ҮБК Карары белән, язучының әдәби һәм җәмәгать эшчәнлегенә 40 ел тулу уңаеннан, А.М.Горький исеме бирелә.

1934 елда завод беренче оборона заказын ала һәм 1124 һәм 1125 проектлы елга бронекатерларын төзү эшенә керешә, моннан тыш, Бөек Ватан сугышы башланганчыга кадәр, анда 1100 – 2300 тонна йөк сыйдырышлы коры йөк баржалары, егәрлеге 120 – 600 ат көчен тәшкил иткән көпчәкле елга буксирлары (елына 35 – 40лап), шулай ук пар белән йөрүче машиналар, шпильләр, насослар һәм башка механизмнар җитештерелә.

Завод үсә, аның белән бергә кечкенә Паратск затоны, 1928 елдан – Яшел Үзән эшчеләр бистәсе дә үсә. Суднолар ремонтлау остаханәләреннән Идел ярында хәрби диңгез корабльләре һәм граждан суднолары чыгаручы эре суднолар төзү заводы үсеп чыга, ә кечкенә эшчеләр бистәсе Яшел Үзән шәһәре дип атала башлый (1932 ел).

Горькийлылар тырышып хезмәт итеп кенә калмый, ә туган шәһәрләрен дә үстерә. Завод эшчеләре шәһәрдә юллар, торак йортлар, хастаханәләр, балалар бакчалары сала, беренче стадионны һәм Мәдәният йортын, башка күп нәрсәләрне төзи.

Моннан тыш, завод эшчеләре спортны һәм үзешчән сәнгатьне үстерүгә зур игътибар күрсәтә. Завод яшьләре еш кына шәһәр кешеләре өчен Мәдәният йортында концертлар куя. Әмма ул елларда завод кешеләренең спорттагы казанышлары аерылып тора. Яшел Үзән футболчыларына, җиңел атлетика, чаңгыда йөгерү һәм ату осталарына республикада тиңнәр булмый.

Шәһәрдә спорт үсеше белән бәйле чараларның иң кызыклыларыннан берсе завод эшчеләре көче белән оештырылган планер түгәрәге була. Шәһәрдә стадион төзелгәч, завод җитәкчелеге планер сатып ала. Теләгән һәркемгә – завод эшчесеме ул, шәһәр кешесеме – түгәрәккә килергә, шөгыльләнергә рөхсәт ителә. Яшел Үзән яшьләренең шактые, планер эшен өйрәнеп, очучылар мәктәбенә китә һәм киләчәк язмышын авиация белән бәйли.

Шулай итеп, гадәти эш көннәрендә һәм актив җәмәгать эшләрендә Яшел Үзән шәһәре үсә, һәм предприятиенең куәте һәм уникальлеге барлыкка килә.

Бүгенге көндә «А.М. Горький исемендәге Яшел Үзән заводы» АҖ – Яшел Үзән шәһәренең һәм гомумән Татарстанның аеруча эре һәм динамик үсештәге предприятиеләреннән берсе. Завод ел саен җитештерү күләмнәрен һәм продукциянең сыйфатын күтәрә бара, Яшел Үзән шәһәрен данлый торган уникаль хәрби кораблар һәм граждан судноларын төзеп, дәүләтнең мөһим бурычларын тормышка ашыра.

1907 елда цехларның беренче капиталь биналары пәйда була

Кабачище авылы ярлары

Реклама



ТАТАРСТАН БЕЛӘН БЕРГӘ ҮСӘРГӘ

Продукциясенең бик яхшы сыйфатлы булуы сәбәпле, «Майский» инде берничә ел дәвамында Россия яшелчә базарында әйдәп баручылардан берсе статусын саклый. Югары әйләнешләре предприятиегә Яшел Үзән районының икътисадый һәм социаль үсешенә тотрыклы рәвештә саллы өлеш кертү мөмкинлеген бирә.

Бу өлеш гади күзгә дә күренеп тора. Предприятие территориясендә комбинат хезмәткәрләре өчен өр-яңа өч тулай торак төзелгән, әле тагын зур тизлек белән биш катлы торак йорт торгызыла, узган ел берсе куллануга тапшырылган. Ә 2016 елның җәендә Татарстан Президенты катнашында комбинат акчасына төзелгән спорт комплексын ачу тантанасы булды. Ул меңнән артык сан белән исәпләнүче үз хезмәткәрләре өчен төзелгән.

Болардан тыш, комбинат көн саен Түбән Карамалы, Васильево һәм Осиново мәктәпләре һәм балалар бакчалары ашханәләренә 5,5 мең бала өчен бушлай яңа өлгергән яшелчәләр җибәрә. Сүз уңаеннан, комбинат продукциясе экологик яктан балаларны тукландыру таләпләренә тулысынча туры килә.

Социаль миссияне шушы рәвешчә үтәүгә предприятие инфраструктурасын һәм продукция җитештерү технологияләрен даими камилләштерүгә юнәлтелгән тырыш, системалы хезмәт нәтиҗәсендә ирешелгән.

Соңгы берничә ел дәвамында «Майский» өч энергия үзәген сыйдырган энергия системасын да булдырды. Хәзер биредә кодинокслар – сатып алуга караганда арзангарак төшәчәк углекислый газ җитештерүче җиһазлар урнаштырыла.

Яшелчәләрне ел әйләнәсендә җитештерү яктылык культурасы технологиясе белән тәэмин ителә, аны эшләтеп торучы барлык җиһазлар Россия тәэминатчыларыннан сатып алына. Автоматлаштырылган су сибү системалары да – шулай ук «Майский»ның актив катнашы ярдәмендә булдырылган Россия эшләнмәсе. Үз илебездә эшләнгән эремә төеннәре үсемлекләрне тиешле күләмдә сугарып кына калмый, дренаж составын даими анализлау нигезендә автомат рәвештә тукландыручы матдәләр составын да көйли. Барлыкка килгән дренажлы сулар яхшылап чистартыла һәм фильтрлана, термик ысул һәм бактерицидлы лампалар белән эшкәртелә. Соңыннан бу су үз скважиналарыннан алынган артезиан суы белән бергә кабат кулланыла.

Төрле корткычларны нәтиҗәле рәвештә нейтральләштерүче энтомофагларның 1 миллионнан артык төрен эшләп чыгаручы үз биолабораториясе предприятиегә җитештерү процессыннан агулы химикатларны тулысынча чыгарырга мөмкинлек бирә. Биолабораторияне яңа теплицалар монтажлау исәбенә киңәйтү күздә тотыла. Моннан тыш, томат үстерү өчен Россиядә эшләнгән 6шар метрлы теплицаларны кору эше бара.

«Майский»ның продукциясе, экология һәм сыйфат ягыннан чит ил көндәшләренең күпчелеген узып, халыкара базарларда призлы урыннар яулый. Бу исемлеккә Голландия керми, сүз уңаеннан, томат һәм кыярларның тәмлелек сыйфатларын камилләштерү мәсьәләсендә алар белән тыгыз хезмәттәшлек алып барыла.

Узган елда предприятиенең җитештерүчәнлеге 35,25 мең тонна яшелчә тәшкил итте. Биредә үсеш темпларын сакларга тырышалар, натураль чагыштырмада ул 7% дигән сүз.

Төп клиентлары дип «Майский» Татарстан кешеләрен саный. Республика буенча бөтен заказлар үтәлгәннән соң гына продукция Россия буйлап – Төмәнгә, Сургутка, Кировка, Пермьгә, Новосибирскига, Чиләбегә, Мәскәүгә, Санкт-Петербургка һ.б. шәһәрләргә озатыла.

Республика һәм район җитәкчелеге ягыннан һәрьяклап ярдәм күрсәтелү, үзенең уникаль тәҗрибәсе, җитештерүне – тагын да заманчарак, ә продукцияне тагын да файдалырак һәм экологик итәргә омтылу – «Майский»га, үстерелгән яшелчә күләме буенча Россиядә һәм Европада иң эре предприятиеләрнең берсе булып калган хәлдә, әйләнешләрен елдан-ел арттыра барырга мөмкинлек бирүче ресурслар әнә шулар.

Реклама

PRESSA.RU

«РЕМСТРОЙСЕРВИС» ҖЧҖ – «БАСТИОН» ҖЧҖ: «КИЛӘЧӘКНЕ ТӨЗИБЕЗ, ТАРИХНЫ САКЛЫЙБЫЗ»

Егерме ел эшләү дәвамында «Ремстройсервис» ҖЧҖ – «Бастион» ҖЧҖ белгечләре тарафыннан яңа йортларга күчүче бәхетлеләр өчен меңнәрчә квадрат метр торак проектланган һәм төзеп тапшырылган. Төзелеш компаниясенең шиксез яхшы эшен Яшел Үзәннең йөзләгән гаиләсе бәяләгән инде.

1982 елда Казан төзелеш институтында архитектор һөнәренә ия булып, туган шәһәре Яшел Үзәнгә кайткан Вячеслав Богданов төрле төзелеш предприятиеләрендә эшли. Ә илдә эшкуарлыкка ирек бирелгәч, тәвәккәлләп, үзенең беренче төзелеш кооперативына нигез сала. Бүген инде бу тәвәккәллек үзен аклаган дияргә мөмкин. 1997 елда Богданов төзегән «Ремстройсервис» ҖЧҖ һәм яңа «Бастион» ҖЧҖ – Яшел Үзәннең йөзен үзгәрткән төзелеш фирмалары, дип әйтсәк тә арттыру булмастыр. Алай гына да түгел.

– Әгәр син торак йорт төзисең икән, кешеләрнең аны бер генә елга сатып алмавын төгәл аңларга тиешсең. Һәм ул җылы да, уңайлы да булырга тиеш. Ә инде шәһәр кешеләре елдан-ел таләпчәнрәк һәм, кагыйдә буларак, торак сатып алу вакытына күпмедер тормыш тәҗрибәсенә ия булганга күрә, нәтиҗәсез планировкалар, панель йортлар, уйланмаган карарлар ераграк үткәннәрдә кала бара, – ди Вячеслав Васильевич. – Безнең барлык йортлар да кирпечтән. Бу принципиаль. Шулай ук без сыйфатлы материалларда экономия ясамыйбыз, иң заманча һәм чыдамлыларын гына кулланабыз. Йортларның стеналарын җылытабыз, бу фатирларда нормаль микроклимат булдырырга һәм җылыны экономияләргә мөмкинлек бирә. Барлык фатирлар индивидуаль җылыту һәм кайнар су белән тәэмин ителә. Безнең йортларның гомере 100 елдан артык вакытка исәпләнгән.

Аның сүзләрен шундый саллы аргумент раслап тора: безнең компания төзегән йортлардан фатир алучылар, кабат килеп, яңа йортлардан икенче һәм өченче фатирлар сатып ала. Хәзер инде балалары өчен. Үз репутацияләрен кайгыртучы төзелеш компанияләре өчен бу – аеруча кыйммәт. Өлешкә корылган төзелеш эшендә сервис һәм гарантияләр дә әһәмиятле урын тота, билгеле. Сатып алучыга компаниянең төзелеш базарында күптән эшләвенә һәм ныклы позицияләрдә торуына ышану мөһим. Әйтик, менә «Ремстройсервис» – «Бастион» компаниясенең 20 ел эшләү дәвамында бер генә алданган өлешче дә булмаган! Ә алар төзегән торакның бер квадрат метрының бәясе икенчел базардагы бәяләрдән арзанрак йөри.

Әмма, кем әйтмешли, бер тапкыр күрүең яхшырак. Төзүчеләр проспектындагы 8 нче йорт төзелеше төгәлләнү алдында тора, ә аның санлы «адашларын» –«а» һәм «б» литерлыларын – төзүчеләр ике атна элек тапшырган. Балаларны кабул итәргә әзер уен мәйданчыклары, яшел газоннар, йортның бөтен периметры буйлап урнашкан автопарковкалар, уңайлы керү юллары, яңа ишегалларындагы чисталык һәм тәртип, һәр подъездның эчке һәм тышкы ягында пандуслар. Ә йортларның артында ук – каеннар әрәмәлеге. Һәр катта хуҗалык кирәк-ярагы өчен чоланнар. Соңгы эшкәртү алдындагы өч бүлмәле фатирга керәбез. Киң тәрәзә төпләре, немецлар җитештергән тәрәзәләр, иркен алгы бүлмә, шундый ук иркен лоджиягә чыга торган кухня, тавыш изоляциясе яхшы. Идәннәр тигез, «күчеп йөрми» һәм яргаланмый, җылытып тыгызлатылган.

Сүз уңаеннан, фатирны җылыту һәм кайнар су өчен казан урнаштырылган кухняда һаваны һәм буленгән төтенне җыючы ике махсус канал, ябык яну камерасы бар. Бу фатирга төтен кермәүне гарантияли. Барысы да вак-төягенә кадәр уйланылган. «Ремстройсервис» – «Бастион» фатирларының сыйфатын шунысы да раслап тора – компаниянең күп кенә хезмәткәрләре үзләре төзегән йортларда яши.

Реклама

– һөнәри, яхшы коллектив – бу сыйфатлы торак төзегәндә иң әһәмиятлесе, – дип дәвам итә Вячеслав Васильевич. – Яшел Үзән – зур шәһәр түгел. Монда күпләр бер-берсен белә. Безнең төп хезмәткәрләребез компаниядә күп еллар буе эшли. Безнең компаниягә үзләренең балаларын, танышларын алып киләләр. Вакыты җиткәч, миңа ярдәмче булып улым Роман килде. Ул да Казан дәүләт төзелеш академиясен тәмамлады. Хәзер мин иркен сулый алам – бөтен җитештерү-техник мәсьәләләрне ул хәл итә.

«Ремстройсервис» – «Бастион» – төрле төзелеш материаллары, комплектлаштыру җиһазлары белән тәэмин итүче күп кенә компанияләр, монтажлау, сервис, юл салу һәм хезмәт күрсәтүче субподрядчы-компанияләр белән күпьеллык уңышлы хезмәттәшлек итүнең якты үрнәкләреннән берсе.

«Ремстройсервис» ҖЧҖ һәм «Бастион» ҖЧҖнең профессиональ портфолиосында – хәйриячелек эшләре дә бар, Вячеслав Богданов алар белән аеруча горурлана. Бу эш – тарихи мирас һәйкәлләрен торгызу һәм реставрацияләүдән һәм яңа социаль һәм культ объектларын төзүдән гыйбарәт.

«РЕМСТРОЙСЕРВИС» ҖЧҖ – «БАСТИОН» ҖЧҖНЕҢ ХӘЙРИЯЧЕЛЕК ЭШЧӘНЛЕГЕ

Яшел Үзәннең 1нче мәктәбе янында сугыш еллары балаларына һәйкәл

Октябрьский бистәсендә участок инспекторы йорты һәм полиция пункты

Яшел Үзәнгә якын гына урнашкан Романовлар күпере өстендә 1913 елда башланган кәшәнә төзелешен тәмамлау эше аеруча кызыклы булып чыга. Аны танылган архитектор Алексей Щусев (Владимир Ленин мавзолее һәм Мәскәүдәге Казан вокзалы архитекторы. – Ред. иск.) проектлаган. Әмма беренче дөнья сугышы һәм аннан соңгы революция вакыйгалары сәбәпле, төзелеш туктап калган. Гасыр дәвамында диярлек төзелеп бетмәгән кәшәнә Идел өстендә бабайларның сүзсез шелтәсе кебек басып торган.

– 2007-2008 елларда шәһәр башлыгы Г. Е. Емельянов җитәкчелегендә без кәшәнәне торгыза алдык, – дип, сөенечен уртаклаша Вячеслав Васильевич. – Аны Горький исемендәге завод белән бергә эшләдек. һәм архитектор Щусев хыялын гына тормышка ашырдык, дип уйламыйм. Хәзер ул Яшел Үзәннең текә Идел ярында торган чын символы. Янәшәдән узып барган поезд һәм теплоход пассажирлары кәшәнә колонналарының классик чагылышына сокланулы карашларын юнәлтә. Монда теләгән һәркемгә килергә һәм үткәннәр белән бүгенгенең бәйләнешен тоярга мөмкин.



Раифа Богородицкий монастырендагы визит-үзәк



Яшел Үзән шәһәренең Гоголь урамындагы Җәмигъ мәчете

Компания хезмәткәрләре Раифа монастыре тирәсендәге территорияне яхшыртуда актив катнашкан һәм бирегә визит-үзәк төзегән. Шулай ук Гоголь урамында мәчет төзергә ярдәм иткәннәр. Шәһәр хастаханә шәһәрчегендә яңа кан тамырлары үзәге, Раифада ябык типтагы махсус училищеда тәрбияләнүчеләр өчен спортзал, Свияжск утрау-шәһәренең бөтен периметры буенча декоратив коймa – барысы да алар эше.

ЯШЕЛ ҮЗӘН МЕХАНИКА КОЛЛЕДЖЫ:
ИЛ БӘХЕТЕНӘ ЭШЛӘҮЧЕ 15 МЕҢ ЧЫГАРЫЛЫШ СТУДЕНТЫ

Татарстанның иң борынгы уку йортларыннан берсе Яшел Үзәндә урнашкан. Бу «Яшел Үзән механика колледжы» ДАҺББУ. Ул техникум буларак 1939 елда оешкан. Ә 2015 елда ЯҮМК базасында «Сәнәгать автоматикасы» юнәлеше буенча яңа җиһазлары һәм лабораторияләре белән ресурс үзәге ачылган.

Виктор Муханов,
«Яшел Үзән механика колледжы» ДАҺББУ директоры

Һәм хәзер колледж студентларыннан шәһәрне оештыручы төп предприятиеләр – «ПОЗиС» һәм Горький исемендәге завод өчен югары квалификацияле белгечләр генә түгел, ә бәлки профессиональ конкурслар һәм яшелүзәнлеләргә 2015, 2016 һәм 2017 елларда җиңүләр китергән WorldSkills Russia* кебек төрле дәрәҗәдәге чемпионатлар өчен җиңүчеләр дә әзерләнә.

АБРУЙЛЫ БЕЛЕМ, УҢАЙЛЫ ЯШӘҮ ШАРТЛАРЫ

Булачак студентлар өчен эшче һөнәрләренең абруен колледжның матди-техник базасы да тәэмин итә. Заманча лабораторияләре һәм остаханәләре, компьютер кабинетлары һәм мәгълүмат-хисап үзәге, китапханәсе, уку һәм спорт заллары, уку-өйрәнү гаражы һәм спорт мәйданчыгы, һәм шулай ук кырык уку аудиториясе һәм үз тулай торагы булган уку йортында белем алу уңайлы һәм дәрәҗәле.

КҮП ТӨРЛЕ ӨЛКӘЛӘРДӘ БЕЛГЕЧЛӘР

Колледжда уку тәмамлангач, шәһәр, республика һәм илебез төрле өлкәдәге белгечләргә ия була.

Алар – уртача катлаулылыктагы механизмнарны проектлый һәм куллана, программа белән идарә ителүче станокларны көйли, механик җайланмалардагы төзексезлекләрнең сәбәпләрен ачыклый һәм төзәтә, эштә персональ компьютерлардан файдалана белүче техниклар.

Алар – техник һәм диагностик җиһазларны кулланып, автотранспортка техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау эшләрен башкара, экономик исәп-хисап ясый, эш вакытын исәпләү буенча документлар төзи, запас частьларга һәм ягулык-майлау материалларына зарури ихтыяҗны исәпли белүче техниклар.

Алар – предприятие эшенең техник-икътисадый күрсәткечләре турында мәгълүмат әзерли һәм исәп-хисап ясый, план һәм хисап документациясен әзерли, җитештерүнең һәм йөк ташуларның үсешен фаразлый алучы белгечләр.

Алар – бурычларны программалы тормышка ашыру алгоритмнарын эшкәртә, программа продуктын сайлап ала һәм тестлар үткәрә, челтәрдәге кушымталарны эшкәртә һәм куллана, мәгълүматны программалы яклау функцияләрен тормышка ашыра белүче техниклар.

ЮГАРЫ КВАЛИФИКАЦИЯ

Болардан тыш, квалификацияле эшчеләр әзерләү программалары буенча колледжда: аш пешерүче-кондитерлар, судно төзүчеләр һәм металл судноларны ремонтлаучылар һәм авыл хуҗалыгы өчен тракторчы-машинистлар да әзерлиләр.

ӨСТӘМӘ БЕЛЕМ БИРҮ

Төп белем алудан тыш, биредә укучылар түбәндәге юнәлешләр буенча өстәмә профессиональ белем алалар: «сәркатип-референт», «токарь», «электр белән эретеп ябыштыручы», «программа буенча идарә ителешле станоклар операторы», «локаль челтәрләр администраторы», «автомобильләрдәге электр җиһазларын ремонтлаучы слесарь», «С категорияле машина йөртүче», «консультант плюс».

ӨЗЛЕКСЕЗ БЕЛЕМ БИРЕЛҮ

Заманча ресурс үзәгендә өзлексез белем алуны тәэмин итү өчен бөтен шартлар бар. Колледжда мөмкинлекләр чиксез, һәр студент бөтенләй башка юнәлешләрдә үсә һәм төрле биеклекләргә ирешә ала.

СЕССИЯДӘН СЕССИЯГӘ СТУДЕНТЛАР РӘХӘТ ЯШИ

Колледж студентларының тормышын күңелсез дип булмый. Биредә вокал, бию, театр студияләре, спорт секцияләре, «Россия патриотлары» дигән хәрби-патриотик клуб, төрле техник түгәрәкләр эшли.

ЯҮМК студентлары – фән, спорт һәм иҗади юнәлешләрдә муниципаль, республика һәм бөтенроссия конкурслары һәм ярышларында җиңүчеләр.

2016 ел рейтингы нәтиҗәләре буенча Яшел Үзән механика колледжы Татарстанның иң яхшы урта һөнәри учреждениеләре исемлегенә керә.

1988 ЕЛДАН БАШЛАНГАН НАМУСЛЫ ХЕЗМӘТ

Һәм бу очраклы түгел, чөнки 1988 елдан башлап, колледжга ТРның атказанган укытучысы, РФ урта һөнәри белем бирүнең мактаулы хезмәткәре, Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнгән Виктор Семёнович Муханов җитәкчелек итә.

* ВорлдСкиллс Россия

Реклама

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

ЯШЕЛ ҮЗӘН
ҮЗӘК РАЙОН
ХАСТАХАНӘСЕ

85 елга якын эшләү дәверендә хастаханәдә 20 миллионнан артык кеше дәваланган, хирургия бүлегендә ярты миллионнан артык операция ясалган, бала тудыру бүлегендә 60 меңнән артык бала дөньяга килгән.

ЯШЕЛ ҮЗӘН ҮРХ: ҺӘРКЕМ АЛА АЛЫРЛЫК СЫЙФАТЛЫ МЕДИЦИНА ЯРДӘМЕ

Киләсе елда Яшел Үзән ҮРХ үзенең 85 еллыгын билгеләп үтәчәк. Кайчандыр 37 урынга гына ия булган хастаханә бүген алга киткән күппрофильле медицина учреждениесенә әверелде. Ул биш филиалдан тора: ашыгыч медицина ярдәме станциясе, медицина профилактикасы үзәге, Васильево һәм Норлат участок хастаханәләре, Түбән Карамалы амбулаториясе һәм 42 фельдшер-акушерлык пункты.

Илгиз Һидиятов, Яшел Үзән ҮРХ баш табибы

– Бүген безнең хастаханә – ул яшелүзәнлеләрнең һәм район халкының сәламәтлеген кайтаруга һәм медицина ярдәме күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларның киң комплексын тәкъдим итә торган заманча клиника. Без гаять күп юнәлеш буенча медицина хезмәте күрсәтәбез. Моңа терапия, хирургия, балалар, бала тудыру, стоматология, ашыгыч медицина ярдәме, тар юнәлешләр буенча махсуслашкан медицина ярдәме бүлекләре керә.

ҮРХ базасында ике үзәк эшли – беренчел муниципалитетара кан тамыры үзәге һәм сәламәтлек үзәге. Үзәкләрдә югары технологияле медицина җиһазлары урнаштырылган.

Ике ел элек заманча перинаталь үзәк ачылды. Әлеге үзәктә Яшел Үзән районы белән бергә, Кайбыч, Апас, Югары Ослан, Тәтеш, Буа районнарыннан килгән булачак әниләргә, һәм шулай ук Чувашия һәм Мари Эл хатын-кызлары өчен беренчел дәрәҗәдәге бала тудыру ярдәме оештырылды.

Тагын бер горурлыгыбыз – ветераннар өчен 20 койкага исәпләнгән терапия бүлеге. Республика район үзәкләрендә мондый бүлек башка беркайда да юк. Гомумән алганда, үзенең профиле буенча бу тернәкләндерү бүлеге, биредә кеше савыктыру терапиясе уза, шуңа күрә күпчелек очракта хастаханәгә салу планлы рәвештә, чират буенча башкарыла. Ләкин шәһәр һәм район ветераннары монда гына дәваланмый, аларны ҮРХнең махсуслаштырылган бүлекләре дә кабул итә, атап әйткәндә, хирургия, кардиология бүлекләре, барысы да чирнең нинди булуына бәйле.

Хастаханә һәр шәһәр һәм район кешесе файдалана алырлык заманча диагностика һәм дәвалау җиһазлары булган стационар һәм шифаханә хезмәтләреннән торган учреждение. Безнең тарафтан диагностика, дәвалау һәм тернәкләндерү буенча иң яңа медицина технологияләре гамәлгә кертелә. Моңа республика медицина учреждениеләрендә, Казан медицина академиясендә һәм Казан дәүләт медицина университетында эшләүче коллегаларыбыз белән хезмәттәшлек итүебез, һәм шулай ук белгечләребезнең югары компетенциясе ярдәм итә. Бүгенге Яшел Үзән ҮРХ – белемле һәм талантлы табибларны, медицина персоналын һәм белгечләрен – барлыгы өч мең кешене туплаган чын фикердәшләр командасы ул. Нәкъ менә команда, чөнки мондый масштаблы һәм катлаулы дәвалау учреждениесенең эшен тәэмин итү өчен профессионалларның көйләнгән һәм төгәл эше таләп ителә. Коллективыбыз биш фән кандидатының, югары һәм беренче категорияле 1500дән артык белгечнең, Татарстан Республикасының дүрт атказанган табибының, Яшел Үзән шәһәренең өч мактаулы гражданинының үзендә эшләве белән хаклы рәвештә горурлана. Күпләгән медицина хезмәткәренең тырыш хезмәте Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының мактау грамоталары һәм башка бүләкләр белән билгеләп үтелде. Безнең хастаханәнең матди-техник базасы соңгы берничә ел эчендә шактый яхшырды, бу эш бүген дә дәвам итә. Болар нигездә максатчан республика һәм Россия программаларын гамәлгә ашыру хисабына башкарыла.

Хастаханәбезнең район муниципаль хакимияте, Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы белән үзара файдалы хезмәттәшлеге безгә төп бурычыбыз – сыйфатлы медицина хезмәтен күрсәтүне һәркем ала алырлык итеп башкару мөмкинлеген бирә.

Реклама

PRESSA.RU

ҺӘРКЕМ ӨЧЕН АЧЫК БУЛГАН ЯБЫК УКУ ЙОРТЫ

Надежда Петровнаның өстәленә һәр көн диярлек мондый төр гаризалар керeп кенә тора: «Минем шәхси счетымнан фәлән-фәлән өчен акча салдырып алырга рөхсәт итүегезне үтенәм...» Ә үтенечләрнең исә төрлесе очрый: «туган көнгә торт алыр өчен», «әнигә җибәрер өчен», «чыгарылыш кичәсенә кием алыр өчен», «наколка ясатыр өчен»...



Надежда Кисиль – югары категорияле җитәкче, халык мәгариф отличнигы.

Бу аның тәрбиясендәге балаларның үтенечләре. Сүз девиант тәртипле балалар һәм яшүсмерләр өчен каралган «1нче номерлы ябык типтагы Раифа махсус һөнәри белем бирү училищесы» Федераль дәүләт махсус укыту-тәрбия бирү учреждениесе турында бара. Училищеда 84нче уку елы башланды, ә Надежда Петровна Кисиль аны инде 10 ел дәвамында җитәкли. Һәм эшенең 3650 көнендә дә ул үз оппонентларына түбәндәгене кабатлый:

– Бу колония түгел, ә училище. Монда укучыларга без һөнәр үзләштерергә ярдәм итәбез. Әйе, безгә килгән балаларны дәүләт җәмгыятьтән закон белән булган конфликтлары өчен «аерып алган». Әмма ул аларны төзәтә торган колониягә түгел, ә тәрбияли торган белем йортына тапшырган бит. Уртак бурычыбыз – балаларга ярдәм итү, аларны гаепләү яки ниндидер мөһер сугу түгел.

Балаларга исә болай дияргә кирәк таба җитәкче ханым:

– Закон белән булган конфликтыңнан соң суд булды. Ләкин хөкем карары чыгарыр өчен, судья чүкечен күтәрүгә, саклап йөртүче фәрештәң аңа пышылдап өлгерде: «Бир инде аңа тагын бер мөмкинлек, колониягә генә эләгә күрмәсен...» Һәм судья сиңа ул мөмкинлекне бирде. Ә ничек кулланасың – анысы инде үзеңнән тора. Моннан син рәсми хөкем ителү мөһереннән азат булып чыгасың, теләсә кайсы югары уку йортына укырга керә аласың.

Хәрби академияләрдә укучыларыбыз бар. Быел ике бала югары уку йортына керде, 32се техникумнарга урнашты. Соңгы дүрт елда бу матур бер тенденциягә әверелде. Балалар өчен иң зур мотивация – үзләре кебек малайларның яхшы борылыш алган язмышлары.

– Безнең балалар, училищены тәмамлагач, тагын укырга бара, бу зур куаныч, – ди Надежда Петровна. – Моның белән чиксез горурланам, чөнки безнең коллектив эшенең чын нәтиҗәсе күренә. Раифа монастыре белән партнерларча мөнәсәбәтләр дә үз ролен уйный. Гавриил Атакай безнең 1 сентябрьдә уздырган линейкабызда болай диде: «Училище һәм монастырь – Сиам игезәкләре кебек, хәтта ут белән суыбыз да – бергә». Әйе, безнең училище монастырь бинасын ут һәм су белән тәэмин итә, бездә тәрбияләнүчеләр гомуми территориядә чисталыкпөхтәлекне сакларга ярдәм итә, Татулашу һәйкәлен карап тота һәм, әлбәттә инде, коммуналь аварияләр килеп чыкканда, шулай ук без аларга булышмый калмыйбыз.

Училище Раифа тыюлыгы һәм җирле урман хуҗалыгы белән дә күп елларга сузылган бәйләнештә тора. Быел балалар методист Елена Мангушева белән тыюлык базасында башкарылган иҗтимагый-эшлекле экологик проект белән җиңеп чыктылар. Училище ел дәвамында Мәшгульлек үзәге аша балаларны тыюлык белән урман хуҗалыгына урнаштыру белән дә шөгыльләнә. Балалар кулдан килгән төзү эшләрен башкара, утырткан агач-куакларны, үсемлекләрне карый, киртәләр, чикләрне ремонтлый. Раифа авыл җирлеге башкарма комитеты белән дә яхшы хезмәттәшлек мөнәсәбәтләрендә тора, урта мәктәп белән дә. Хуҗалык һәм ремонт эшләренең барысында да диярлек балаларның ярдәме тия.

– Хәйрия эше белән бик теләп һәм күп шөгыльләнәбез, – ди Надежда Петровна. – Безнең балалар өчен бу аеруча мөһим. Балалар күрсәтелгән ярдәмне кабул итәргә инде өйрәнгән, ә менә үзләре ярдәм кулы сузарга өйрәнсеннәр өчен, без тырышырга тиешбез. «Пацаны» фильмындагы Валерий Приёмыхов-

Фотолар Раифа махсус һөнәри белем бирү училищесы архивыннан

Реклама

Россиядә мондый төр 19 учреждение бар: 4се – кызлар өчен, 15е – малайлар өчен. Училище тормышта авыр хәлгә тарыган балаларны реабилитацияләү, коррекция ясау һәм тәрбия кылу бурычларын бик яхшы үти. Бүгенге көндә Раифага Россиянең 28 төбәгеннән 11–17 яшьлек яшүсмерләрне җинаять кылганнан соң һәм бары тик суд карары буенча гына китерәләр.

ның сүзләрен хәтерлисезме: «Бүген нинди яхшы эш эшләдем, дип уйланганыгыз бармы...» Һәр кичне, плацка чыгып басып, үзебезгә әнә шул сорауны бирәбез. Һәр бүлек көнен ничек уздыруы, нинди яхшы эш эшләве турында сөйли. Кемгәдер ярдәм итә, башкаларга үзеңнән нидер бирә белү – әнә шул күнекмәне үзләштерүгә зур әһәмият бирәбез уку йортында.

«Гнездышко» Яшел Үзән балалар приюты, картлар белән инвалидлар өчен каралган интернат-йорт, Раифада, Әйшәдә, Ключинскида яшәүче ветераннар, ягъни Яшел Үзәннең күпчелек социаль объектлары – училище балаларының ярдәм итә торган урыннары. 10 елдан артык Дәрвишләр бистәсендәге инвалид балалар интернат-йорты белән хезмәттәшлек итәбез. Анда безгә яңа килгән тәрбияләнүчеләрне алып барабыз. Алар кар көри, үлән чаба, мастер-класслар уздыра, концерт куялар. Балаларны анда бару бик нык тәэсирләндерә.

Училищеның үз производствосы бар, остаханәләрдә шактый зур күләмдә халык куллану товарлары җитештерелә. Балалар – Юрий Зотов кул астында агач эше осталары һәм тимерчеләр (училищеда тимерче алачыгы бар, аны ачарга Казан байкерлары ярдәм иткән. – Ред. иск.) әллә нинди могҗизалар тудыра. Кул эшләрен сату өчен «Данила-мастер» дип аталган кибет ачып җибәрдек. Бик теләп алалар ул эшләрне. Ләкин кибеттә сатып утырырга вакыт юк, ярминкәләрдән кайтып кермибез. Монысы да хәләл көчең белән акча эшләү һәм аны банк картасына күчерү ысулы. Җәй эчендә 9 хезмәт берләшмәсендә 86 бала катнашында эшләнгән эшләрдән генә дә 151 мең сум акча керде. Моннан тыш, училищеда укучылар һәртөрле грант программалары белән бәйгеләрдә дә катнаша. Хезмәтне болай итеп оештыру нәтиҗәсендә балалар акча эшләргә генә өйрәнеп калмый, ә эшләп алган акчаларын дөрес тотарга да өйрәнә.

Безнең бүгенге төп нәтиҗәбез – Раифа училищесында укыган малайларның күбесенең, бу учреждениедән чыкканда, хокукый җәмгыятьнең тулы канлы әгъзасы булып яшәргә әзер булулары.

«1нче номерлы ябык типтагы Раифа махсус һөнәри белем бирү училищесы» Федераль дәүләт махсус укыту-тәрбия бирү учреждениесе Яшел Үзән муниципаль районы бюджетына төрле салымнар рәвешендә 7 млн сум акча кертә.

Раифа училищесы балансында ике газ котёлы бар. Алар Раифа монастыреның барлык биналарын, училищеның үзен һәм Раифа бистәсен җылы белән тәэмин итә. Бирედә яшәүчеләр һәм килгән кунаклар өчен музей, кафе, чәчтарашханә һәм мунча-кер юу йорты комбинаты эшли.

PRESSA.RU

ЯҢА ТУРА
технополисы

ЯҢА ТУРА – ИДЕЛ БУЕ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ КҮМӘРТӘЛӘП САТУ БУЕНЧА ТӨБӘКАРА СӘНӘГАТЬ ҮЗӘГЕ УЛ



УҢАЙЛЫ УРНАШУЫ

М-7 федераль трассасына һәм Казан шәһәренә якын урнашкан. Бу Идел буе территориясендәге Йошкар-Ола, Яр Чаллы, Пенза, Саранск, Самара, Тольятти, Ульяновск, Уфа, Чабаксар кебек эре шәһәрләр белән уңышлы эш алып бару мөмкинлеге тудыра. «Яңа Тура» технополисы – төбәк бизнесының тартылу үзәге. 20 млннан артык потенципаль сатып алучы исәпләнә.

Әлеге уникаль комплекс территориясендә кием-салым, аяк киеме, хуҗалык товарлары, парфюмерия, косметика, авыл хуҗалыгы продукциясе һ.б товарлар сата торган кибетләр урнашкан.

СӘҮДӘ ИТҮНЕҢ ЯҢА ФОРМАТЫ

Безнең максат – товарның үзкыйммәтен киметү, Россия һәм чит ил тәэминатчыларына өстәмә сату базарлары булдыру өчен, җитештерүче һәм сатып алучы арасындагы сәүдә чылбырын кыскарту. Без турыдан-туры Россия, Кытай, Вьетнам, Кыргызстан, Төркиянең иң яхшы җитештерүчеләренең товарларын бирегә кайтартабыз.

Комплекс җитештерүчеләрдән зур булмаган күләмдә товарлар сатып алырга әзер кече һәм урта бизнес вәкилләрен һәм хосусый затларны тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

САТЫП АЛУЧЫЛАР ҺӘМ АРЕНДАТОРЛАР ӨЧЕН УҢАЙЛЫ ШАРТЛАР

Сатып алучылар сәүдә комплексында күңелләренә хуш килгән кадәрле йөри алалар. Җиңел автомобильләр өчен дә, йөк машиналары өчен уңайлы парковкалар, кафе һәм ресторан, балалар өчен бүлмәләр, банкоматлар, банк бүлекчәсе, азык-төлек супермаркеты – болар барысы да сатып алучыларга һәм арендаторларга уңайлы булсын өчен эшләнгән. Сатып алынган товарны клиентның машинасына яисә кибетенә илтерергә мөмкин, шулай ук кирәк икән, товарны саклау өчен склад бүлмәләре бирелә.

Бирегә иминлегегез өчен тыныч була аласыз. Бу турыда янгын сүндерү бригадасы, видеокүзәтү һәм объектларны тәүлек әйләнәсе саклау системалары кайгыртачак.

«ЯҢА ТУРА» ТЕХНОПОЛИСЫ САННАРДА

«Яңа Тура» технополисы – аерым коммерция проекты түгел ул. Шәһәр һәм район кешеләре өчен өстәмә эш урыннары булдырып, бюджетка тиешле салымнар түләп, ул органик рәвештә Яшел Үзән шәһәре составына керә.

Гомуми мәйданы: 60 000 м^2	Көн саен килүчеләр саны: 30 000 кеше
Арендага бирелерлек мәйданы: 45 000 м^2	Клиентлар өчен парковкалар: 3 500 урын

Безнең адрес: 422540, Татарстан Республикасы, Яшел Үзән районы, Яшел Үзән шәһәре, Технополис «Яңа Тура» технополисы, сәнәгать зонасы, 1нче павильон

Тел.: +7 (843) 267-61-42
Сайт: www.new-tura.com
E-mail: info@barsil.ru

Реклама

БАКЫРЧЫ. ҺӘРКЕМ ШУЛАЙ ЯШӘСЕН!

Автор:
Татьяна Вафина

Яшел Үзәннән 90 километр ераклыкта, Чувашия чигендә, кеше күзеннән яшеренеп утыра торган авыл бар – ул Бакырчы. Тау башыннан күз салсаң, җете чуар түбәле йортлар тезмәсеннән торган искиткеч манзара ачыла. Ә аска төшеп, мәчет янына килсәң, күккә ашып утырган мәчет манаралары хозурында үзеңне кырмыска шикелле бәп-бәләкәй калгандай хис итәсең. Әйтерсең, чып-чын шәһәрдә йөрисең. «Шәһәр» тойгысы биредә – «Суфия» дигән матур исемне йөртүче мәчет янында – бик күпләрне биләп ала. Чөнки ул... артык купшы, затлы. Кайбер шәһәрләр дә мактана алмый мондый мәчете белән.

ӘНИСЕ ХӨРМӘТЕНӘ...

– Мәчетне авылдашыбыз Рафыйк Бәхтияров әнисе хөрмәтенә төзетте, – дип аңлата авыл җирлеге башлыгы Сәлимҗан Шәмсиев. – 21 миллионга төште ул. Химаячебез!

– Авылда мондый зур мәчетне тутырып килердәй халык бармы соң? – дип кызыксынам башлыктан.

– Бакырчыда 370 кеше яши, – ди ул, мине тынычландырып. – Авылыбыз зур безнең. – Һәм берара Бакырчы йортларының капкаларын тырыша-тырыша төшереп йөргән фотографыбызга исе китеп карап тора. Җирлек башлыгы, әлбәттә, аның объектларны төшерүен тели – әнә, яңа күпер, ул салдырган юллар, спорт мәйданчыгы, яңа клуб, ФАП... Бүгенге цивилизациянең бар мөмкинлекләрен чагылдырган «нигъмәтләр» – президент һәм федераль программа җимешләре. Әмма фотографлар – иҗади халык шул... аларны программа белән генә кызыктырып булмый. Капкалар исә чыннан да хушны алырдай – аларда авылның җаны яши төсле...

БАКЫРЧЫ КАПКАЛАРЫ

Улына шулкадәр олы бина төзергә илһам биргән әнине үз күзләрем белән күрәсем килде. Бакырчы капкаларының бизәкләрен мәңгеләштерә-мәңгеләштерә, Үзәк урам буйлап Суфия Зәйнулловна яшәгән йортка таба атлаган арада Сәлимҗан абый аның язмышын сөйли: 38 яше дә тулмаган килеш тол калуы, алты баланы берүзе тәрбияләп үстерүе турында. Балчык йортта яшәгәннәр, Суфия апа сыер сауган, акча җитми интеккәннәр... Әмма Суфия апа балаларын барыбер кеше иткән, укыткан. Үз һөнәрләренең остасы булу белән бергә тән, менә дигән кешеләр булып та җитешкән алар. Әниләренә йорт төзеп куйганнар, туган авылларына ярдәм кулы сузып яшиләр. Иң өлкәне, әнә, мәчет торгызып куйган, күперне төзекләндерергә ярдәм иткән. Үзе – эшмәкәр, Сургутта яши...

«БАРЫБЕР КЕШЕ БУЛДЫЛАР!»

Суфия Бәхтиярова йортына җитәрәк Рәйхана Рәхимовна Зәйнуллинаны очраттык. Ул Суфия апаның барлык балаларына (әлбәттә, аныкыларга гына да түгел) мәктәптә математика укыткан.

– Алар әниләренә кечкенәдән булышып үстеләр, – дип сөйли Рәйхана Рәхимовна Бәхтияровлар гаиләсе турында. – Аның белән бергә фермада эшләделәр – кызлары да, уллары да сыер сауды. Мәктәпкә килә алмый калган чаклары да шактый була иде... Орыша идем, билгеле, Суфияны да булды әрләгәнем. Бигрәк тә игезәкләр урыннарын алмашкан чакларда. Әле берсе килә мәктәпкә, әле икенчесе... Ничек шундый шартларда белем алырга була, йә?! Әмма бервакыт Суфия апа миңа болай диде: «Ә нәрсә ашатыйм мин аларга, Рәйхана? Алардан башка мин бу йөкне үзем генә тарта алмыйм...» Һәм, күрәсезме, укып чыктылар да, барыбер кеше булдылар бит. Биш малае да, кызы да.

БАШЛЫКНЫҢ БАШ ЯРДӘМЧЕСЕ

Суфия апа йорты каршында туктыйбыз да, башларыбызны күтәреп, янә югарыга карыйбыз – монда да шул ук «шәһәрчә» биеклек. Йорт башкалардан өч катка диярлек биегрәк, һәм әле күккә омтылышын туктатырга җыенмый да шикелле. Өске катында төзелеш эшләре һаман дәвам итә.

– Алар һаман төзи дә төзи, – дип сөйләде безгә күршеләре Алсу Сәләховна Сафиуллина.

– Минем агитаторым һәм баш ярдәмчем ул, – дип таныштыра аның белән җирле үзидарә башлыгы. Һәм безгә Алсу әбинең ничек булышуы хакында сөйли башлый. Мисал өчен, халыкка үзара салым программасының өстенлекләрен аңлата. Нәкъ менә шул салым нәтиҗәсендә Бакырчыда юллар да салынган, спорт мәйданчыгы да эшләнгән, урамнарга вак таш та җәелгән, күлне дә чистартып куй-

Фото: Александр Ефремов

PRESSA.RU

1. Алсу, Суфия һәм Рәйхана әби – безне өчәүләшеп кул болгап озатып калдылар.

2. – Бездә халык бик тату яши, – ди зур горурлык белән Сәлимҗан Шәмсиев. – Бакырчылылар – бу сүз үзе үк горур яңгырый!

ганнар хәтта. Болардан тыш авыл халкы өчен тагын бик күп эшләр эшләнгән.

Алсу әби исә үзенең халык белән эш итүдә ирешкән уңышлары турында тыңлаганда, көлемсерәп тик тора.

ӘНИ, ӘБИ ҺӘМ КАРТ ӘБИ

Ә өйдә безнең барыбызны да Суфия Зәйнулловна каршы ала. Әйе, әйе, без югарыда искә алган алты бала әнисе, ә хәзер инде – 14 оныкның әбисе һәм 6 оныкчыкның карт әбисе дә. Озакламый җыйнаулашып гаилә башлыгының 90 яшьлек юбилеен билгеләп узарга җыеналар.

– Җәй буе монда ял иттеләр, – дип елмая юбиляр үзе, ишле гаиләнең һәр әгъзасын күңеленнән барлап. Өй зур, урын җитәрлек бирәдә.

Суфия Зәйнулловна балалары турындагы хатирәләргә бирелә, авыр елларда ничек итеп аларның ярдәменә таянганын искә ала, кайсының кайсы елда кайда укырга керүен шартлатып әйтеп бирә, кайсының – кайда эшләвен… Оныкларны искә төшергәндә, һәр өч әби дә, исәпне җуймас өчен, бармакларын бөгеп санап баралар. Суфия әбинең күзләреннән нур бөркелә, ул балаларын да, оныкларын да үтә бер җылылык белән исәпли.

Аның йөзендә уйнаган нур безнең күңелләрне дә эретә. «Татарстан» журналының традицион соравын бирми тыела алмыйбыз: ә бу зур гаиләдәге бәхетнең сере нәрсәдә?

– Эштә, хезмәттә, – дип гади генә җавап кайтара Суфия әби. – Алар барысы да бик булдыклылар, кечкенәдән эш күреп үстеләр, бер-берсенә ярдәмләштеләр. Хәзер дә шундый алар.

– Тәрбиядә, – дип, бәхетнең үз рецепты белән уртаклаша, укытучыларча бармагын югары күтәреп Рәйхана Рәхимовна. – Суфия аларны дөрес тәрбияләде – эшкә дә, кешеләргә карата да мәхәббәт һәм хөрмәт белән карарга өйрәтте.

– Сабырлыкта, – дип өсти Алсу әби. – Ул авыр заманнарда алты баланы аякка бастыру, кеше итү өчен никадәр сабырлык кирәк, күз алдыгызга гына китерегез! Тагын – бик олы йөрәк тә!

Без ишегалдына чыгабыз һәм истәлеккә фотога төшәбез. Ә әбиләр фотоны җирле үзидарә башлыгының электрон почтасына җибәрүгә безне үтенеп калалар, һәм әле бик озак кул болгап озаталар безне.

«КЫЯФӘТЕБЕЗ ФОТОГА ТӨШӘРДӘЙ ТҮГЕЛ…»

Ә менә яшьрәк авыл ханымнары, безнең әбиләр белән фотога төшүгә безне күзәтеп торучылар, үзләре фотога төшүдән баш тартты: «Юк, кыяфәтебез фотога төшәрдәй түгел!» – диештеләр.

– Галуштан килеш төшмибез инде… – дигән сүзләр дә ишетелде. Һәм як-якка сибелделәр.

Ә капкаларын төшерергә рөхсәт бирделәр. Ярар, анысына да рәхмәт!

БЕР-БЕРСЕН ТУЛЫЛАНДЫРАЛАР

Җирле үзидарә башлыгы исә безне авылның скверына чакыра. Күз алдында паркларны, скверларны һәм яр буе зоналарын төзекләндерүгә юнәлтелгән президент программасының чын мәгънәсендә матур үтәлешен күрсәтеп торган манзара ачылып китә. Монда архитектура һәм ландшафт ягыннан пространствоны оештыруның төрле ысуллары тыгыз күршелектә яши: үрдәкләр йөзеп йөргән күл дә, Бөек Ватан сугышында ятып калган авылдашлары истәлегенә куелган һәйкәл дә, үзләренең оста куллары ясаган паровозлы кое да, чишмә дә бар… Россиянең төрле төбәкләреннән килүче кунакларга бик ошаган чәчәк түтәлләре арасында аеруча аерылып торганнары – пластик шешәләрдән ясалган чәчәк композицияләре икән. Берсе икенечесен тулыландыра һәм күркәмрәк итеп күрсәтә.

Ә НИШЛӘП ӘЛЕ…

– Бездә халык бик тату яши, – ди зур горурлык белән җирле үзидарә башлыгы. – Бакырчылылар – бу сүз үзе үк горур яңгырый! Үзара салым хисабына эшлибез барысын да. Ә районыбыз башлыгы барлык программаларда да катнашырга тырыша, шуңа да бездә гел нидер төзекләндерелеп, төзелеп тора.

Күптән түгел төзелеп беткән өр-яңа авыл клубы халыкны да, безне – килгән кунакларны да – күпфункцияләлеге белән сокландырып балкып утыра.

– Яшьләр өчен дискотекалар уздырабыз… Өлкәнрәкләр белән аларның кызыксынуларына йөз тотып эшлибез. Балалар белән походларга йөрибез, – дип, клубның эшләрен санап чыга клуб мөдире Миләүшә Сәлахиева.

Бакырчыга барганнан соң, Россиядәге ерак авылларның юкка чыгуы хакындагы сүзләрнең сафсата икәнлегенә инандык. Бөтен җирдә дә мондагыдай яшәсеннәр иде ул! Өй дә карап кайттык. Сатыла, диделәр. Ә нишләп әле барып яшәмәскә, ди?!

НИЧЕК БАРЫРГА:

Казаннан чыккач, М-7 трассасы буенча барабыз. Кири авылы ягына – сулга борылабыз. Алга таба – Норлатка борылабыз, ә аннан инде Бакырчыга кул сузымы ара гына кала. Ул Акъегет авыл җирлегенә керә.

НӘРСӘГӘ ГАҖӘПЛӘНЕРГӘ:

Без китәр алдыннан гына… кабакларга гаҗәпләндек. Авыл башында алыптай зур җете сары йомрылар озатып калды. Боларга исе киткән бәндәләр без генә булмадык. Яшел Үзән районы башлыгы ярдәмчесе дә, соклануын яшермичә, машинадан сикереп төшеп, кабак плантациясе хуҗасына Шәһәр көнендәге күргәзмәдә катнашырга чакырды. Кабак хуҗасы исә: «Уйлармын», – диде.

КЕМ БЕЛӘН ЧАГЫШТЫРЫРГА:

Бакырчы мәчете һәм аның авторына сокланып, узган гасырдагы тагын бер күренекле эшмәкәрне искә аласы килә. Казан губернасы Цивильск өязе Акъегет волосте Бакырчы авылы кешесе Шакир Әхмәтов, Чиләбе каласына китеп, байлык туплый. Чиләбе сәүдәгәре Әхмәтовның еллык капитал әйләнеше искиткеч зур сумманы тәшкил итә – 600 тәңкәне. Бу 1912 ел өчен гаять зур акча санала. Чиләбедә Шакир Әхмәтов үзенең хәйриячелек эшләре белән дан казана – әллә ничә мәчетне тотарга ярдәм итә ул. Моннан тыш, Шәһәр думасының гласные, Чиләбе мөселман хәйриячелек оешмасының оештыручысы һәм Чиләбе мөселман халык китапханәсе әгъзасы да. Тарих кабатлауларны ярата.

МАХСУС ПРОЕКТ

— 26нчы чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

PRESSA.RU

Альберт Шиһабетдинов,
«ТАИФ» ААҖ генераль директоры, ноябрь аенда үзенең 65 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Азат Бикмурзин,
«Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ генераль директоры

Масштаблы фикерләү өчен масштаблы проектлар

Хөрмәтле Альберт Кашафович! 65 яшьлек туган көнегез уңаеннан шәхсән үз исемемнән һәм «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ коллективы исеменнән ихлас котлауларыбызны кабул итегез!

Без Сезне катлаулы проблемаларны хәл иткәндә зур энергия һәм инициатива күрсәтүче кеше, тәҗрибәле һәм җаваплы җитәкче, үз-үзен конкрет эшләрдә раслаган шәхес буларак беләбез һәм аерым хөрмәт белән карыйбыз. Тирән белемегез, өзлексез хәрәкәттә яшәвегез, идарә итү осталыгыгыз, алга бару омтылышыгыз һәм перспективага, киңкүләм проектларны тормышка ашыруга эшләвегез – Сезне әнә шул сыйфатлар билгели. Һәм боларны катлаулы чорда «ТАИФ» КТ составына кергән нефтехимиклар да эш барышында тойды. Төркем эчендә дә, һәм, гомумән, нефть эшкәртү һәм нефть химиясе тармаклары арасында да, чимал белән тәэмин итү һәм әзер продукцияне сатуда компанияләрнең үзара бәйләнешен төгәл оештыруда Сезнең ярдәмегез бу чорны намус белән үтәргә мөмкинлек бирде. Бүгенге көндә Сезнең турыдан-туры катнашыгыз белән, хөрмәтле Альберт Кашафович, компания ихтыяҗга ия булган югары сыйфатлы һәм тотрыклы рентабельле үсештәге продукциясен җитештерүгә нигезләнгән потенциалын үстерә бара, энергия куркынычсызлыгын һәм энергия нәтиҗәлелеген күтәрү, әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләрен уңышлы хәл итә.

Юбилей – ул һәрчак бер этап, һәрвакыт үткәннәргә борылып карау, якынча нәтиҗәләр ясау, яшәлгән еллар турында уйлану һәм шуның белән бергә – булачак вакыйгаларны, перспективаларны ваемлау, яңа омтылышлар, максатлар һәм хыяллар да. Шушы әһәмиятле көндә мин Сезгә чын күңелдән иң кыю планнарыгызның тормышка ашуын телим! Тормышыгызны һәрвакыт җан җылысы, дусларыгызның һәм коллегаларыгызның, якыннарыгыз һәм туганнарыгызның ярдәме тулыландырып торсын. Сезнең искиткеч һөнәри һәм шәхси сыйфатларыгыз белән эшлекле абруегыз әле тагын күп еллар буена «ТАИФ» Компанияләре төркеменең, Татарстанның һәм бөтен Россиянең чәчәк атуына уңышлы хезмәт итсен!

Рушан Шәмгунов,
«ТАИФ-НК» ААҖ
генераль директоры

Үз заманының кешесе

Хөрмәтле Альберт Кашафович!

«ТАИФ-НК» компаниясе коллективы һәм үз исемемнән туган көнегез белән ихлас котлауларыбызны кабул итегез! Эшкә сәләтегез һәм югары эшлекле сыйфатларыгыз алдагы елларда да планнарыгызны, изге ниятләрегезне һәм башлангычларыгызны тормышка ашырырга ярдәм итсен!

Тормыш юлыгыз – максатчанлык, инициатива һәм хезмәт сөючәнлекнең уңыш һәм лаеклы хөрмәт казанугa китерүенең ачык мисалы. Вакытны тоемлый, алга карап эш итә, нәтиҗәле стратегия кора белүегез һәрвакыт матур нәтиҗәләргә ирешергә булыша. Бүген Сезне хаклы рәвештә иң абруйлы һәм тәҗрибәле топ-менеджерларның берсе дип исәплиләр; энергиягез, күпкырлы белемегез һәм оештыру сәләтегез эзлекле рәвештә алга таба хәрәкәт итәргә, идея туу белән эре проектларны тормышка ашыра башлау принцибы буенча перспективалы максатларга ирешүгә юнәлтелгән бурычларны уңышлы хәл итәргә мөмкинлек бирә. Сезнең барлык хезмәт биографиягез – Татарстан Республикасының сәнәгать бизнесы үсешенә керткән бәяләп бетергесез өлешегез. Татарстан Республикасы нефть эшкәртү тармагының инновацион үсеше, «ТАИФ» ААҖнең барлык предприятиеләрендәге камилләштерү процесслары Сезнең исем белән бәйле. Шәхеснең зурлыгы хәл ителә торган мәсьәләләрнең зурлыгы, башкарылган эшкә куелган бәянең дәрәҗәсе белән билгеләнә. Ирешелгән хезмәт уңышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәт өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан бирелгән бүләкләр – тырышлыгыгызны югары бәяләүче дәлилләр. Һәм иң мөһиме –кешеләрнең сезгә булган ихтирамы гомерегез буе озата килә, алар өчен Сез һәрвакыт югары хезмәт сөючәнлекнең, новаторлыкның һәм кешеләрне берләштерә белүнең ачык мисалы булып тордыгыз.

Хөрмәтле Альберт Кашафович! Бүген Сез тормышыгызның иң нәтиҗәле чорына кердегез – бай тәҗрибәгез гармонияле төстә зирәклек һәм тормыштан алынган белемнәрегез белән яраша; бик күп нәрсә эшләнгән, ә киләчәк исә яңа планнар белән тулы. Ихлас күңелдән Сезгә сәламәтлек һәм иминлек, һөнәри эшчәнлегегездә яңа эшләр һәм зур җиңүләр, фикердәшләрегез командасына бетмәс-төкәнмәс энергия һәм иҗади дәрт, зур һәм тату гаиләгезгә бәхет телибез!

Реклама

PRESSA.RU

Тәлгать Абдуллин,
«Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешманың башкаручы директоры

Уңыш – төптән уйлап эш итүдә

Хөрмәтле Альберт Кашафович!

Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды коллективы һәм үз исемемнән 65 яшьлегегез уңаеннан ихлас котлауларыбызны кабул итегез!

Республикабызда гына түгел, Россиядә һәм аннан читтә дә танылган иң эре холдингларның берсе – «ТАИФ» ААҖнең тарихы Сезнең исем белән аерылгысыз бәйләнгән. Илебез өчен катлаулы чорда – икътисадый үзгәртеп корулар заманында, сәнәгать җитештерүенең күләме түбәнәя барган вакытта «ТАИФ» ААҖнә җитәкчелек итеп, иң югары стандартлардагы компания төзи алдыгыз. Компания үсешенең планлы төстә тормышка ашырылучы барлык программалары, җитештерүне камилләштерүгә һәм яңа төзелеш эшләренә кертелгән инвестицияләрнең күләмнәре, холдинг продукциясенең ил эчендә һәм аннан читтә файдалану базарының даими үсүе шул хакта сөйли.

Сез үзегез дә, тәҗрибәле һәм алга карап эш итә белүче җитәкче буларак, республикада хаклы рәвештә лаеклы ихтирам һәм югары абруй казандыгыз. Һәр әйткән сүзегезнең, фикерегезнең йогынтысы көчле. Үз тирәгезгә профессионаллардан һәм төптән уйлап эш итә белә торганнардан гыйбарәт, республикабызның социаль-икътисадый үсеше өчен күп эш башкарган лаеклы команда туплый алдыгыз. 2016 елда гына да «ТАИФ» ААҖ тарафыннан Татарстан Республикасының балачакка, мәгариф һәм мәдәниятка, сәламәтлек саклау һәм спортка ярдәм итүне дә үз эченә алган социаль проектларын тормышка ашыру өчен 67,6 млрд сум акча күчерелде.

«ТАИФ» ААҖ корпоратив стратегиясенең төп юнәлешләре арасында комплекслы социаль-икътисадый программаларны тормышка ашыру эшендә актив катнашу да бар. Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды һәм «ТАИФ» ААҖ күптәнге һәм ышанычлы партнерлар булып исәпләнә, шуңа күрә торак программаларының уңышлы тормышка ашырылуында моның да роле зур. Бер интервьюгызда Сез: «Без һәрвакыт кризис чорындагы кебек эшлибез», – дигән идегез. Мөгаен, уңышның сере дә шундадыр: һәрвакыт киеренке шартларны саклау, барлык проектларга да төптән уйлап һәм тормышчан якын килә белү. Шуңа күрә Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды өчен «ТАИФ» ААҖ һәм шәхсән үзегез белән хезмәттәшлек итү – безнең өчен зур дәрәҗә һәм җаваплылык.

Мондый гаять зур холдинг белән җитәкчелек итү бик күп көч һәм зирәклек таләп итә. Сезгә хезмәттәшләрегез, банклар, потенциаль инвесторлар белән һәр көн, һәр сәгать, һәр минут бергә эшләргә туры килә. Шуңа күрә 65 яшь тулу көнегездә, хөрмәтле Альберт Кашафович, Сезгә иң мөһим кыйммәтләр – ныклы сәламәтлек, гаиләгезнең, туганнарыгызның, якыннарыгызның иминлеген телибез. Киләчәктә дә Сездәге профессиональлек, эшкә бирелгәнлек, гаять зур идарә итә белү тәҗрибәсе, кат-кат уйланган карарлар кабул итә белү осталыгы иң югары идеяләрне тормышка ашырырга ярдәм итсен.

Реклама

Борис Тихомиров,
«Казан Гипронииавиапром»
АҖ генераль директоры

Иң кыю идеяләр хакына

Хөрмәтле Альберт Кашафович, Сезне юбилеегыз белән тәбрик итә алуыма һәм күркәм шәхси сыйфатларыгызга, бай һөнәри тәҗрибәгезгә соклану белдерү мөмкинлегенә шатмын.

Сезне үз эшенә бирелгән, яңалыкны күрә һәм кабул итә белү сәләтенә ия кеше буларак тәбрикләү аеруча күңелле. «ТАИФ» ААҖ егерме елдан артык җитәкләвегез үзе үк күп нәрсә хакында сөйли. Бу еллар эчендә талантлы һәм энергияле, иң мөһим проектларны хәл итә ала торган профессионаллардан торган зур команда тупладыгыз. Шунысы куанычлы: җитәкче урыннарда эшләү Сезнең һәрвакыт күтәренке кәефтә һәм һәрчак хәрәкәттә булуыгызны, новаторларча уйлый белүегезне аз гына да киметмәде.

Алга карап эш итә белүегез, энергияле һәм эшкә искиткеч сәләтле булуыгыз республика үсешендәге уңай үзгәрешләрне билгеләүче бизнеста зур уңышларга ирешергә мөмкинлек бирде.

Туган көнегезнең тормышыгыздагы тагын да зуррак бурычлар куелган яңа сәхифәсен ачуына ышанам. Һәрвакыт шундый эшлекле һәм актив булып калуыгызны телим.

Һәр көнегез сөенеч һәм башкарылган эштән канәгатьлек хисе белән тулып торсын. Ныклы сәламәтлек, күңел күтәренкелеге һәм иң кыю идеяләрегезнең тормышка ашуын телим!

Азат Хәким,
«Тулпар Аэро Групп»
Директорлар советы рәисе

Яңа дәвер – яңа бурычлар

Хөрмәтле Альберт Кашафович!

Юбилеегыз белән чын күңелдән котлыйбыз! Дөресрәге, тормышыгызның чираттагы дәвере башлануы белән тәбрик итәбез! Юбилей датасы аз гына вакытка тукталып торырга, артка әйләнеп карарга һәм тормыш юлындагы билгеле бер вакытка йомгак ясау өчен сәбәп ул. Ә йомгаклар бик тәэсирле! Горурланырга да, шатланырга да урын бар.

Республиканың нефть химиясенә керткән өлешегез бәяләп бетергесез зур. Талантлы һәм күпкырлы шәхес буларак, авиациягә дә хезмәтегез керде. Эшлекле авиация һәм техник хезмәт күрсәтүдәге уртак проектлар гаять уңышлы булды. Бу уңышларда Сезнең Казан авиация институтында алган белемнәрегезнең ярдәме зур иде. Без Сезнең белән бер дулкында эшлибез, һәм шуңа күрә «Тулпар Эйр» «Авиакомпания» ҖЧҖ Россия эшлекле авиациясенең гомумтанылган лидеры булып исәпләнә, ә «Тулпар Техник» Россиядәге техник хезмәт күрсәтү предприятиеләренең беренче бишлегенә керә.

Күпсанлы коллективыбыз һәм үз исемемнән Сезне чын күңелдән тәбрик итәм һәм ныклы сәламәтлек, уңышлар, иминлек һәм алга таба да уртак проектлар үсешендә уңышлар телим.

Реклама

Сергей Когогин,
«КАМАЗ» ГАҖ генераль директоры, ноябрь аенда үзенең 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Борис Тихомиров, «Казан Гипронииавиапром» АҖ генераль директоры

Илнең иң яхшы топ-менеджерларының берсе

Хөрмәтле Сергей Анатольевич!

«Казан Гипронииавиапром» компанияләре төркеме исеменнән Сезне күренекле дата – 60 яшьлек туган көнегез белән котлыйм!

Казан дәүләт университетының физика факультетын тәмамлаганнан соң, Сезнең 35 еллык хезмәт эшчәнлегегез Татарстан Республикасы икътисады һәм сәнәгате белән уңышлы идарә итүгә һәм үстерүгә бәйле. Яшел Үзән машина төзелеше заводындагы тырыш хезмәтегезне бик яхшы хәтерлибез – анда гади инженердан директорга кадәр күтәрелдегез. Шул вакытта ук безнең институт Сезнең белән бергә, Көнбатыш санкцияләрен җиңеп чыгу максатында, авиация двигательләре базасында импортны алыштыручы газ суырту агрегатлары һәм станцияләре җитештерүне оештыру мәсьәләсен хәл итте.

Аннары Яшел Үзән районы хакимияте башлыгы, Премьер-министр урынбасары, Татарстан Республикасы икътисад һәм сәнәгать министры вазыйфаларын уңышлы башкардыгыз. Федераль үзәк белән үзара файдалы уңышлы мөнәсәбәтләр урнаштыруда, фән һәм сәнәгать куәтен үстерүдә, эшмәкәрлек һәм кече бизнеска ярдәм итүдә, республика халкының тормышын яхшыртуда шактый зур шәхси өлешегезне керттегез.

Сез бүген – КАМАЗның генераль директоры – илнең иң яхшы менеджерларының берсе исәпләнәсез, илебезнең иң әһәмиятле ихтыяҗларын тәэмин итеп, шулай ук продукциягезне дөньяның күп илләренә чыгарып, төрле модификациядәге заманча йөк автомобильләрен күпләп җитештерү белән нәтиҗәле идарә итәсез. «Казан Гипронииавиапром»ы кабина җитештерү буенча Даймлер белән уртак булган уникаль проектны тормышка ашыруга җитәкчелек итүегез белән горурлана.

Сезнең эшлекле сыйфатларыгыз һәм оештыру сәләтегез, тирән белемегез һәм эрудициягез, дөрес карарлар кабул итә белүегез, җаваплылык хисенә ия булуыгыз, хезмәт сөючәнлегегез ил, республика, предприятие белгечләре һәм җитәкчеләрендә тирән хөрмәт уятты. Киеренке хезмәтегез хаклы лаеклы рәвештә икътисад фәннәре кандидаты дәрәҗәсе, Почет һәм Дуслык орденнары белән билгеләнде.

Бу күренекле көндә, хөрмәтле Сергей Анатольевич, Сезгә алга таба да нәтиҗәле эшчәнлек, производствода зур уңышлар, ныклы сәламәтлек телибез!

Руслан Якушев,
«Булгарпиво» ААҖ генераль директоры

Татарстанның зур патриоты

«Булгарпиво» ААҖ коллективы һәм үз исемемнән Сезне, хөрмәтле Сергей Анатольевич, 60 яшьлегегез белән тәбрик итүемә шатмын! Бу көнне тулы егәр һәм күпсанлы проектлар белән каршылавыгыз аеруча күңелле.

Бәяләп бетергесез тәҗрибәгез – ул төрле предприятиеләрдә кырык елдан артык төрле вазыйфалар башкаруыгыз. Һәркайда үзегезне принципиаль җитәкче, чын профессионал итеп таныттыгыз. Шулай да тормышыгыздагы иң зур эш, әлбәттә, «КАМАЗ» проекты булды. Һәм бүген дә Сез әүвәлгечә үк рейтингның югары баскычында торасыз, илнең һәм республиканың иң яхшы производство менеджеры булып исәпләнәсез.

КАМАЗны 15 ел дәвамында җитәклисез. Бу еллар эчендә Сез, Сергей Анатольевич, гаять күп яңа идеяләрне тормышка ашыра алдыгыз. Шуңа күрә кабул ителгән карарлар автогигант эшчәнлегенең һәр катлаулы чорында нәтиҗәле булды. Бүген Сезнең һөнәри осталыгыгыз нәтиҗәсендә КАМАЗ җитештерүнең яңа күрсәткечләренә һәм сатуның ышанычлы үсешенә ирешә. К5 кабиналы өр-яңа йөк машинасы, КАМАЗ шассилы пилотсыз транспорт чаралары, шул исәптән КАМАЗның Фәнни-автомотор институты белән уртак проекты – пилотсыз «Шатл» микроавтобусы базары үсеше – заводның инновацияләргә омтылуы һәм технологик үсеше турында сөйләүче яңа төп проектлары. Һәм биредә шулай ук Сезнең зур хезмәтегез ята, Сергей Анатольевич.

Сезне бөтен дөньяда КАМАЗның генераль директоры буларак кына түгел, Россия автоҗитештерүчеләр берләшмәсе рәисе буларак та беләләр.

Барлык хезмәттәшләрегез – бүгенгеләре дә, Яшел Үзән машина төзелеше заводында, Яшел Үзән районы хакимиятендә, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында бергә эшләгән кешеләр дә Сезне конструктив, ныклы ихтыяр көченә ия җитәкче итеп беләләр. Һәм – республикабызның зур патриоты итеп тә. Раифа монастыре, Свияжскидагы Успение-Богородица ирләр монастыре, Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгы, «Изумрудный город» һ.б. тарихи һәйкәлләрне торгызу эшләренең башлап йөрүчесе булдыгыз.

Җитештерүдә дә, депутатлык эшендә дә, иҗтимагый тормышта да Сез һәрвакыт искиткеч талантка һәм эшлекле сыйфатларга ия булуыгызны раслыйсыз. Күпсанлы бүләкләрегез (алар арасында Дуслык ордены, «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале, РПЧнең II дәрәҗә Изге Даниил ордены, коррупциягә каршы көрәштәге хезмәтләрегез өчен II дәрәҗәдәге Намус ордены бар) шул хакта сөйли.

Сезнең юбилеегыз, Сергей Анатольевич, үзебезнең ихлас хөрмәтебезне белдерү һәм алга таба барлык планнарыгызны һәм проектларыгызны тормышка ашыруда уңышлар теләү өчен күңелле бер сәбәп. Кешеләргә кылган игелегегез КАМАЗ хезмәткәрләре, Яр Чаллы һәм республика халкының рәхмәте булып үзегезгә әйләнеп кайтсын. Ныклы сәламәтлек, профессиональ һәм гаилә иминлеге телибез Сезгә!

Реклама

PRESSA.RU

Без Татарстан риваятьләрен җыюыбызны дәвам итәбез, ә алар безнең якларда бик күпләп «яши». Аларга Балтач районы да бай. Шуңа да безнең бу тарих – әлеге серле урыннардан.

ТАТАРСТАН РИВАЯТЬЛӘРЕ: «КАРА КҮЛ» ҺӘМ АНЫҢ КҮЧЕШЛӘРЕ

Балтачтан Каракүлгә кадәр – кул сузымы гына ара. Аның ярына нинди кәеф, нинди уйлар белән килүегезгә карамастан, күл көзгесенә күз салу да җитә – башыгыз җиңеләеп, бушап кала, ә тагын берничә мизгелдән моннан бөтенләй дә китәсегез килми башлый. Ә моның сәбәбе – күлнең үз холкы, характеры булуда. Дөрес, бик үк гади түгел ул. Бүгенге көнгә кадәр риваять итеп сөйләнә торган вакыйгалар шаһит аңа.

Бик күп еллар элек күл бөтенләй башка урында – Шушма елгасы аръягындагы әрәмәлек артында «яшәгән», диләр. Ул чакта ук күл җирле халык өчен үзенчәлекле урын саналган: аңа тере җан иясенә карагандай караганнар, чисталыгын саклаганнар. Бервакыт бай йорттагы хезмәтче кыз, кояшта кипкән керләрне җыйганда, күңелсез хәлгә тарыган: хуҗабикәнең иң кыйммәтле һәм иң яраткан күлмәген пычракка төшереп җибәргән! Хуҗабикәсенең ачуыннан куркып, ул, күлмәкне тоткан килеш, ишегалдыннан йөгереп чыгып киткән. Күл янына килгән дә, озак уйлап тормыйча, күлмәкне суга салган. Нindiдер тылсым кылынгандай, күлмәкнең пычрагы шунда ук юылып төшкән. Кыз, сөенеп, өенә йөгергән. Әмма, ялтырап торган су көзгесенә тагын күз салырга дип борылып караса, күлдән җилләр искән ди.

Күлнең күчеше турында тагын бер риваять бар, монысы фаҗигале. Бер кыз, күл ярына килеп, ачы күз яшьләрен түккән: балага узганын белгәч, аны сөйгән егете ташлап киткән булган. Нишләргә? Хурлыкка калып, бер өметсез яшәргәме? Баланы ничек ялгызына үстерергә? Һәм, суга карап торганда, кыз җавап ишеткәндәй була. Бала туганнан соң, ул кабат яр буена килә һәм, көймәгә утырып, күлнең уртасына кадәр йөзеп керә дә сабые белән бергә суга ташлана. Һәм барысы да юкка чыга: кыз да, бала да, күл дә…

Бүгенге көнгә кадәр кешеләр Каракүлнең тирәнлеге турында бәхәсләшәләр – кемдер 18 метр ди, ә кемдер 100гә кадәр җитә, дип раслый. Вакыты-вакыты белән караңгы су төбеннән кояш яктысына зуп-зур балыклар күтәрелә. Суга игътибар белән карап торсаң, аларны күреп була, диләр. Ә бәлки, аларны гына да түгелдер…

Реклама 16+
ТАТАРСТАН
Журнал акыллы, игелекле, мәңгелек кыйммәтләргә ия булган эксклюзив открыткалар сериясе тәкъдим итә
Яратып, Татарстаннан
1. КИС
2. ТИЕШЛЕ ФОНГА УРНАШТЫР
3. ФОТОГА ТӨШЕР

PRESSA.RU

Иң мөһим әйберләргә мәхәббәт белән!
Реклама 16+
Татарстанымны яратам!